Титул

# VI Бөтендөнья татар яшьләре форумы
# ПРОГРАММАСЫ
# 1–5 август 2014 ел

## 1 АВГУСТ (ҖОМГА)

| | |
|---|---|
| Катнашучыларның килүе, теркәү, Универсиада авылына урнаштыру (*БТК Башкарма комитеты, К. Маркс ур., 38/5*) | |
| | Делегатларның килү көне. |
| 11.30-12.30 | **Төшке аш** *(«Казан» милли мәдәният үзәге , Пушкин ур., 86)* |
| 13.00-14.00 | **Кол Шәриф мәчете белән танышу** |
| 14.00-16.00 | **Казан шәһәре буйлап экскурсия** (Иске татар бистәсе, Казан Кирмәне, Казанның меңъеллыгы музее) |
| 16.00-16.30 | **«Казан» милли мәдәният үзәгенә бару** *(Пушкин ур., 86)* |
| 16.30-17.00 | **Кичке аш** *(«Казан» милли мәдәният үзәге, Пушкин ур., 86)* |
| 17.00-17.30 | **Г. Камал исемендәге ТДА театрына бару** *(Татарстан ур., 1)* |
| 17.30-18.00 | **Г. Камал исемендәге ТДА театры янында яшьләр спорты төрләре тамашасы** |
| 18.00-20.00 | **«Идел» яшьләр журналының әдәби-музыкаль юбилей кичәсе** *(Г. Камал исемендәге ТДА театры, Татарстан ур., 1)* |
| 20.00-20.30 | **Тору урыннарына кайту** *(Универсиада авылы)* |

## 2 АВГУСТ (ШИМБӘ)

| | |
|---|---|
| 07.30-08.30 | **Иртәнге аш** (*тору урыннарында*) |
| 08.30-09.00 | **Г. Камал исемендәге ТДА театрына бару** *(Татарстан ур., 1)* |
| 09.00-10.00 | **Г. Камал театры фоесында Татарстан Республикасыныңхалык кул эшләре үрнәкләре күргәзмәсе** |

| | |
|---|---|
| 10.00-13.00 | **Форумны ачу. Пленар утырыш**<br>*(Г. Камал исемендәге ТДА театры, Татарстан ур., 1)* |
| 13.00-13.30 | **«Казан» милли мәдәният үзәгенә бару** *(Пушкин ур., 86)* |
| 13.30-14.30 | **Төшке аш** *(«Казан» милли мәдәният үзәге,*<br>*Пушкин ур., 86)* |
| 14.30-15.00 | **Секцияләр утырышы урыннарына бару** |
| 15.00-17.00 | **Секцияләр/ Проектлар мәктәбе**:<br>**1)** «Мин Татарча Сөйләшәм» һәм «Tatweb». Милли мәгариф һәм татар телен өйрәтүдә, саклап калуда яңа технологияләр, Татарстанда икетеллелек проблемалары; *(IT-парк, Петербург ур., 52)*<br>**2)** «Рух». Бүгенге татар яшьләренең тарихи үзаңнары һәм халкыбызның рухи кыйммәтләре; *(«Казан» милли мәдәният үзәге, Пушкин ур., 86)*<br>**3)** «Бизнес яшьлек»; *(«Казан» милли мәдәният үзәге, Пушкин ур., 86)* |
| 17.00-17.30 | **«Казан» милли мәдәният үзәгенә бару** *(Пушкин ур., 86)* |
| 17.30-18.30 | **Кичке аш** *(«Казан» милли мәдәният үзәге,*<br>*Пушкин ур., 86)* |
| 18.30-19.00 | **Тору урыннарына кайту** *(Универсиада авылы)* |
| 20.00-22.00 | **Зөлфия Камалова һәм Мубай концерты** *(Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясенең концерт залы, Универсиада авылы, 35)* |

## 3 АВГУСТ (ЯКШӘМБЕ)

| | |
|---|---|
| 7.30-08.30 | **Иртәнге аш** (*тору урыннарында*) |
| 08.30-09.00 | **Г. Камал исемендәге ТДА театрына бару**<br>*(Татарстан ур., 1)* |
| 09.00-11.00 | **Проектлар мәктәбенең нәтиҗәләрен чыгару, яңа проектларны тәкъдим итү**.<br>Бөтендөнья татар яшьләре форумының җитәкче органнарын сайлау. Форум документларын кабул итү *(Татарстан ур.,1)* |
| 11.00-12.30 | **Дискуссия: «Яшь татар гаиләсе һәм аның алдында торган сынаулар»** *(Татарстан ур. 1)* |
| 12.30-13.00 | **«Казан» милли мәдәният үзәгенә бару** *(Пушкин ур., 86)* |

| | |
|---|---|
| 13.00-14.00 | **Төшке аш** *(«Казан» милли мәдәният үзәге, Пушкин ур., 86)* |
| 14.00-16.00 | **Арча муниципаль районына бару** |
| 16.00-19.00 | **Бөтендөнья форумы делегатлары катнашында Арча шәһәре көне** |
| 19.00-20.00 | **Кичке аш** |
| 20.00-22.00 | **Тору урыннарына кайту** |
| 23.00-00.00 | **«Мин татарча сөйләшәм акциясе»** ***(Универсиада авылы)*** |

## 4 АВГУСТ (ДҮШӘМБЕ)

| | |
|---|---|
| 07.00-08.00 | **Иртәнге аш** (*тору урыннарында*) |
| 08.00-11.00 | **Болгар шәһәренә бару** |
| 11.00-12.00 | **Төшке аш** |
| 12.00-15.00 | **«Болгар» тыюлыгы буенча экскурсия** |
| 16.00-19.00 | **Казанга кайту** |
| 19.00-20.00 | **Кичке аш** *(«Казан» милли мәдәният үзәге, Пушкин ур., 86)* |
| 20.30-21.00 | **Тору урыннарына кайту** ***(Универсиада авылы)*** |

## 5 АВГУСТ (СИШӘМБЕ)

| | |
|---|---|
| 08.00- | Форум делегатларының һәм кунакларның китүе |

**ПРОГРАММА**
**VI Всемирного Форума татарской молодежи**
**1–5 августа 2014 г.**

## 1 АВГУСТА (ПЯТНИЦА)

| | |
|---|---|
| Заезд, регистрация и размещение участников в гостиницы (*Исполком ВКТ, ул. К.Маркса 38/5*) | |
| | День приезда делегатов |
| 11.30-12.30 | Обед (*НКЦ «Казань», ул. Пушкина, 86*) |
| 13.00-14.00 | Посещение мечети Кул-Шариф |
| 14.00-16.00 | Экскурсия по городу Казани *(Старо-татарская слобода, Казанский Кремль, Музей тысячелетия Казани)* |
| 16.00-16.30 | Переезд в НКЦ «Казань» *(ул. Пушкина, 86)* |
| 16.30-17.00 | Ужин *(НКЦ «Казань», ул. Пушкина, 86)* |
| 17.00-17.30 | Переезд в театр им. Г. Камала |
| 17.30-18.00 | Представление молодежных видов спорта возле театра им. Г. Камала |
| 18.00-20.00 | Юбилейный литературно-музыкальный вечер молодежного журнала «Идел» *(Театр им. Г. Камала, ул.Татарстана, 1)* |
| 20.00-20.30 | Переезд к местам проживания *(Деревня Универсиады)* |

## 2 АВГУСТА (СУББОТА)

| | |
|---|---|
| 07.30-08.30 | Завтрак (*по месту проживания*) |
| 08.30-09.00 | Переезд в театр им. Г. Камала *(ул. Татарстана, 1)* |
| 09.00-10.00 | Выставка изделий народных промыслов Республики Татарстан в фойе театра им. Г. Камала |
| 10.00-13.00 | Открытие Форума. Пленарное заседание *(Театр им. Г. Камала, ул. Татарстана, 1)* |
| 13.00-13.30 | Переезд в НКЦ «Казань» (*ул. Пушкина, 86*) |
| 13.30-14.30 | Обед (*НКЦ «Казань», ул. Пушкина, 86*) |
| 14.30-15.00 | Переезд в места проведения секционных заседаний |

| | |
|---|---|
| 15.00-17.00 | Работа по секциям/Школа проектов:<br>1) «Мин татарча сөйләшәм» и «Tatweb». Национальное образование и современные технологии в изучении и сохранении родного языка, проблемы двуязычия в Республике Татарстан; *(IT-парк, ул. Петербургская, 52)*<br>2) «Рух». Историческое самосознание татарской молодежи и духовные ценности татарского народа; *(НКЦ «Казань», ул. Пушкина, 86)*<br>3) «Бизнес для молодых» *(НКЦ «Казань», ул. Пушкина, 86)* |
| 17.00-17.30 | Переезд в НКЦ «Казань» |
| 17.30-18.30 | Ужин (*НКЦ «Казань», ул. Пушкина, 86*) |
| 18.30-19.00 | Переезд к местам проживания *(Деревня Универсиады)* |
| 20.00-22.00 | Концерт Зульфии Камаловой и Мубая *(Концертный зал Поволжской государственной академии физической культуры, спорта и туризма)* |

## 3 АВГУСТА (ВОСКРЕСЕНЬЕ)

| | |
|---|---|
| 7.30-08.30 | Завтрак (*по месту проживания*) |
| 08.30-09.00 | Переезд в ТГАТ им. Г. Камала (*ул. Татарстана, 1)* |
| 09.00-11.00 | Подведение итогов работы школы проектов, презентация новых проектов. Выборы руководящих органов ВФТМ. Принятие итоговых документов *(театр им. Г. Камала, ул. Татарстана, 1)* |
| 11.00-12.30 | Дискуссия: «Испытания современной татарской семьи» |
| 12.30-13.00 | Переезд в НКЦ «Казань» (*ул. Пушкина, 86*) |
| 13.00-14.00 | Обед (*НКЦ «Казань», ул. Пушкина, 86*) |
| 14.00-16.00 | Переезд в Арский муниципальный район |
| 16.00-19.00 | День города Арск с участием делегатов Всемирного форума |
| 19.00-20.00 | Ужин |
| 20.00-22.00 | Переезд к местам проживания *(Деревня Универсиады)* |
| 23.00-00.00 | Акция «Мин татарча сөйләшәм» *(Деревня Универсиады)* |

## 4 АВГУСТА (ПОНЕДЕЛЬНИК)

| | |
|---|---|
| 07.00-08.00 | Завтрак (*по месту проживания*) |
| 08.00-11.00 | Переезд в г. Булгар |
| 11.00-12.00 | Обед |
| 12.00-15.00 | Экскурсия по Булгарскому музею-заповеднику |
| 16.00-19.00 | Переезд в г.Казань |
| 19.00-20.00 | Ужин (*НКЦ «Казань», ул. Пушкина, 86*) |
| 20.30-21.00 | Переезд к местам проживания *(Деревня Универсиады)* |

## 5 АВГУСТА (ВТОРНИК)

| | |
|---|---|
| 08.00- | Отъезд делегатов и гостей Форума |

# I өлеш
# VI Бөтендөнья татар яшьләре форумы

## ПЛЕНАР УТЫРЫШ

*(Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры)*

**02.08.2014**

*Чыгыш ясаучылар:*

*1. Энгель Нәвапович **ФӘТТАХОВ** – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры.*

*2. Ринат Зиннурович **ЗАКИРОВ** – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе.*

*3. Тәбрис **ЯРУЛЛИН** – Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе.*

*4. Рашат **ЯКУПОВ** – БТЯФ советы әгъзасы, татар-төрек лицееның татар теле укытучысы.*

*5. Әлфрид **БОСТАНОВ** – философия фәннәре докторы (PhD), Санкт-Петербургтагы Европа университеты профессоры;*

*6. Әмир **ҖИҺАНШИН** – Канада татарларының «Берлек» оешмасы әгъзасы.*

*7. Айрат **ФӘЙЗРӘХМАНОВ** – тарих фәннәре кандидаты, Бөтендөнья Татар яшьләре форумы советы әгъзасы.*

*8. Эмиль **ФӘЙЗУЛЛИН** – Мәскәү татар яшьләре оешмалары шурасы җитәкчесе.*

*9. Рамил **НӘҖМЕТДИНОВ** – «Станкин» Мәскәү дәүләт технология университетының югары квалификацияле кадрлар әзерләү үзәге рәисе, яшь галимнәр өчен фән һәм техника өлкәсендә Россия Федерациясе хәкүмәте Премиясе лауреаты, техник фәннәр кандидаты. (Темасы: «Түбән Новгород өлкәсендәге татар оешмасы эшчәнлеге, сәләтле укучыларны укырга кертү һәм татар авылларын җанландыру»).*

*10. Рифкат **ФӘХРЕТДИНОВ** – Кытай татар яшьләре лидеры.*

*11. Хәлил **ШӘЙХЕТДИНОВ** – Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары.*

**Алып баручы:** Т.М. ЯРУЛЛИН – Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Хөрмәтле форум делегатлары, хөрмәтле Президиум әгъзалары, хөрмәтле кунаклар. Иң элек оештыру комитеты исеменнән һәммәгезне дә кайнар сәламләргә, Казанга килү мөмкинлеге табуыгыз өчен рәхмәт әйтергә һәм нәтиҗәле эш теләргә рөхсәт итегез.

Татар яшьләре форумына милләттәшләребез тупланып яшәгән төбәкләрдән иң актив, креатив, иҗади, милли чараларны белгән һәм ул эшләрдә турыдан-туры катнашкан вәкилләребез килгән. Россия Федерациясенең 43 төбәгеннән – 383, дөньяның 24 иленнән – 96, Татарстан Республикасыннан 70 вәкил, ә Казан шәһәреннән 57 делегат катнаша.

Алтынчы Форумны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Бөтендөнья татар яшьләре форумы советы оештырды. Форумны әзерләү эшенә шулай ук Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан хөкүмәте, Татарстанның Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы җитди ярдәм күрсәттеләр. Моның өчен аларга зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Быел катнашучыларыбызга уртача 25 яшь, иң яшь делегатыбызга – 15, иң өлкәненә 42 яшь. Шулай ук бүген безнең хөрмәтле кунакларыбыз арасында туган көнен билгеләүче делегатларыбыз бар. Шакирова Гөлназ Камил кызы, Канаева Сурия Назир кызы! Сезне оештыру комитеты исеменнән туган көнегез белән тәбрик итәбез!

Форумның әзерлек этабында әлеге җыен белән кызыксынуның югары булуы күренде. Безнең Форум эшендә Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, республикабызның мәгариф һәм фән министры Энгель Нәвапович Фәттахов, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Зиннур улы Закиров, Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары Хәлил Хәмит улы Шәйхетдинов, Татарстанның дәүләт хакимияте органнарының башка вәкилләре, татар зыялылары катнаша.

Форумның пленар өлешен алып бару, Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе буларак, миңа – Тәбрис Мөдәрис улы Яруллинга йөкләнде.

Мөхтәрәм форумда катнашучылар, безнең Форумның бүгенге пленар өлешен өч сәгать эчендә, ягъни 13:00 сәгатьтә тәмамларга тәкъдим ителә.

Сезгә таратылган резолюция проектына игътибар итүегезне сорыйм. Чыгышларыгызда аның эчтәлеге турында фикерләрегезне

дә әйтсәгез иде. Резолюцияне пленар утырыш йомгаклары буенча иртәгә кабул итү күздә тотыла.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты эшчәнлегенең бер юнәлеше – яшь буын белән максатчан эш алып бару. Шушы өлкәдә татар конгрессының төп проекты – 2004 елда «Бөтендөнья татар яшьләре форумы» иҗтимагый оешмасының барлыкка килүе һәм татар яшьләре җыеннарын үткәрү. Форум Уставка нигезләнеп ике елга бер җыела.

Бүгенге көндә Форум 100гә якын татар яшьләре оешмаларын берләштерә һәм алар белән һәрдаим эшләп килүче бердәнбер оешма. Җыеннарның нәтиҗәсе шунда: беренче форум делегатлары бер-берсе белән фикер алышып, танышып кына киткән булсалар, хәзер алар иҗтимагый оешмалар төзеп, шуларны җитәкли, төгәл, максатчан эшләр башкара.

Оешманың төп максатлары – туган телне саклауда, халыкның мәдәниятен үстерүдә яңа алымнар табу һәм якын перспективага милләтнең үсеш юнәлешен билгеләү. Форум күпсанлы акцияләр, чаралар оештыра: конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, «Мин татарча сөйләшәм», «Автохәрәкәт», «Интернет татарча сөйләшә», «Татар-дозор», «Чәк-чәк пати», региональ һәм төбәкара форумнар. Күп кенә чараларны Форум активы төрле илләрдә оештырганга күрә, алар халыкара статуска ия булды. Форум һәрвакыт актуаль вакыйгаларга карата үз фикерен белдерә, ачык хатлар һәм мөрәҗәгатьләр кабул итә. Әйтик, безнең соңгы мөрәҗәгатебез Россия Федерациясе мәдәният министры исеменә татар телен яклау максатыннан эшләнде. Күпләрегез безнең бу белдерүне күрде һәм аны тарату эшендә дә безгә нык ярдәм итте.

Бөтендөнья татар яшьләре Татарстан Республикасын тарихи ватан буларак таныйлар һәм дөньяда аның дәрәҗәсен, абруен, әһәмиятен күтәрүгә зур өлеш кертәләр. Бу да форумның бер казанышы.

Форум килгән делегатларга үзләренең тәҗрибәләре белән уртаклашырга һәм шул ук вакытта башкаларның тәҗрибәсен файдаланырга зур мөмкинлек бирә. Форум программасы кызыклы һәм эчтәлекле итеп төзелгән. Пленар утырыштан кала, актуаль темаларга проект мәктәпләре оештырыла. Быелгы җыенда без гадәти секция рамкаларыннан баш тартып, яшьләребезнең үз проектларын тәкъдим итүне керттек. Яшьләргә хас булган кайнарлык белән дискуссиядә үз төбәгегезнең проектларын тәкъдим итә алачаксыз. Шуның белән бергә бу көннәрдә сезгә бик бай мәдәни программа да тәкъдим итәчәкбез, сез мәшһүр Арча якларында, борынгы

Болгарыбызда сәяхәттә булачаксыз. Татарстаныбызда узган бу 5 көн сезнең хәтерегезгә тормышның бер матур мизгеле булып кереп калыр дип ышанабыз.

Форум эшен ачык дип игълан итәм һәм барыгызга да файдалы һәм уңышлы эш көннәре теләп калам!

Хөрмәтле форум делегатлары, сезнең барыгыз исеменнән безнең чарада катнашырга вакыт тапканы өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, республикабызның мәгариф һәм фән министры **Энгель Нәвапович Фәттаховка** зур рәхмәтләребезне белдерәбез. Сүз сезгә бирелә, рәхим итегез.

**Энгель ФӘТТАХОВ:** Хәерле көн, форум делегатлары, хөрмәтле милләттәшләр! Сезне Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов, Татарстан Республикасы Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы исеменнән сәламлим һәм Форум эшендә зур уңышлар телим.

Туган телебезне саклау, камилләштерү – бүген гаять мөһим һәм көн үзәгендә торган мәсьәлә. Җир шарының төрле төбәкләрендә сибелеп яшәүче татарлар өчен туган тел – милләтебезне милли-мәдәни һәм рухи яктан берләштерүче зур көч ул. Иң куанычлысы: кайда гына яшәсәләр дә, дәүләтебез турында кайгыртырлык, милли үзаңлы, заман белән бер адымда баручы алдынгы карашлы яшьләребез бар. Чөнки милләтнең киләчәген, беренче чиратта, яшьләр билгели. Ә инде бүген бирегә Россия Федерациясенең 43 төбәгеннән, 25 ләп чит илдән 600гә якын татар егетләре һәм кызлары җыелган икән, милләтебезнең киләчәге өметле.

Мин бүген татар яшьләрен берләштерү юнәлешендәге әлеге зур мөһим чараны уздырулары өчен Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетына, «Бөтендөнья татар яшьләре форумы» иҗтимагый берләшмәсенә ихлас рәхмәт сүзләрен җиткерергә телим.

Бүгенге көндә дөньяда 7 миллионнан артык татар яши. Шуларның бары 2 миллионы гына Татарстанда. Дөньяның төрле төбәкләрендә сибелеп яшәүче 5 миллионнан артык татар халкы өчен Казан шәһәре һәрвакыт тарихи ватан, милли мәркәз, рухи кыйбла булып тора. Шунлыктан Форумның милли мәркәзебез Казанда үткәрелүе табигый.

Милләтебез соңгы ике дистә ел эчендә зур үзгәрешләр кичерде. Иң мөһиме, безгә бабаларыбызда булган горурлык хисе әйләнеп кайтты. Ә болар, асылда, Татарстанның үсеше белән бәйле. Бүген күңелендә милли хисе булган һәр татар кешесе канатланып Казанга килә, изге Болгар җиренә омтыла.

Татарстан җирлеге, мәркәзебез Казан бөтен дөнья татарларын берләштерүче нык үзәккә әверелде. Халыкара мәдәни бәйләнешләр үсешенә кертекән лаеклы өлеше өчен Казан төрки дөньяның мәдәни башкаласы итеп игълан ителде. Болгар тарихи-археологик комплексы ЮНЕСКО бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде. 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада исә Татарстанны бөтен җир шарына танытты.

Болар барысы да республиканың үз йөзен, дөньякүләм аренада үзенең лаеклы урынын булдыруга юнәлдерелгән акыллы сәясәт нәтиҗәсе. Шул ук вакытта республикабызда туган телне, мәдәниятне, тарихи мирасны, милли традицияләрне саклауга да зур әһәмият бирелә.

Бүгенге көндә Татарстан ике дәүләт телен дә бертигез дәрәҗәдәге югарылыкка куйган, мәктәпләрдә татар һәм рус телләрен тигез күләмдә өйрәнүне законлы рәвештә хәл иткән бердәнбер регион. Республикабыздагы акыллы милли сәясәт, халыклар дуслыгы, этник мөнәсәбәтләрдәге тотрыклылык өчен Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановка, Республика җитәкчелегенә рәхмәтлебез.

Кадерле яшьләребез! Туган телен белгән һәм онытмаган халык кына милләт булып кала; теле бетсә, ул тарала, юкка чыга. Ана теле – ул кешенең үзен саклап калу, яшәтү чарасы, кешенең умыртка баганасы. Бөек Гете «Үзенең туган телен белмәгән кеше шәхес була алмый» дип язып калдырган.

Туган тел халкыбызның тарихын, рухын, ерак гасырлардан буыннан-буынга күчеп килүче гореф-гадәтләрен чагылдыра. Татар теле – милләттәшләребезне рухи берләштерүче, Россия күләмендә һәм киң мәйданда милләтебезнең милли статусын яклаучы көч. Шуңа күрә телебезне саклау – безнең уртак бурычыбыз.

Туган телгә булган мәхәббәт, милли горурлык хисләрен тәрбияләүгә нигез гаиләдә салына. Күренекле галим Ризаэтдин Фәхретдин сүзләре белән әйтсәк, «Бала чакта алынмаган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да биреп бетерә алмас». Туган телнең «ана теле» дип аталуы да очраклы гына түгел. Татар телен сакларга телибез икән, беренче чиратта, ул ана тәрбиясе аша башкарылырга тиеш. Аннан соң гына ул мәктәпкәчә, башлангыч, төп, урта белем бирү оешмаларында үстерелә. Шунлыктан регионнарда татар гаиләләренең милли йөзен, ныклыгын саклап калу зарур. Ә моның өчен татарларның бер йодрык булып берләшеп яшәве кирәк.

Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры буларак, мин шуны әйтә алам: милләтнең бүгенгесен исә милли

белем бирү оешмалары билгели, милләтнең киләчәгенә дә алар нигез ташларын сала. Ә бүген, дөньякүләм глобальләшү шартларында, халкыбызның милли йөзен саклап калу мәсьәләсе аеруча кискенләште.

Шунлыктан узган уку елында милли мәгариф белән идарә итү һәм педагогларга әлеге юнәлештә методик ярдәм күрсәтү системасын ныгыту турында карар кабул ителде. Министрлыкта милли мәгариф идарәсе төзелде, Мәгарифне үстерү институтында милли мәгариф кафедрасы һәм лабораториясе булдырылды, барлык муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге идарә органнары штатына милли мәгариф һәм регионара хезмәттәшлек буенча методист ставкасы кертелде. Хәзерге вакытта милли мәгариф идарәсендә төбәкара хезмәттәшлек буенча аерым бүлек эшләп килә, шулай ук республиканың барлык муниципаль районнары министрлык боерыгы нигезендә аерым төбәкләргә беркетелгән.

Бүгенге көндә Татарстан хөкүмәте белән 70 регион, безнең министрлык белән 29 регион һәм 4 чит ил (Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Төркия) арасында килешүләр төзелде, хезмәттәшлек программалары булдырылды. Һәрбер килешүдә туган телдә белем алу, татар телен саклау, үстерү каралган.

Белгәнегезчә, 2013 елда «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы, «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014–2016 еллар)», «Татарстан Республикасында милли дәүләт сәясәтен 2014–2020 елларга гамәлгә ашыру» дәүләт программасы кабул ителде. «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын координацияләү безнең Министрлыкка йөкләнде. Программаны тормышка ашыру турындагы мәгълүматны киң җәмәгатьчелеккә җиткереп бару, киңәшеп эшләү өчен Иҗтимагый совет төзелде. Совет тарафыннан хезмәт күрсәтүнең төрле сфераларында халыкка ике дәүләт телендә хезмәт күрсәтү, элмә такталарны, рекламаларны ике дәүләт телендә эшләү мәсьәләләре аерым игътибарга алынды.

Әлеге дәүләт программаларында чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм итү юнәлешендә бик күп чаралар каралган. Программалар үз эченә Россия төбәкләрендәге мәктәпләрне укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итү, татар теле укытучыларының белемен күтәрүдә ярдәм күрсәтү, татар мәгарифе көннәрен үткәрү,

татар яшьләре өчен тел өйрәнү лагерьлары оештыру һәм башка күп кенә чараларны ала.

Аерым алганда, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә дә татар дөньясындагы яңалыкларны оператив рәвештә җиткереп бару өчен махсус телевизион тапшырулар эшләнә. Алар «ТНВ-Планета» каналында трансляцияләнәчәк. Август-сентябрь айларында «Мең дә бер җавап», «Әдәби хәзинә», «Без тарихта эзлебез», «Поем и учим татарский язык», «Переведи! Учим родной язык» дип исемләнгән тапшырулар күрсәтелә башлый.

Моннан тыш, программа кысаларында Мәдәният министрлыгы тарафыннан Татарстан кинематографистлары төшергән фильмнарны (алар ике дәүләт телендә дә төшерелә) кинотеатрларда күрсәтү эше тормышка ашырыла башлады.

Безнең максат – әлеге проектларга Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезне мөмкин кадәр күбрәк җәлеп итү, планлаштырылган эшләрне нәтиҗәле итеп башкару. Бу җәһәттән, проектларны уңышлы тормышка ашыру өчен, безнең министрлык, Бөтендөнья татар конгрессы һәм аның урыннардагы бүлекчәләре, милли-мәдәни автономияләр, милли яшьләр оешмалары, дәүләт органнарының уртак максатка юнәлгән бердәм эшчәнлеге сорала.

Республика җитәкчелеге тарафыннан Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм итү йөзеннән максатчан эш алып барыла. Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич үзенең эшлекле визитлары вакытында һәрдаим татар диаспорасы вәкилләре белән очраша, проблемаларны уртага салып хәл итә.

2013 елда Президентыбыз ярдәме белән «АНА ТЕЛЕ» проекты гамәлгә кертелде. «АНА ТЕЛЕ» онлайн мәктәбендә Татарстанда һәм Татарстаннан читтә яшәүче һәркем татар телен өйрәнә, татар мәдәнияте, тарихы хакында мәгълүмат туплый ала. Бүгенге көндә системадан Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе субъектлары һәм дөньяның 33 илендә яшәүче 10 меңгә якын кеше файдалана. Хәзер чит илләрдән татар телен өйрәнүчеләр саны – 253. Аеруча Казахстан (69 кеше), Кытай (29 кеше), Төркия (24 кеше), Австралиядә (17 кеше) яшәүче милләттәшләребез активлык күрсәтә.

Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен татар телен яшь буынга өйрәтүдә әлеге проект бик яхшы мөмкинлек. Бүгенге көндә чит илләр өчен махсус 400 дән артык лицензия бар. Шунлыктан, чит илләрдән килгән яшьләребездән, үз илләренә кайткач, «АНА ТЕЛЕ» онлайн мәктәбе мөмкинлекләре турында киң җәмәгатьчелеккә җиткерүләрен сорыйм.

Иң кирәкле эшләрнең берсе – регионнардагы мәктәпләрне дәреслекләр белән тәэмин итү. Узган уку елында гына да Россия төбәкләренә 3 млн. сумлык 12 меңнән артык дәреслек җибәрелде. Дөрес, бүгенге законнар нигезендә мәктәпләрне дәреслекләр белән тәэмин итү субъектлардагы министрлыклар вазыйфасына керә. Дәреслекләрне чит регионнарга җибәргән өчен безне финанс органнары тәнкыйтьлиләр дә. Чөнки һәрбер регионның үзендә дәреслекләр алу өчен финанслар каралган. Шуңа да карамастан, без киләчәктә дә татар теле һәм әдәбиятыннан, туган телдә бастырылган башка укыту-методик кулланмалар җибәрәчәкбез.

Дәреслекләр турында сүз алып барганда шуны искәртеп үтим: 2013 елда башлангыч сыйныфлар өчен федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп яңа татар теле дәреслекләре һәм методик ярдәмлекләр төзелде. 51 дәреслек (барысы 15 укыту-методик комплекты) уңай эксперт бәясе алып, федераль исемлеккә кертелде. Бүгенге көндә әлеге дәреслекләр Россиянең теләсә кайсы төбәгендә кулланылырга хокуклы. Хәзерге вакытта 5–9, 10–11 енче сыйныфлар өчен татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре төзү буенча киеренке эш бара.

Бүгенге көндә татар тормышына, теленә, мәдәниятенә, сәнгатенә кагылышлы материаллар шактый күп эшләнә. Аларны җир шарында сибелеп яшәүче милләттәшләребезгә оператив җиткерү максатыннан, Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татар иле» сайтына куеп бару эшен җайга салды. «Татар иле» сайтында татар театрының алтын фондына кертелгән спектакльләрне карарга, татар китапларын укырга, татар җырларын тыңларга мөмкин. Моннан тыш, биредә яшьләргә татар телендә аралашу өчен социаль челтәр дә булдырылды.

Икенче мөһим юнәлеш – татар яшьләр оешмалары эшләп тора. Безнең министрлык Татар яшьләре форумы, «Сәләт» яшьләр оешмасы белән нәтиҗәле генә эшләп килә. «Мин татарча сөйләшәм» акциясе, «Сәләт» лагерьлары – алдынгы карашлы актив татар яшьләренең Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә тормышка ашырыла торган уртак проектлары.

Быел сәләтле укучылар өчен яңа форматта «Прага мәктәбе» оештырылды. Әлеге проект кысаларында Татарстанның 40 егете һәм кызы Европаның үзәгендә урнашкан Прага шәһәрендә Германия, Чехия, Австрия галимнәре үткәргән мастер-класс, тренингларда катнашты, үзләренең проектларын яклады. «Прага мәктәбе»нең төп максаты – татар, рус, инглиз телләрен камил белгән, заманча фикерли торган яшь лидерлар тәрбияләү, чит илләрдәге ватандашларыбыз белән уртак проектлар булдыру.

«Алгарыш» проекты кысаларында перспективалы яшьләргә чит ил уку йортларында белем алу өчен шартлар тудырыла. Әлеге проектлар киләчәктә дә дәвам итәчәк.

Министрлык тарафыннан Россия регионнарындагы татар балаларына татар телен тирәнтен өйрәтү максатыннан ел саен махсус профильле тел өйрәтү сменалары оештырыла. Узган ел әлеге лагерьларда 250 укучы ял итсә, быел масштаблар да, катнашучыларның географиясе дә шактый киңәйде. Биектау районында оештырылган «Дуслык» сменасында, Актаныш муниципаль районы җирлегендә оештырылган «Бүләк» лагеренда 700 укучы ял итте.

Тарихта беренче тапкыр «Болгар» музей-тыюлыгы территориясендә татар телен өйрәтү максатыннан 600 укучы өчен палаткалы лагерь оештырылды.

Әлеге профильле тел өйрәтү сменаларында Россия Федерациясенең 24 субъектыннан укучылар катнашты. Аеруча Оренбург өлкәсе (62 укучы), Самара өлкәсе (52 укучы), Пермь крае (46 укучы), Удмуртия Республикасы (45 укучы), Башкортостан Республикасы (39 укучы) активлык күрсәтте. Хәтта Таҗикстан Республикасы, Казахстан Республикасыннан килгән укучыларыбыз да бар иде.

Укучылар өчен лагерьларда татар теле дәресләре, мастер-класслар, тренинглар үткәрелде, балалар республикабызның тарихи урыннары белән таныштылар, галимнәр, сәнгать әһелләре белән очрашулар уздырылды.

Моннан тыш Актаныш районында 1 августтан 7 августка кадәр өр-яңа проект – «Агыйдел» интеллектуаль яшьләр форумы старт алды, анда Россиянең 5 төбәгеннән 150 укучы катнаша. Алда атап үтелгән лагерьлар гуманитар юнәлештә булса, биредә укучыларның техник юнәлештәге сәләтләрен үстерүгә аерым игътибар биреләчәк.

Һичшиксез, алдагы елларда да бу эш дәвам итәчәк. Моннан тыш регионнарның үзләрендә дә тел өйрәтү лагерьларын оештыру максатка ярашлы булыр иде. Без исә кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсендә ярдәм итә алабыз.

Быелгы уку елында икенче мәртәбә татар теле һәм әдәбиятыннан Халыкара олимпиада үткәрелде. Олимпиаданың дистанцион этабында биш меңгә якын студент һәм укучы катнашты. Апрель аенда узган төп этапта 12 чит илдән һәм Россия Федерациясенең 19 субъектыннан 300 егет һәм кыз катнашты. Гран-прига Токио университеты студенты Юто Хисияма һәм Апас районы кызы Илүзә Гайфуллина лаек булды.

III Халыкара олимпиадага октябрь аенда старт бирeләчәк. Олимпиаданың форматын тагын да киңәйтү күздә тотыла. Олимпиаданың эчтәлеге камилләштерeләчәк, татар теленә, әдәбиятына, тарихына, сәнгатенә кагылышлы кызыклы биремнәр белән баетылачак. Төп этапта катнашучылар санын да 500 гә җиткерү планлаштырыла.

Шулай ук масштаблы итеп «Илһам» исеме астында республикакүләм яшь әдипләр бәйгесе уздырылды. Әлеге бәйге татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту, әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне ачыклау, осталыкларын үстерергә ярдәм итү максатыннан, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә үткәрелде. Яшь язучылар бәйгесенә барлыгы 772 эш кабул ителде, 715 егет һәм кыз үз көчләрен сынап карады. Без иҗат дөньясына тәүге адымнарын атлаган яшьләргә киләчәктә зур өметләр баглыйбыз, татар матбугатының һәм әдәбиятының йөзек кашлары – кыю каләмле журналистлар, язучылар һәм шагыйрьләр булып китәрләр дип өметләнәбез. Шунлыктан яңа уку елында үткәрeләчәк әлеге чарада Россия регионнарында яшәүче яшь әдипләрне дә күрергә теләр идек. Әлеге конкурска шулай ук октябрь аенда старт бирeләчәк.

Җәй айларында Россия регионнарындагы сәләтле укучыларны югары уку йортларына кабул итү буенча Бөтендөнья татар конгрессы, милли оешмалар, югары уку йортлары белән зур эш алып барыла. Чит илдә яшәүче ватандашларыбыз исә югары уку йортларына Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Россотрудничество» федераль агентлыгы квотасы аша керәләр. Ләкин абитуриентларның күпчелеге укырга кергәндә конкурс зур булган юнәлешләрне сайлый (юрист, икътисадчы һ.б.). Бу юнәлешләргә Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре бик яхшы булган абитуриентлар гына укырга керә ала. Минем әйтәсе килгән фикерем шул: хәзерге вакытта югары уку йортларына Бердәм дәүләт имтиханы белән генә алалар. Максатчан кабул итү буенча конкурс аерым булса да, баллары аз булган абитуриентлар укырга керә алмаска мөмкин.

Шул ук вакытта, «Татар теле һәм әдәбияты», «Татар мәктәбендә башлангыч класс укытучысы», «Музыка укытучысы» белгечлекләре буенча заявкалар юк. Алар буенча укыйсы килгән абитуриентларны безнең югары уку йортлары бик теләп кабул итәр иде. Ә бит халкыбызның телен, мәдәниятен, тарихын са-

клау һәм үстерү өчен шушы белгечлекләр кирәк. Шул ук вакытта бу белгечлекләр җитешми дип безгә урыннардан заявкалар килә тора.

Яшьләребезнең лаеклы алмаш булып үсүендә хөрмәтле татар теле мөгаллимнәренең өлеше гаять зур. Шунлыктан 10–13 августта татар теле һәм әдәбияты укытучыларының VI Бөтенроссия съездын уздырырга әзерләнәбез. Съезд кысаларында милли мәгариф юнәлешендәге җитди мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү, алдынгы тәҗрибә уртаклашу планлаштырыла. Съездга Россиянең барлык төбәкләреннән дә 200 татар теле һәм әдәбияты укытучысы, мәктәп җитәкчеләре чакырылды.

Моннан тыш, 2014 елның икенче яртыеллыгында Башкортостан Республикасында, Чувашстан Республикасында, Саратов өлкәсендә, Чиләбе өлкәсендә, Түбән Новгородта «Татар мәгарифе көннәрен» үткәрү планга кертелгән.

Югарыда әйткәннәрдән күренгәнчә, татар телен, мәдәниятен саклауга, үстерүгә юнәлдерелгән кызыклы проектларыбыз шактый күп. Аларны мөмкин кадәр нәтиҗәле итеп тормышка ашыру өчен, хөрмәтле яшьләребез, сезнең актив катнашуыгыз сорала. Шунлыктан Сезнең һәммәгезне дә бердәм уртак эшчәнлеккә чакырам һәм хезмәттәшлегебез нәтиҗәле булыр дип ышанам!

Бүгенге форумга җыелган делегатлар һәммәсе дә татар милләте өчен җан атып яшәүче яшьләр. Кадерле егетләр һәм кызлар, мин бүген Сезгә, дөньяның кайсы гына төбәгендә яшәүгә карамастан, татар теленә, мәдәниятенә карата битараф булмыйча, милли рухны саклау юнәлешендәге эшләрегез өчен ихлас рәхмәтемне җиткерәм. Халкыбыз сүзләре белән әйтсәк, «Бердәмлектә – көч!». Шунлыктан үзара элемтәләрнең һәрвакыт тотрыклы, нык булуын телим. Мондый алдынгы карашлы, заман белән бер адымда баручы актив татар яшьләре бар икән, татар теле, һичшиксез, яшәячәк!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт бик зур, Энгель Нәвапович! Сүз Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары **Хәлил Хәмит улы Шәйхетдиновка** бирелә.

**Хәлил ШӘЙХЕТДИНОВ:** Хәерле көн, хөрмәтле делегатлар, чакырылган кунаклар! Яшь ватандашларым һәм төрле илләрдән җыелган дусларым! Сезне чын күңелдән сәламлим! Татарстан барыбыз өчен дә уртак Ватаныбыз булып кала. Татарстан республикасы җитәкчелеге тарафыннан татар яшьләре белән эшләүгә җитди игътибар бирелә. Әлеге эшчәнлекне Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Идел», «Сәләт»

яшьләре үзәкләре уздыра. «Идел» үзәге уздырган чараларны әйтеп үтәргә кирәк: «Татар яшьләре көннәре», «Максат», «Дулкыннар» фестивальләре, «Яз гүзәле» һәм башка конкурслар.

Татарстанда өченче ел рәттән Россиянең төрле төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче ватандашларыбыз, 5000 сәләтле яшьләребез, катнашында халыкара белем бирү «Сәләт» форумы уздырыла. Ул киң колач җәйде, елдан ел катнашучылар саны арта бара.

Һичшиксез, барлык чараларны да күзәтеп, элемтәгә кереп, белешеп барабыз. Казанда нәтиҗәле эш алып барыла. Бу барлык чаралар мәдәният, милли гореф-гадәтләрне үстерүдә, Татарстаныбызны өйрәнүдә тирәнтен белем бирә. Шуны да ачыклап үтәргә кирәк. Ике яклы очрашулар һәрберебез өчен мөһим чараларның берсе. Татарстаннан читтә яшәүче ватандашларыбыз белән капма-каршы сөйләшү кыен мәсьәләләрне чишәргә, яшьләр сәясәтен, мәдәниятне, спорт мәсьәләләрен өйрәнергә ярдәм итә. Яшьләр сәясәте, спорт өлкәсендә эзлекле алып барылган чаралар Татарстан яшьләренең иҗтимагый хәлен яхшыртуга китерә.

Белүегезчә, Татарстан соңгы елларда яшьләр һәм спорт шәһәре буларак беренчелекне кулдан ычкындырмый. Бүгенге көндә Казан шәһәре Россиянең «спорт мәркәзе» буларак танылган. Моңа, билгеле, беренче чиратта 2013 елда XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада үткәрелү зур өлеш кертте. Универсиада мирасы спорт һәм шәһәр инфраструктурасын булдыруда әһәмиятле урын алып тора. Шул ук вакытта, республикабызда халыкара хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен яңа дәрәҗәгә күтәрә.

Безнең җыелма спорт командаларыбызның нәтиҗәле эшчәнлеге: «Зенит» ирләр волейбол командасы, «Динамо» хатын-кызлар командасы, «Ак барс» хоккей командасы, «Рубин» футбол командасы, «Уникс» баскетбол командасы һәм башка командалар Татарстанны Россия һәм дөньякүләм ярышларда танытуда зур этәргеч ясадылар.

Казанда 8–10 август көннәрендә дөньякүләм хайдайвинг буенча ярышлар уза. Бу яңа спорт төре. Узган ел Барселона шәһәрендә йөзү буенча дөнья чемпионаты узды. Анда ир-егетләр 27 метрлы вышкадан сикерәләр, ә хатын-кызлар 20 метрлыдан. Тагын искәртеп китәм, киләсе елга су төрләре буенча дөнья беренчелеге узачак, 2016 елда яшьләр кёрлинг буенча дөнья чемпионаты, 2018 елда футбол уены буенча дөнья чемпионаты узачак. Барыгызны да шушы чараларга чакырып калабыз. Безнең белән бергә карарга, безнең спортсменнарга көч биреп торырга килегез!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Ә хәзер сүзне Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе **Ринат Зиннур улы Закировка** бирәбез.

**Ринат ЗАКИРОВ:** Хәерле көн, кадерле дуслар, газиз милләттәшләр! Сезгә барыгызга да БТК исеменнән, аның 400дән артык оешмалары исеменнән кайнар сәламнәрне җиткерергә рөхсәт итегез. Бу безнең инде алтынчы форум һәм, шөкер, елдан-ел яңа яшьләр килгәнен күреп торабыз. Миңа күптән түгел сорау бирделәр: «Яшьләр эшен бик яхшы алып барган утыз яшенә җиткәннәргә нишләргә?» – дип сорадылар. 30га җиткәч беренче чиратта өйләнергә, кияүгә чыгарга, гаилә корырга кирәк, татар гаиләсе корырга кирәк, аннан соң инде безнең оешмалар күп, аларның лидерлары шулай ук олыгая бара, шушы лидерларны алыштырырлык лидерлар тәрбияләргә кирәк. Яшьләр бүген креатив, яшьләр дөньяны аңлый, күп аралаша, күп белә, сезгә чын лидер булып формалашырга бөтен мөмкинлекләр бар. Татарстанга килүләр күбәйде, бер ел эчендә генә уздырылган чараларны санап китсәк, бер кул бармаклары җитмәс иде: яшьләрне, хатын-кызларны, татар имамнарын җыйдык, һ.б. һ.б. Энгель Нәвапович та сөйләде, олимпиадалар, конкурслар, семинар һәм очрашулар – барсы да татар яшьләре формалашсын өчен оештырылган күпсанлы чаралар. Татарстан бүген, мөмкинлекләре зур булган дәүләт, шуңа үзебезнең яшьләребезне тиешле дәрәҗәдә, безгә ничек кирәк шулай формалаштырырга мөмкинлекләребез бар. Күп кенә регионнарда татар яшьләренең активлашуын күреп куанабыз. Безнең әле махсус оештырылган оешмалар юк иде, олылар оешмалары тирәсендә, алар канаты астында эшләүче оешмалар бар иде, ләкин үзләре теркәлеп, махсус оешма булып, яшьләр форумын конгресс канаты астыннан чыгарып, Россиянең Юстиция министрлыгында теркәргә кирәк дигән фикергә килдек. Форумның эше киңәя бара, илнең дә мөмкинлекләре арта бара, төрле грантлар бар, бу мөмкинлекләрне кулланыр өчен яшьләр оешмасын беркем дә ябып куя алмый торган, форматын үзгәртә алмый торган хәлгә китерергә кирәк. Киләчәктә БТЯФ татар яшьләренең дөньяда төп оешмасы булыр дигән фикердә калам мин.

Татар дөньясын яшәтү – татар конгрессының төп вазифасы. 20 ел узганнан соң инде авыз тутырып, татар дөньясы бар, дип әйтә алабыз. Дөньяның 37 илендә, Русиянең 70кә якын төбәгендә татар оешмалары эшли, башка милләт оешмалары белән чагыштырганда аларның артта сөйрәлгәнен күргәнем юк. Бу, әлбәттә, Татарстан Республикасының казанышы, Татарстан татар дөньясына тая-

нып, ә татар дөньясы Татарстан уңышлары белән горурланып яши. Элек Татарстан белән Казахстанны бутыйлар иде, хәзер андый нәрсә юк һәм дөньякүләм, транснациональ компанияләр Татарстан Президентына керү өчен чират торалар, чөнки Татарстан инвестицияләр кертү ягыннан да, һәм мөнәсәбәтләр кору ягыннан да бүген бик ышанычлы партнер булып санала, һәм шуңа инвестицияләр кертү илнең башка төбәкләре белән чагыштырганда уңышлырак бара. Татарстанның уңышлары татар дөньясы белән бик тыгыз бәйләнгән, шуңа күрә нинди генә төркемнәрне чакырмыйбыз, биредә татарның рухы береккән, татарның мәдәнияте, сәнгате Казанда, Татарстанда формалаша.

Ә инде Татар яшьләре форумы ничә еллардан бирле безнең проектларның үзәгендә. Форум барлыкка килгәннән соң Татарстан уку йортларына чит җирләрдән, төбәкләрдән татар яшьләрен кабул итүне башладык. Башта бик авыр барган эш хәзер шактый гына зур күләмдә башкарыла. Менә узган ел 500дән артык татар яшьләре безнең мәгариф министрлыгы белән бергә татар конгрессының махсус юлламаларын алып, Татарстан югары уку йортларына керделәр. Быел да ким булмас дип уйлыйм. Әгәр дә татар яшьләре Казанга килеп, шушы мохиттә укый икән, бу безнең шушы төбәкләрдә, чит илләрдә татар тормышын сүрелдермәскә зур этәргеч булыр дип ышанабыз. Яшьләр өчен Казанда уку зур мәртәбә генә түгел, зур байлыкка ия булу дип саныйбыз. Биредә Казанда белем алган, Кытайдан килеп, укып чыккан егетләрне күрдем. Инде Кытайда үз бизнесларын ачсалар да, нинди генә чара булмасын монда алар еш күренәләр, димәк, эшләре Татарстан белән бергә дәвам итә, без моңа бик шатбыз. Татарстан Президентының үзе барган җирләрдә, дөрес әйттеләр, татарлар белән очрашмыйча калганы юк, кайсы ил яисә төбәккә барса да, аның программасында иң төп чараларның берсе – шундагы милләттәшләр белән очрашу. Ул очрашуларда минем булганым бар, сөйләшү бик конкрет алып барыла. Татар яшьләрен Казан уку йортларында укыту – төп мәсьәләләрдән санала. Безгә хәзер, елапелап шалтыратучылар шактый: «Безгә укытучы җибәрегез, безгә имам җибәрегез, безгә клубка белгеч җибәрегез» – дип. Беркем беркемне җибәрмәячәк, сез аны аңлыйсыз. Менә сезнең кайсыгыз әти-әнисен калдырып, икенче җиргә, икенче төбәккә эшкә китеп барсын, беркемне дә көчләп җибәреп булмый.

**Рашат ЯКУПОВ:** Рәхмәт. Ә хәзер сүз Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе **Тәбрис Мөдәрис улы Яруллинга** бирелә.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Эшләнгән эшләр буенча хисап тотар-

га рөхсәт итегез. Исәнмесез, хөрмәтле Энгель Нәвапович, Ринат Зиннурович, Президиум, Форум делегатлары һәм кунаклар! Исәнмесез, татар яшьләре! Сезне барыгызны да яңадан Казанда күрүемә бик шатмын! Ике ел элек Форум идарәсен – Советны һәм мине рәис итеп сайлап, безгә ышаныч белдергән өчен зур рәхмәт! Без аны акларга һәм Форум эшен нәтиҗәле алып барырга тырыштык!

Хисапны башлаганчы, барыгызны да шушы көннәрдә узган Ураза гаете белән чын күңелдән котлыйм! Илебезгә иминлек, халкыбызга иманлы, туры юл һәм якты киләчәк насыйп булсын иде! Әлеге чарада беренче форумда катнашкан кешеләр дә бар. Моңа кадәр Форумны җитәкләгән, аякка бастырган өч рәис тә залда. Шул ук вакытта форумга, хәтта Казанга беренче тапкыр килүчеләр бар! Мин үзем дә сезнең белән беренче тапкыр III Форумда волонтер буларак таныштым.

Ун ел элек татар яшьләре оешмалары Татарстаннан читтә санаулы гына иде, булсалар да бик аз иделәр. Минем күз алдымда Казахстан яшьләре Форумда бер-берсен күреп, Казанда таныштылар, бүгенге көндә аларның илкүләм эшләп килүче оешмасы бар. «Мин монда ял итәргә килдем, миңа татар проблемалары кызык түгел» дигәннәр хәзер татар оешмаларын җитәкләп, зур чаралар үткәрә. Форум, сез, делегатлар, Татарстан, аларны илһамландырды. 2012 елда V Форумда Татарстан Президенты катнашып, аның дәрәҗәсен тагын да күтәрде һәм бу форум эшчәнлегенә бик уңай йогынты ясады. Безне барыбызны да Форум мәйданы берләштерә һәм ул үзенең төп миссиясен – татар яшьләрен берләштерү эшен уңышлы башкара дип саныйм.

Былтыр декабрьдә, ел ахырында Форумның йомгаклау утырышын уздырдык һәм без беркайчан да андый состав белән, география белән җыелганыбыз юк иде. Югыйсә, форумга ун ел булса да, без беренче тапкыр шундый зур составта җыелдык, нәтиҗәләр ясадык, планнар кордык. Шунысы да мөһим, форумның эшлекле командасы җыелды һәм чара буларак үзенең форматын аклады. Ни өчен аклады?

Татар яшьләре форумы – ул үзе чара буларак рәсми җитди мәйданчык. Хәзерге вакытта төрле төбәкләрдә һәм чит илләрдә шундый ук татар яшьләре форумнары уздырыла. Ульяновскида өченче тапкыр узды, Себер төбәге татар яшьләрен Новосибирск автономиясе җиденче тапкыр җыя. Чит илләрдә: Эстониядә икенче тапкыр, Европа татар яшьләре форумы былтыр узды, ел саен Литва татар яшьләре җыены була, Казахстанда Республикакүләм Сабантуй вакытында татар лидерлары җыела.

Форум – татар яшьләре өчен резолюцияләр, мөрәҗәгатьләр кабул итеп, татарларның мәнфәгатьләрен якларга, хокукларын тормышка ашырырга өйрәнә торган җирлек. Аны шуңа оештырырга кирәк тә. Төрле төбәкләрдә татар яшьләре форумнарын уздырганда рәсми вәкилләрнең чыгышы һәм концерт белән генә чикләнеп калмасыннар иде. Ә семинарлар, укулар, мастер-класслар оештырып, хокук яклауның заманча технологияләрен өйрәнеп, остаханәләр оештырсыннар иде. Ул безнең чорга, татар яшьләренә килешле һәм заманча форум булыр иде. Ун ел узганнан соң без дөньяда йөзгә якын татар яшьләре оешмалары бар дип әйтә алабыз.

Монысы форумның нинди булырга тиешлеге турында. Ләкин кая гына уздырылса да, Идел буе һәм Рәсәйнең Үзәк төбәкләренә шундый җыеннар җитми. Декабрьдә форум советыннан тәкъдим кертелде. Идел буенда иң актив татар оешмалары эшләп килә, димәк, безгә күчеп йөри торган төбәкара Идел буе җыены кирәк. Бер елны Ульянда, шуннан Самарада, Ижауда уздырып була моны. Идел буе форумы тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгы булыр иде.

Бу залда иң зур делегацияләрнең берсе Мәскәү шәһәреннән. Мәскәүдә 20гә якын татар яшьләре оешмалары бар: якташлар, спорт командалары, дини һәм иҗтимагый оешмалар. Якын тирәдәге төбәкләр белән бергә Мәскәүдә шулай ук бер җыен оештыру кирәк. Мәскәү яшьләре гел яңа проектлар тәкъдим итә. Аны тормышка ашыру юлларын эзли. Димәк, Мәскәү яшьләре форумы яңа проектлар мәйданы була алыр иде!

Форум эшчәнлегенә килгәндә, аны шартлы рәвештә үзебез өчен ике өлешкә бүләбез: беренчесе – рәсми өлеш, икенчесе – проектларны тормышка ашыру, чаралар уздыру. Рәсми өлешенә килгәндә, ике ел эчендә форумны Татарстанда теркәдек, счетыбызны ачтык, социаль челтәрләрдә үзебезнең төркемнәрне уңышлы гына алып барабыз, Спорт һәм яшьләр министрлыгы белән килешү төзедек, Мәдәният министрлыгы һәм аеруча Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бик уңышлы һәм нәтиҗәле эшләдек, һәрвакыт безгә игътибарлы булганнары өчен аларга татар яшьләре исеменнән рәхмәтемне белдерәм. Иң мөһим эшләребезнең берсе – татар яшьләре форумының Казан бүлеген ачу! Оператив рәвештә күп кенә мәсьәләләрне чишү өчен кулай форма булды. Яңа көчле команда формалашты.

Монда безнең күчмә утырышларны, инде әйтеп узылган йомгаклау утырышын атарга була, гомумән, бу ике елның географиясе: Европа татар яшьләре форумы – Рига (Латвия), Таллин (Эстония), Европа яшьләре форумнарында катнашу,

Азиядә – Җаек шәһәре (Казахстан) – Казахстан һәм Татарстан яшьләре форумы, Истанбулда төрки яшьләре форумы, Себер өлкәсендә – Новосибирск, Төмән.

Томск шәһәрендә күптән түгел Федераль Сабантуенда Урал һәм Себер татар яшьләре белән очраштык, Идел буенда Ульян һәм Ижау шәһәрләре, Мәскәүдә мөселман яшьләре форумында һәм ике тапкыр Уфада булдык.

Форумның географиясе киң, шуңа тәкъдим: ФОРУМНЫ ХАЛЫКАРА ОЕШМА БУЛАРАК ТЕРКӘРГӘ!

Форумның икенче өлеше – проектлар, чаралар дип әйтеп уздым. «Мин татарча сөйләшәм» акциясе яки МТС – иң популяр татар яшьләре чарасы. Ул ике элементтан тора: шәһәр мәдәнияте һәм татар теле. Аның эчтәлеге турында төгәлрәк мәгълүматны МТС секциясендә белә алачаксыз. Шуны гына әйтәм, МТСка киләсе елда 10 яшь тула. Төмән, Ижау, Җидепулат, Чаллы һәм башка күп кенә шәһәрләр безнең белән бергә аны елдан-ел оештырып килә. Мәскәү, Петербург, Ырынбур, Екатеринбург, Татарстанның Алабуга, Түбән Кама һәм Яшел Үзән шәһәрләре, безнең бу хәрәкәткә кушылыгыз! МТСның 10 яшенә, ким дигәндә Россиянең 10 шәһәрендә, бер үк вакытта, 26 апрель көнне, әлеге акцияне уздыру!

Казанның тарихи урыннары белән бәйле, икетеллелек проблемаларына багышланган «Татар дозор» квест-уены уза. Быел без аны Татарстандагы мәктәп укучылары өчен генә оештырабыз, уен формасы аларга бик ошый. Ләкин аның эчендә җитди идея яши: ике теллелекне, Казанның элмә такталарын тикшерү, биредәге тарихи урыннар белән бәйле. Шундый дозорлар кайсы төбәкләрдә оештырыла? Төмән, Түбән Кама, Иваново шәһәрләрендә уза. Аның максаты – укучы балаларда гражданлык инициативасы тәрбияләү. Быел без аңа фотомарафонны да өстәргә тырышачакбыз. Бу һәрберегез дә оештыра алырлык формат.

Безнең эшчәнлекнең бер юнәлеше – рухи тәрбия, дини юнәлеш. Соңгы вакытта дини яшьләрдә милли эшләргә сак карау күзәтелә. Шуңа форум дини һәм милли яшьләрне берләштерә торган чаралар оештырды: ике ел рәттән корбан ашы һәм читтә ифтар ашы уза. Ифтарны татар яшьләре өчен махсус Уфада ясадык. Башта 40 кеше жыймакчы идек, ләкин ул 100гә тулды. Бик матур итеп оештырдык, шуннан соң безнең бәйләнеш китте, чөнки моңарчы Башкортостанның күпсанлы делегацияләре Казанда уздырылган чараларда катнашып килә, ә Уфада җыелганыбыз юк иде. Ул чара безгә Башкортостан яшьләрен якынайтты, шушы чарадан соң без

татар балаларын лагерьга алып килдек. Бер төркем яшьләр «Мин татарча сөйләшәм»гә килеп китте. «Нәүрүз гүзәле» бәйгесе алдыннан педагогия университеты яшьләр активы белән күрештек. Шулай итеп, әхлакый чара аша Башкортостан яшьләре белән даими хезмәттәшлек башланып китте. Башкортостан татар яшьләре, сезгә мөрәҗәгать итәм: без сезнең белән дуслаштык һәм тиз генә безнең мәхәббәт сүрелмәячәк, сүз бирәм – котыла алмаячаксыз!

Форумның тагын бер уңышлы проекты – Казанның милли урыннарын танытуга юнәлтелгән, татар шәһәр милли костюмын һәм милли һөнәрчелекне популярлаштыручы «Тукай 100зе» һәм «Печән базары» чарасы. Быел без аны тагын бер зур чара – «Ялкын» журналы редакциясенең «Уку паркы» проекты белән берләштердек. Бу чараның технологиясен сез үзегезгә ала аласыз.

Барлык чараларны да ачып бетереп булмый. Регламент бар. Аларның барысын да интернет аша өйрәнеп, аларның стилистикасын, сценарийларын үзегезгә ала аласыз. Санап кына китәм: автохәрәкәт, велохәрәкәт, Хәтер көненә багышлап, ташландык татар зиратында өмә, опэнэйр «Татар Университеты», татар телендә төрле темаларга ачык һавада лекцияләр. Барлык чаралар турында интернетта, бездән дә, пленар утырыштан соң секция (проектлар мәктәбендә) тәгәлрәк сораулар биреп, белешә аласыз. Ләкин аларның барысын да берләштереп торган нәрсә – заманча иҗтимагый технологияләр куллану, openspace-ачык урам чаралары (татарлар өчен генә түгел, узып баручы теләсә кем, барлык кызыксынучылар өчен, чөнки без үзебезне таныта белергә тиеш).

Сүземне тәгәлләп, татар яшьләренә шуны әйтәсем килә: безне нәрсә берләштерә? Төрле диалектларда сөйләшәбез, төрле төбәкләрдә яшибез, мәдәният ягыннан да аермалыкларыбыз бар. Арабызда дини яшьләр дә, дин тотмаганнар да бар. Бездә бу эшләрдә принципиаль уртаклык юк. Безне барыбызны да нәрсә берләштерә соң? Минемчә, ул дәүләтчелек идеясе, ә Татарстан ул шушы идеянең бер формасы. Шуңа күрә без, татар яшьләре, Татарстанның уңышларына шатланып һәм, киресенчә, аның уңышсызлыкларын кире борып, аңа ярдәм итәргә тиеш. Яшәсен Татарстан Республикасы!

Хөрмәтле форум делегатлары, сүз **Рашат Якуповка,** БТЯФ советы әгъзасына бирелә.

**Рашат ЯКУПОВ:** Хәерле көн, хөрмәтле форум делегатлары, мөхтәрәм кунаклар!

Минем чыгышым, мөгаен, иң четерекле һәм еш күтәрелә торган мәсьәләләрнең берсе – Татарстандагы икетеллелеккә багышлана.

Бүген мин сезгә әлеге проблемага карата яшьләрнең нинди караш-та булырга тиешлеген җиткерергә тырышырмын.

Мәгълүм ки, рәсми рәвештә икетеллелек бездә инде егерме ике ел хөкем сөрә. Бу вакыт эчендә без нәрсәгә ирешә алдык? Берьяктан, үсеш-үзгәреш шактый зур: татар телен урамнарда күреп, ишетеп була, татарча игъланнар, юл күрсәткечләре бар. Ләкин икенче дәүләт теле белән чагыштырганда, татар теленең дәрәҗәсе әлегә шактый түбән. Моның сәбәбен эзләп, күп кеше хөкүмәткә гаеп тага, башкалары җәмгыять гаепле ди.

Чынлыкта татар теленең чын дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүе икеяклы тырышлыклардан тора. Әлбәттә, дәүләттән күп нәрсә тора: Президент, министрлар, депутатлар татарча сөйләшсә, тел мәсьәләсенә игътибарлы булса, оешмалар, төрле урындагы җитәкчеләр дә алардан үрнәк алырлар. Ләкин татар теле болай гына дәүләт дәрәҗәсенә менә дигән сүз түгел. Актив җәмгыять булган урында проблемалар даими рәвештә чишелә, тәрәккыят күзәтелә.

«Үзебез» хәрәкәте һәм татар яшьләре форумы җитәкчеләре һәрвакыт актив позициядә булырга өнди. Бу карашны безгә тормыш стиле буларак кабул итәргә тәкъдим итәм. Теләсә кайда, теләсә нинди күренешне, игъланны, продуктны һ.б. күрәбез икән, ә нигә ул татарча булырга тиеш түгел, дигән сорау бирик. Мәсәлән, Казан автобусларында язулар рус телендә генә. Моны күргәч, без мэриягә мөрәҗәгать иттек. Инде кайбер автобусларда татарча язулар барлыкка килә дә башлаган. Калганнарында да татарча булсын дип актив язсак, ансы да булыр, Аллаһ боерса! Язмасак, булмаячак. Бу принципны һәр урында тормышка ашырыйк: кибетләргә, сәүдә үзәкләренә кергәндә, анда татарча язылганмы, сатучылар татарча беләме, транспортта татарча игъланнар ясыйлармы, товар тышлыкларында татар теле урын алганмы һ.б. Оешма җитәкчелегенә хат язып җибәрү яки шалтырату берничә минут вакытны кына алачак, ә татар теле кулланышы бер адымга алга атлаячак.

Туган телебез үсешенең бер юнәлеше генә бар: аның кулланылыш даирәләре киңәергә тиеш. Тел прогресста булмый икән, димәк, аның регрессы, артка китеше башлана. Шуңа күрә безгә бөтен тырышлыкны татар телен төрле урыннарда, өлкәләрдә куллана башлауга юнәлтергә кирәк. Әйтик, театр өлкәсенә татар теле инде бер гасыр элек кереп урнашты. Ләкин хәзер, аеруча яшьләр арасында, кино өлкәсе популяррак. Димәк, Казанда татар кинотеатрын ачу мәсьәләсе актуаль. Чит ил фильмнарын татар теленә тәрҗемә итү һәм татар фильмнарын төшерү тел үсешенә шактый

уңай тәэсир ясаячак. Биредә утырган Татарстан җитәкчелеге бу мәсьәләне игътибарга алса иде.

Татар теленә мөнәсәбәт мәгариф өлкәсендә дә үсештә булырга тиеш. Хәзер, кызганычка каршы, тискәре юнәлеш сизелә. Безнең җәмгыятьнең һәм Татарстан хөкүмәтенең максаты Бердәм Дәүләт Имтиханын татар телендә дә тапшыру мөмкинлеге булдырып, татар телендә фәннәр укыту һәм югары белем алу мөмкинлеген торгызу булырга тиеш. Шуны аңлыйк: монсыз татар теле үсеше мөмкин булмаячак. Балалар бакчасы – мәктәп – университет чылбырын тулысы белән татар телендә укып чыгу мөмкинлеге – телебезнең үсеш гарантиясе.

Соңгы еллар дәвамында «Үзебез» хәрәкәте һәм Бөтендөнья татар яшьләре форумы тырышлыгы белән хөкүмәт даирәсенә, төрле оешмаларга, корпорацияләргә йөзләрчә хат җибәрелде. Аларның бер өлеше кабул ителеп, уңышлы адымнар күзәтелде, ләкин күпчелеге йә гадәти отпискалар, йә татар телен исәпкә алудан баш тартулар белән калды. Татарча язылган хатларга аерым чиновниклар тарафыннан хәтта «пишите на понятном языке» дигән сүзләр ишетелде. Бу хәлләрне безгә төзәтергә кирәк. Шуңа күрә мин форум исеменнән биредә утырган Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улына һәм Татарстан хөкүмәтенә шундый тәкъдим белән чыгам: җөмһүриятебездә икетеллелекне саклау һәм үстерү максатыннан, Дәүләт телләре турында канун нигезендә, Татарстан Президенты каршында икетеллелек мәсьәләләре буенча омбудсмен булдырырга һәм Татарстан хөкүмәте каршында иҗтимагый шура (общественный совет) оештырырга. Бу урыннарга отпискалар белән шөгыльләнгән чиновникларны түгел, ә икетеллелек өчен көрәшкән активистларны куярга тәкъдим итәм. Бу очракта дәүләт һәм җәмгыятебез татар телен чын дәүләт теле итү максатында, һичшиксез, уңышка ирешәчәк.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт! Сезнең алдыгызда хәзер философия фәннәре докторы, Санкт-Петербургтагы Европа университеты профессоры **Әлфрид Бостанов** чыгыш ясый.

**Әлфрид БОСТАНОВ:** Хөрмәтле милләттәшләр! Белгәнебезчә, татар тарихы, татар теле, татар әдәбияты гаять бай. Үткән гасырларда күп нәрсә булган: мәңгелеккә лаек горурлык та булган, оят һәм бик аянычлы, хәсрәтле хәлләр дә булган һәм бар. Милләтебезнең киләчәге булуына мин өметләнәм. Ул да бертөсле булмас, анда да төрле сәхифәләр булачак, бу сәхифәләрне тудырырга безгә кала.

Киләчәгебезне хәзрәти Нух галәйхис-сәлам төзегән Ковчег кыяфәтендә күз алдына китерик. Әйтик, без тиздән ерак һәм катлаулы сәфәргә җыенабыз. Милләтебезнең киләчәге булсын өчен нәрсә кирәк соң? Хәзрәти Нух шикелле, без менә хәзер ук сайларга тиеш, нәрсәләр белән Ковчегыбызны тутырабыз? Хәзер без, Аллага шөкер, матди яктан яхшы тәэмин ителгән: арбаларыбыз, фатирларыбыз, төрле айфон-майфоннар белән тормышыбыз тулы. Бәлки бу әйберләрне Ковчекка сыйдырыргадыр? Бу очракта киләчәгебез була аламы?

Узганнарыбыздан, бабаларыбыздан сакланып калган мирасыбыздан берәр нәрсә алыйкмы? Картларыбыз бик кыен вакытлар аша безнең өчен ана телебезне, пакь динебезне, халык иҗатын, әдәбиятын тапшырганнар. Димәк, безнең өчен бу изге әманәт, ягъни вакытлыча гына бирелгән байлык, без дә аны киләчәк буыннарга калдырырга бурычлы.

Аңлыйбызмы без? Хәзер бу Ковчекка сыймаган, кирәкми дип саналган әйберләрне киләчәктә беркайчан да табып булмас, мәңгелеккә югалыр, безне хәерче калдырыр, мәдәниятебезне гаять ярлыландырыр. Бу бик җитди сораулар һәм без аларга тиз арада җавап бирергә тиеш.

Хәер, киресенчә да була алмый. Әгәр без айфоннарны суга җибәреп, Ковчегыбызны тулысынча иске кулъязмалар, музей экспонатлары һәм сүзлекләр белән тутырсак, бу көймә бер генә кеше белән юлга китәр һәм милләтебезнең киләчәге бу очракта бөтенләй булмаячак. Кызганычка каршы. Фәүзия ханым Бәйрәмова бер тапкыр чыгыш ясаганда шундый фикер белән уртаклашты: татар милләте бары тик Идел-Урал буенда сакланачак, чөнки монда гына татар мәдәниятен үстерә торган факторлар бар. Үзем себер татары буларак, мин бу сүзләрне бик авыр кабул иттем, чөнки Татарстаннан башка күптөрле татар төбәкләре бар бит. Аларның үз тарихлары, үз телләре, мәдәни үзенчәлекләре барыбызга да мәгълүм. Күп уйладым мин бу турыда, күп сәфәр кылдым татар авылларына һәм, кызганыч ки, Фәүзия ханым белән килешергә туры килә. Моны әйтергә бик авыр һәм оят, чөнки күптәннән татар милләте төбәкләр белән көчле иде: Семипалат, Петропавловск-Кызылъяр, Күлҗә – барысы да татар җирләре иде. Хәтта Бохара XX гасыр башында татарлар яшәгән иң зур шәһәрләрнең берсе булып саналган. Совет чорында «татар империясе» юкка чыга башлады, чөнки аны берләштерүче факторлар бик аз иде. Мәсәлән, Казан галимнәре тарафыннан ел саен оештырылган фәнни экспедицияләр. Төрле татар төбәкләренә студентлар белән барып,

өлкәннәрдән милли байлыгыбызны өйрәнгәннәр, яңа татар китаплары да таратканнар. Хәзер хәл бик үзгәрде: күп очракта татар авылларында тарих һәм тел ягыннан кызыклы мәгълүмат табуы авыр, чөнки без телебез һәм тарихыбыз белән эләмтәне өзәбез. Шул ук вакытта, Казан университетында татар тарихын һәм әдәбиятын өйрәнүче студентларның саны да азая.

Төп соравыбызга кайтып, үзебездән сорыйсым килә: без милли мәгарифне, милли мәктәпне киләчәккә алабызмы, юкмы? Алмасак, балаларыбыз, һичшиксез, инглизчә, гарәпчә һәм урысча камил дәрәҗәдә белерләр, әмма безнең борынгы һәм яңа әдәбият мәңгелеккә югалыр һәм беркайчан да булмас.

Хәер, бу сорауларны бирергә бик җиңел. Әйткәнебезчә, бүгенге көндә татарларда барысы да бар, тик мәктәп кенә юк. Татарстанда алар нинди булса да бар әле, ә менә төбәкләрдә татар мәктәбе юк диярлек һәм анда Айнурлар, Алсулар русча гына сөйләшәләр, югары милли мәдәниятебезне бөтенләй белмиләр. Хәтта Ислам динебез дә бик тиз арада руслашкан һәм сәләфиләшкән. Беркем дә аңа игътибар итмәгән узган елларда, бүген инде бу процессны кире кагып булмый. Минемчә, бу руслаштыру да түгел, без үз йөзебезне югалтып, руслар була алмыйбыз, бәлки берничә буыннан соң гына. Ә милләтен югалткан кеше ул – маргинал. Рәсәйдә милли сәясәт булмаганга, мәмләкәтебез маргиналлар белән туп тулы...

Айфон булгач, милли хәрәкәт тә сүнә. Айфон гына түгел, әлбәттә, яңа фикер һәм яңа концепцияләр кирәк, чөнки һәрьяктан укымышлы татар яшьләренә гади национализм бик примитив тоела, хәзер ул беркемгә дә кирәк түгел. Татар халкына яңа зур фикерләрне, милли модельләрне тудырыр өчен, бәлки, Ковчег метафорасы файдалы булыр иде. Сайлыйк инде, дуслар, нәрсәне суга атабыз, нәрсәне үз балаларыбыз өчен сакларга тырышабыз?

Ә хәзер сезгә шигырь юллары укып үтәсем килә. Ул Мәрҗәни мәчетенең имамы Габделкаюм Кадыйров тарафыннан утызынчы елларда язылган:

### Милләттән сорау

Әй, милләтем, тәбарәк итеп телим синең яшәвеңне,
Тәрбияле балалардан ихтияр ит яшьләрне.
Әй, милләтем, бармы синдә тәрбияле аналар,
Тудыручы милләт өчен тәрбияле балалар?
Әй, милләтем, бармы синдә тәрбияле аталар?
Тәрбияле бала калса, гафу кылына хаталар.
Әй, милләтем, бармы синдә тәрбияле остазлар?

Аллаһ разый булсын аннан яхшылыкка кушканнар.
Әй, милләтем, бармы синдә тәрбияле шәкертләр,
Тәкъва галим булучылар, үз остазлары кебекләр?
Әй, милләтем, бармы синдә тәрбияле егетләр?
Тәрбияле егет булыр милләт хәдимнәр.
Әй, милләтем, бармы синдә төрле-төрле чәчәкләр?
Чәчәкләре нурлы булып бирсен татлы җимешләр.
Әй, милләтем, бармы синдә картаеш карт-карчыклар,
Зикер-тәсбих илә мәшгүл дога кылган карчыклар?
Әй, милләтем, бармы синдә дин юлында хәдимнәр?
Кем мөфти? Кем казый? Кем галим? Кем гасый?
Кем гадел? Кем залим? Кем мәзлүм? Кем гарип?
Кем багый? Кем гасый? Кем гакыл? Кем гафил?
Әй, милләтем, сорыйм синнән, бирең миңа җавабың,
Киләчәктә ни булсын язды микән каләмең?
Әй, милләтем, телим сиңа: Аллаһ кылсын дәвамың,
Тарих көненә язар өчен тиз җитештер җавабың.
Әй, милләтем, үтенәмен бераз мине вәгазьлә
Ни күрсәм дә күрәм инде, тәкъдирем шул әзәлдә.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт! Хөрмәтле форумда катнашучылар, эшебезне дәвам итәбез. Хәзер сүз Канада татарларының «Берлек» оешмасы әгъзасы **Әмир Җиһаншинга** бирелә.

**Әмир ҖИҺАНШИН:** Әссәләмәгаләйкүм вә рахматуллаһү вә бәрәкәтүһ, хөрмәтле Президиум, хөрмәтле делегатлар. 1997 елда мин беренче мәртәбә үзем генә Нью-Йорк шәһәренә килеп төштем, акчам да аз, инглиз телен дә яхшы белми идем, әле ул чакта мин бала идем. Билет сату кассасына килеп, бер егеттән, мин шул шәһәргә барам, миңа билет алырга ярдәм итегез, дип сорадым. Ул әйтә, 1500 доллар була, ди. Мин әйтәм, юк, минем ул кадәр акчам юк. Икенче кассага бардым – шул ук хәл. 1200 доллар сорадылар. Аннан соң, өченче кассага килдем: анда бер хатын паспортны алды да, русча әйтә, синең исемең кызык, милләтең нинди, ди. Мин горурланып, татар, дип әйттем. Ул шул ук секундта, шатланып әйтә, минем дә әбием татар иде, ди. Аннан миңа әбисе турында сөйли башлады. Аннан соң әйтә: мин сиңа хәзер иң арзан билет табам. 300 долларга миңа билет бирде. Шушы вакыйгада мораль бар: мин ярты сәгать эчендә Америкада якын туганы татар булган кешене таптым! Иң мөһиме шул – без күп, без сибелгән милләт. Татар милләтен белгән кеше безгә хөрмәт белән карый, шулай ук киләчәктә дә безгә бергә булырга кирәк.

Мин хәзер Канадада яшим, безнең диаспорада төрле кеше бар, шулай ук үзен татарга санаучы башка милләт кешесе дә бар. Быел Торонто Сабантуена 200дән артык кеше килде. Әрмән егете килде, миннән дә чистарак татарча сөйләшә, миннән дә күбрәк татар милләте турында белә.

Башка милләт безгә килсә, без каршы түгел, без шат, чөнки без беләбез, безгә килүче башка милләт кешесе ул татар милләтен хөрмәтли, ул татар милләте белән горурлана, ул татар милләтен үзенә үрнәк итеп саный, ул татар рухы белән, идентичность белән тормышын алып барырга тели. Узган ел безгә татар егете килде, әнисе татар, Африкадан. XXI гасырда төрле татар бар, ләкин татарның төсе мөһим түгел. Татарның рухы гына мөһим.

Чит илдә торган татарның приоритетлары күп: без Торонтода тулы комплектлы татар булып калырга телибез. Кем ул «тулы комплектлы татар»? Анда нәрсә булырга мөмкин? Мин белмим!

Ләкин без тырышабыз:

1) татар телен белергә;

2) татар тарихын белергә;

3) татар гореф-гадәтләрен белергә;

4) динебезне белергә;

5) татар ашларын белергә;

6) әти-әниеңне, олыларны хөрмәт итәргә;

7) милләт белән горурланып, үзебезне хөрмәт итәргә;

8) тырыш, уңган, укыган профессионал булырга;

9) татар гаиләсен корырга;

10) башка татарларга ярдәм итәргә;

11) үрнәк милләт булырга.

Шушы безнең рухыбыз Торонтода.

Ләкин ул безне тулы комплектлы татар ясыймы, юкмы мин белмим.

Булып чыгамы, юкмы – вакыт күрсәтер, ләкин тырышкан кеше беркайчан да үкенми. Без сибелгән милләт, ләкин без көчле, тырыш милләт, зур потенциаллы. Милләтсез кешенең рухы буш була. Торонто татарларының рухы бай, чөнки без татар милләтенең көчен беләбез. Без үрнәк милләт булырга телибез, ватаныбыздан еракта яшәсәк тә.

Торонто татарларына Татарстанда матур салынган биналар мөһим түгел, безгә кирәкми универсиада, безгә кирәкми суши, пицца, безгә кирәкми КамАЗ, безгә кирәкми «Рубин», безгә кирәкми анысы-монысы. Чит илдә торган татарларга иң матур туган телен, әткәм-әнкәмнең телен ишетү кирәк. Татарстанга килгәч, безгә та-

тар әбиләребез кирәк, ак яулыклардан намаз укып, бәлешләр пешереп, тынычлыкта оныкларын караучы, безгә кирәк сезнең тынычлык, сезнең сәламәтлек, безгә кирәк яшьләр лидерлары (егетләр дә, кызлар да кем татар милләтен алга алып баралар киләчәктә).

Татарстанда бер бина калмаса да, бер агач калмаса да, без барыбер ватанны әзрәк хөрмәт итмәячәкбез, әзрәк яратмаячакбыз. Татарстанны без гел яратып калабыз, авыр көннәрдә һәм җиңел чакта да.

1997 елда мин Нью-Йорк аэропортында борчылмадым да, дулкынланмадым да: чөнки мин белдем, ул мөһим түгел, иң мөһиме – үзеңнең кем икәнлегеңне белү. Мин үземнең кем икәнлегемне беләидем. Мин – татар егете, татар ашлары ашап, гореф-гадәтләр белән, татар-мөселман гаиләсендә үстем. Мин татар булып Америкага килдем, мин татар булып китәчәкмен дә, иң зур бәхет шушы, үзеңнең идентичностьне белеп, хөрмәт итеп үсәргә һәм аннан соң аны тырышып саклап, үз балаларыңа бирергә. Бик зур рәхмәт миңа сүз биргән өчен!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт үзеңә, Әмир! Сүз тарих фәннәре кандидаты **Айрат Фәйзрахмановка** бирелә. Рәхим итегез.

**Айрат ФӘЙЗРАХМАНОВ:** 6 нчы тапкыр Бөтендөнья татар яшьләре форумын уздыру өчен Республика, БТК җитәкчелегенә олы рәхмәтләр әйтәсе килә. Бу көннәрдә без милләтне борчыган мәсьәләләрне күтәреп, аларны чишү юлларын эзлибез. Чөнки без – милләтнең киләчәге, хәзерге көне дә. Бу барыбызга да телебезне һәм мәдәниятебезне үстерүдә зур җаваплылык йөкли. Һәм безнең, татар яшьләренең, һичшиксез, үз фикере, үз позициясе бар.

Алдагы сүзем Татарстан Республикасы Президенты Институты турында булса да, чыгышта бу темага кагылышлы башка иҗтимагый-сәяси сорауларга тукталып калмыйча булмас. Һичшиксез, Татарстан Республикасының хәзерге сәяси һәм икътисадый алгарышы татар халкының үсеше, бердәмлеге өчен иң нык таяныч. Татарстан үссә, татар халкын зур уңышлар көтә.

Үз чиратында, Республиканың тотрыклы үсешенең хокукый нигезе – Татарстан һәм Россия Федерациясе конституцияләренең тулы үтәлеше, Татарстан һәм Россия хакимият органнары арасында вәкаләтләр бүлешү турындагы шартнамә. Алар татар халкының үсешенә мөмкинлекләр ача.

Белгәнебезчә, халык тарафыннан кабул ителгән Татарстан Конституциясе һәм Россия Конституциясе (5 енче маддә) буенча Республикабыз дәүләт булып тора. Һәм Татарстанның һәр дәүләткә

хас булган сыйфатлары бар: мөстәкыйль хакимият органнары, хокук системасы. Президент атамасы – нәкъ шундый сыйфат. Безне, татар халкын, бу атамадан мәхрүм итү төп дәүләтчелек сыйфатын алып ташлау дигән сүз.

Шуны да онытмаска кирәк: 7 ел элек Россия һәм Татарстанның дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турындагы икенче шартнамә төзелде һәм хәзерге вакытта Татарстан федераль үзәк белән аерым шартнамә нигезендә федератив мөнәбәтләр урнаштырган бердәнбер төбәк булып кала. Шартнамә Татарстан Конституциясен, үзенчәлекләрен, 1994 елгы шартнамәне һәм 1992 елда уздырылган үзбилгеләнү референдумын таный. Икътисадый яктан Шартнамә тотрыклы үсеш өчен җитди алшартлар ачты һәм бу хәзерге алгарышның хокукый нигезе булып тора.

Анда Республиканың халыкара багланышлары дәрәҗәсе, милләттәшләр белән эшләү зарурлыгы, Татарстанның тарихи, мәдәни, икътисадый үзенчәлекләре булуы раслана. Шартнамә – Россия дәүләт органнары тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри федераль закон ул. Документка Россия һәм Татарстан президентлары кул куйган. Димәк, федераль үзәк Татарстанның Президенты булуын таный.

Бу исә, Татарстанда президент институтын саклауга бер нигезләмә булырга мөмкин. Бу исем халык референдумы белән булдырылды. Демократия шартларында халык фикере белән санлашмауның хокукый нигезе була алмый.

Һәм без, яшьләр, милләтнең киләчәге, бу әйберләрне белергә, аңларга һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә тиеш. Аллага шөкер, барыбыз да диярлек югары белемле, барыбыз да иҗтимагый активист. Һәм үз җирлегебездә андый аңлату эшләрен алып бару – ул безнең миссиябез, безнең җаваплылыгыбыз.

Демократия шартларында Россия, һичшиксез, федерация булып калачак. Илнең территориясе гаять зур һәм анда төбәк үзенчәлекләрен бер генә стандартка, тәртипкә салып булмый. Һәм алга таба федераль үзәк Татарстанны ишетеп, аерым бер Шартнамә нигезендә, Татарстанннның Президент институтын саклап калырга мөмкинлек тудырыр дип ышанабыз.

Кемдер әйтер: бу алда әйтелгән фикерне яшьләргә өстән тәкъдим иттеләр, дип. Әйе, әлбәттә, без өлкәннәр белән киңәшләшеп эшлибез. Әмма бөтен җаваплылык белән әйтәбез: бу – татар яшьләренең мөстәкыйль фикере.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт, Айрат. Ә хәзер сүз Мәскәү татар яшьләре оешмалары шурасы **Эмиль Фәйзуллинга** бирелә.

**Эмиль ФӘЙЗУЛЛИН:** Исәнмесез, кадерле дуслар! Мәскәүдән барыгызга да кайнар сәламнәр җиткерәм! Беренчедән, алтынчы Бөтендөнья татар яшьләре форумын оештыручыларга рәхмәт әйтәсем килә. Бу очрашу безнең өчен зур бәйрәм, зур сөенеч!

Минем доклад Мәскәүдә һәм зур шәһәрләрдә милләтебезнең мирасын, гореф-гадәтләрен, телен, мәдәниятен саклау һәм үсеш проблемалары, аларны чишү турында. Мәскәүдә 100 меңнән артык татар яшьләре яши һәм, билгеле, ел саен төрле төбәкләрдән яңа татар яшьләре агыла (югары белем алу өчен яки эш эзләп, яшәргә). Алар 14 миллион шәһәр халкы арасында таралып яши.

Барыбызга да таныш мәкаль: «Теле барның – иле бар». Без аны «Теле барның – милләте бар» дип аңлыйбыз. Шуңа күрә күптән түгел Мәскәүдә яшьләреннән татар телен ни дәрәҗәдә белүләре турында сораштык. Сораштыру анализы буенча 36%ы телне яхшы беләбез дип җавап бирде, 24% – яхшы аңлый һәм бераз сөйләшә, 22% – бераз аңлый һәм 18% бер дә белми. Димәк, 40% (!) туган телен белми дип санап була.

Аларның:

50%ы – чит илләрдән килгән яшьләр;

41%ы – Мәскәүдә туып-үскән яшьләр;

41%ы – Башкортостаннан;

39%ы – Түбән Новгород, Ульян, Оренбург, Самара, Саратов, Пенза өлкәләреннән;

13%ы – Татарстаннан.

Шулай ук Мәскәүдә татар яшьләренең Duslar.ru социаль челтәрендә үткәрелгән сораштыру бу анализ белән тәңгәл. Интернет сораштыруда 50 мең кеше катнашты. «Нинди сәбәп аркасында татар телен белмисез?» дигән сорау да бирелде. Иң популяр җаваплар: «Әти-әниләр сөйләшмәде», «Мәктәптә укытмадылар». Димәк, милләтне юкка чыгару проблемасы, иң элек, һәрберебезнең гаиләсеннән килә. Әгәр гаиләләрдә татар телендә сөйләшмәсәк, милләтебезне югалтабыз.

Икенче тел саклау урыны ул – мәктәп. Билгеле, татар телен «яхшы» белүчеләр арасында грамматиканы белгәннәре бик сирәк очрый. Бүгенге көндә аны күбесенчә, әлбәттә, мәктәптә генә өйрәнеп була. Әмма ләкин мәктәпләрдә дә татар телен укыту сәгатьләре елдан-ел артып бармый, киресенчә, кими, бетә бара.

Тагын бер мәсьәлә: Рәсәйнең Мәдәният министры В. Мединский, тирән анализ үткәрмичә, мәктәпләрдә башка милләт телләре дәресләрен киметеп, рус теленең дәрәҗәсен арттырырга дип хөкүмәткә тәкъдим итә. Шул чакта, йомшак әйткәндә, дуслар, уйланырга кирәк.

Һәрвакыт туган телен белгән яшьләр рус телен дә яхшы беләләр иде. Чөнки туган телен, ике телне белгән кеше ул сәләтле. Шуңа күрә татар теле, әдәбияты дәресләренең санын киресенчә арттырырга кирәк мәктәптә, иҗтимагый оешмаларда аерым дәресләр оештырып! Һәм без бу проблеманы йомгаклап, яраклы тәкъдимне резолюциягә кертергә тиешбез, хат язарга кирәк министрга, хөкүмәткә.

Шул ук сораштыру буенча татар яшьләренең 80 %ының, кайдан гына килсә дә, үз телен белергә ниятләре бар. Монысы әлбәттә шатлыклы хәбәр.

Гореф-гадәтләр, мәдәниятне саклау турында да берничә сүз әйтеп үтәргә иде. Хәзерге көндә, мәгълүмат гасырында, зур шәһәрләрдә төрле чаралар турында белеп була: интернет аша, метрода барганда. Алар билгеле, кызыгырлык эчтәлекләре белән безнең игътибарыбызны тартып, күңелне дулкынландыра. Шул чаралар, ят биюләр, җырлар милләтебездән аерып һәм акчаны суырып, башка милләтләргә әйләндерә.

Һичшиксез, татар яшьләрен бер урында туплау ул зур мәсьәлә! Ә зур шәһәрләрдә, билгеле, яшьләрнең энергиясе күп, алар бик актив. Аларның энергиясен дөрес тарафка юнәлтү иҗтимагый оешмаларның бурычы.

Кайбер чакта татарлар оештырган чарага киләсең, анда да шундый хәл. Татар җырларын, татарча сөйләшүләрне бик сирәк ишетеп була. Шуңа күрә, билгеле, яшьләрне бер урында туплау ул милләтнең проблемасын яртылаш чишү. Чаралар кызыклы рәвештә үтәргә тиеш. Ягъни проектларны оештырганда алар да шулай ук кызыгырлык булып, башка чараларга альтернатива булып торырга тиеш. Ә татар булуы «модно» һәм «круто» дигән сыйфатларга туры килсен. Ул чакта безнең чаралар яшьләр белән байый һәм кызыклы булачак.

Мәсәлән, Мәскәүдә беренче тапкыр ачык һавада үткән, яшьләрне берләштергән һәм мәдәниятебезне саклый торган «Татфест» дигән проект тормышка ашты. Аның турында тулысынча безнең кызлар, егетләр секция вакытында сөйләр әле, тыңларсыз, сораулар бирерсез. Мәскәүнең Асадулла йортында һәрвакыт, сикәлтәле хәлләргә карамастан, яшьләр тормышының, чараларның байлыгы арта. Ә чараларның дәрәҗәсен тагын да күтәрер өчен, аның санын арттыру өчен яшьләр Советы астында 2014 елда «Хәрәкәт» дигән проектлар конкурсы оештырылды. Аның бүләк тапшыру кичәсен Мәскәү татар яшьләре көне белән бәйләп үткәрергә исәп һәм теләк бар ел ахырында.

Һичшиксез, бүгенге көндә милләтне саклау тарафына юнәлтелгән күп эш башкарыла, Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов кайда гына барса да татарлар белән очраша. Илнең күп почмакларында Сабантуйлар үтә, күбесе Татарстан ярдәме белән. Шул чакта безгә барыбызга да кушылып ярдәм итәргә кирәк. Безнең ваемсызлык, башка милләтләргә охшау ассимиляциянең үсеш темпына турыдан-туры пропорциональ.

Һәм академик Нигъмәтулин әйтүе буенча, «җәмгыятьтә ачыклык, аңлаешлык туарга тиеш». Әгәр дөрес аңлаешлык туса, ул үз вакытында хөкүмәткә һәм башка кирәк җирләргә диффузировать итә, барып җитә. Шуңа күрә мин барыбызга да шушы форумда вакытны файдалы итеп үткәреп, секцияләрдә дөрес нәтиҗәләргә килеп, әйтелгән фикерләрнең, проектларның тормышка ашуын телим. Һәм Мәскәүдән килгән берничә фикерне дә ишеттерергә телим.

1. Мәскәүдә, сез роликта күрдегез, күптөрле чаралар үтә, әмма Мәскәүдә яшәгән күп кенә татар яшьләре алар турында бернәрсә дә белми. Шул ук вакытта аларның әти-әниләре, әби-бабайлары ТНВ каналын карый. Шул каналда безнең чаралар турында аена бер мәртәбә тапшыру чыкса, бик файдалы булыр иде. Без материалларны җибәрергә әзер.

2. Ике елга бер Мәскәүгә Камал театры бик матур гастрольләре белән килә. Әлбәттә, шул хәтле татарлар яшәгән зур шәһәрдә Камал театрының спектакльләрен ешрак күрәсе килә. Шуңа күрә театрның һәр елны килүен сорыйбыз.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт, Эмиль. Ә хәзер сүз Кытай татар яшьләре лидеры **Рифкат Фәхретдиновка** бирелә.

**Рифкат ФӘХРЕТДИНОВ:** Әссәләмәгәләйкүм, кадерле милләттәшләр, дуслар, хөрмәтле җитәкчеләр! Сезгә Кытайда яшәүче 5000 нән артык горур татар халкының кайнар, сагышлы сәламнәрен җиткерергә рөхсәт итегез. Дөньяда татар аягы тимәгән, ул барып җитә алмаган почмак юк. XX гасырның төрле тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә язмыш җилләре безнең ата-бабаларыбызны туган җирләреннән аерып, үз динен, үз телен саклап калу максатында Кытай иленә барып урнашырга мәҗбүр иткән. Кая гына барып чыкса да, җирле халык белән уртак тел табып, дус һәм тату яши ул татар. Нинди генә шартларда да үз телен, гореф-гадәтләрен, динен саклап калырга тырыша. Татар халкының шанлы, данлы тарихына карасак, һәр җирдә булган кебек, безнең бабаларыбыз да Кытай дәүләтенең үзләре килеп урнашкан төбәкләрендә иң әүвәл мәчет-мәдрәсәләр төзеп, татар телендә мәктәпләр ачкан, татарлар-

ны гына түгел, шул төбәктәге уйгыр, казакъ, үзбәк кебек тугандаш мөселман халыкларны да укыткан. Аларның «татар халкы ул – мәдәният таратучы, белем бирүче халык» дигән мактауларга ирешүе бер дә гаҗәп нәрсә түгелдер!

Кытайда кайчандыр бистәләр, мәхәлләләр оештырып яшәгән халкыбыз, күченеп китүләр аркасында, бүген биш меңнән аз гына күбрәк. Аллага шөкер, инде күп еллардан бирле татарлар тупланып яшәгән Өремче, Голҗа, Чәүчәк шәһәрләрендә һәм бердән-бер милли татар авылы булган Чишмә авылында татар оешмалары бик актив эшләп килә. Ел саен Кытай хөкүмәте ярдәме белән Сабантуе бәйрәмнәрен гөрләтеп уздырабыз. Соңгы елларда бу бәйрәмнәргә тагын да ямь өстәп, Татарстан хөкүмәте, Бөтендөнья татар конгрессы дәүләт вәкилләрен һәм сәнгать әһелләрен юллый! Без моның өчендә бик рәхмәтле!

Сабантуйлардан тыш, һәр елны Тукай кичәсен үткәрү, дини һәм рәсми бәйрәмнәрне бергә җыелып уздыру, туган телебездә концертлар оештыру матур гадәткә әверелде. Казаннан килгән һәр гәҗит-журнал, һәр китап кулдан-кулга күчеп укыла, һәр кассета һәм диск өйдән-өйгә күчеп тыңлана һәм карала. Без, Кытайга сибелгән татарлар, бүгенге көндә миллиардтан артык кытай, миллионлаган уйгыр, казакъ һәм башка халыклар арасында утрау-утрау, төркем-төркем яшәсәк тә, үз татарлыгыбызны югалтмыйча, бер-беребезнең барлыгын тоеп, үзара теләктәш булып, татар булуыбыз белән горурланып яшибез. Ата-бабаларыбыздан мирас булып калган динебезне, телебезне, гореф-гадәтләребезне сакларга тырышабыз. Ләкин ничек кенә булмасын, безгә рухи байлык җитми, үзегез дә аңлыйсыздыр, Кабан күлендәге тамчы хәлендә булган без татарлар өчен болай гына милләтне саклау бик тә авыр. Татар мәдәниятен һәм телен сакларга омтылыш сизелерлек булса да, Кытайдагы татарлар, теләсәң дә теләмәсәң дә, ассимиляция процессына катнашып китәләр. Без даими рәвештә бер (үз, туган, татар) мәдәни һәм тел даирәсеннән башка (чит, бөтенләй ят, кытай) даирәгә күчү халәтендә яшәргә мәҗбүрбез. Татар телен белүнең кулай дәрәҗәсе (грамматик яктан дөреслек, сөйләү рәвеше, тел чараларын сайлау), теге яки бу дәрәҗәдә татар көнкүреше, мәдәни йолалары һәм әхлакый кыйммәтләрне саклау Кытайдагы татар диаспорасының өлкән буын вәкилләренә хас. Ә мәктәпләрдә, көллиятләрдә һәм университетларда белем алучы яшь буын күбрәк кытай телендә аралаша һәм бик тиз туган телен оныта. Татар телен куллана торган төп урын – көнкүреш. Үз этник диаспорасы вәкилләре белән гаиләдә сөйләшү һәм башка рәсми булмаган ара-

лашулар. Татар этник төркеме эчендә, гаиләдә татар телендә аралашалар.

Кытайдагы татарларның барлык вәкилләре татар телен, алдагы буыннарга караганда, начаррак белүләрен билгеләп үтәләр. Балаларының тел онытулары артканнан арта бара. Балалар кытай телендә сөйләшергә күнегеп китә алмаган әби һәм бабайлары белән, кагыйдә буларак, татарча, дөресрәге уйгурча-татарча аралашырга тырышалар. Шулай да балаларны татар телен өйрәнергә кызыксындыру өчен бу гына җитми. Бүгенге көндә Кытайдагы татарлар телне һәм мәдәниятне саклап калу турында гына уйламый, алар үз балаларына татар телен өйрәтү хакында да борчылалар. Әлбәттә, Кытайда татар балалары шөгыльләнә торган татар шимбә мәктәпләре бар, ләкин бу проблеманы хәл итеп бетерми.

Кытай татарларының мөхтәрәм аксакалы, танылган җәмәгать эшлеклесе Ильяр ага Габитовның юл ачуы аркасында, Кытай татарлары белән Татарстан арасы тагын да якынайды. 2005 елда исә Кытайда яшәүче татарлар тарихында зур үзгәреш булды! Беренче тапкыр 30 дан артык татар кыз-егетләребез тарихи ватаныбыз – Казаныбызга укырга килде! 2009 һәм 2011 елларда тагын 3 төркем яшьләр Татарстанның төрле югары уку йортларына укырга керде! Безгә бу зур тарихи мөмкинлекне биргән мөхтәрәм Президентыбызга, Татарстан хөкүмәтенә, Бөтендөнья татар конгрессына чиксез рәхмәтләребезне җиткерәбез! Барлык Кытайда яшәүче татарлар Сезгә рәхмәт укый, исәнлек вә саулыгыгыз өчен дога кыла. Бу вакыйга Кытай татарларының мәдәниятен, телен саклап калуга зур этәргеч бирде, киләчәккә өметләр уятты! Узган елларда тәүге тапкыр укуга килгән яшьләребез яхшы нәтиҗәдә укуларын тәмамлады! Алар туган якларына кайтып та югалып калмады, кемдер укытучы булып эшләсә, кемдер тәрҗемәче булып эшли. Кайберләре Кытай иленең хәзерге вакытта дөнья икътисады, сәүдә мөмкинлекләреннән файдаланып, татар исемнәре кушылган компанияләр ачып, икътисад өлкәсендә танылырга тырыша һәм шуның аркылы Кытайда яшәүче татарларның мәдәниятен танытуга ярдәм итә! Тарихи ватаныбызда калучылар саны да шактый. Хәзерге көндә Казанда укуын тәмамлаган 8 егет һәм кыз гаилә корып, Татарстан белән кода-кодагыйлар булып, Казанда төпләнеп калдылар. Чын татар гаиләсен арттыруда без дә өлеш кертеп өлгердек. Ата-бабаларыбыз ватанына безне татар рухы алып кайтты.

Казанга каныбыз тарта, җаныбыз тарта! Әлбәттә, тарихыбызга карасак, мактанырлык горурлыгыбыз күп! Безнең халык те-

лен, динен, милли үзаңын, гореф-гадәтләрен саклап һәм үстереп килә алуы белән бәхетле. Бүгенге көндә дә Татарстан хөкүмәте, Бөтендөнья татар конгрессының дөньякүләм сибелгән татар вәкилләрен Казанга җыеп, фикер алышып, милләтебез киләчәге өчен эшләргә мөмкинлекләр бирүе моның ачык мисалы булып тора! Безнең әле милләтебез өчен эшлисе эшләребез шактый күп! Аның өчен безгә бердәмлек, иттифаклык кирәк! Ил-йортта тынычлык һәм тәртип булсын өчен бердәмлеккә һәм дуслыкка ни җитә! Без моннан соң да бөек татар халкының вәкилләре булып яшәргә телибез. Телебезне, моңыбызны, гореф-гадәтләребезне моңа кадәр саклadык, моннан соң да сакларбыз, Иншаллаһ!

Кытайда яшәүче татарлар исеменнән шуны әйтәсем килә. Кадерле милләттәшләр, дуслар, дөньяның кайсы почмагында гына яшәсәк тә, татар булып калыйк. Татарча сөйләшик! Чөнки тел югалса, милләт югала. Халкыбызның данлыклы киләчәге безнең кулыбызда! Бердәм булыйк! Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт, Рифкат. Ә хәзер «Түбән Новгород өлкәсендәге татар оешмасы эшчәнлеге, сәләтле укучыларны укырга кертү һәм татар авылларын җанландыру» темасы белән **Рамил Нәҗметдинов** чыгыш ясый.

**Рамил НӘҖМЕТДИНОВ:** Хәерле көн, хөрмәтле якташлар. Без бик шат бу форумда Түбән Новгород өлкәсендә яшәүче мишәр татарларын тәкъдим итәргә. Дөньяда безне «Сергач мишәрләре» дип йөртәләр. Безнең уңышлар һәм юлыбызда очраган авырлыклар турында сөйлисем килә. Фотографияләрдә эшебезнең нәтиҗәләрен күзәтергә була.

Түбән Новгород өлкәсендә татарлар озак вакыт яшиләр һәм Россия Федерациясенең бу субъектында халык саны буенча икенче урында торалар. Сергач җире зур булмаган регион, ләкин татар мәдәнияте, сәнгатенә, спорт үсешенә бик күп илләргә билгеле талантлы кешеләрне тәрбияләде. Алар: беренче татар Язучылар Союзы рәисе Кави Нәҗми, аның энесе, шахмат буенча халыкара гроссмейстер Рәшит Нәҗметдинов, татар халык артистлары Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Халидә Бигичева, актер Марат Бәшәров, тренерлар һәм спортсменнар: Зиннәтулла Хәйдәрович Билялетдинов, Фәрхәд Әхәтович Мустафин, Алия Мостафина, Шиазам Сафин, Ринат Саярович һәм Данияр Билалетдиновлар, Марат Измайлов, Марат Сафин һәм башкалар.

Шулай да авырлыклар гасырлар чигендә барлыкка килгән. Алар авылда яшәүче халыкны җитди кыскартуга китерде. Бу авырлыкларның күбесе әлеге көннәрдә дә сакланган. Мәсәлән,

мәктәпләр ябылу. Авыл мәктәбенең ябылуы – авылның үлүе дигән сүз. Интеллектуаль һәм технологик эшләр, авылларны төзекләндерү өчен финанс юклыгы, бердәм карашларның юклыгы – безнең якташлар да мондый авырлыклар белән бөтен Россиядә очрашалар.

Авылларның үлүе белән килешеп тә булыр иде. Әйе, авылда даими яшәүче кешеләр аз кала. Ләкин шул ук вакытта авылларга кайтучылар да бар бит әле. Бер ел эчендә кайсына берничә мең кеше кайта, ә кайсы авылларга унар мең дә. Шуңа күрә ресурслар бар, алардан файдаланырга кирәк. Бу уңайдан авылларны саклау өчен иң актив көрәшүчеләрнең зур өлеше – авыллардан чыккан шәһәрләрдә яшәүчеләр.

Авыллар тормышындагы үзгәрешләр шул чорда башланды. Кешеләр үзләре уртак тырышлык белән эшкә керештеләр. Нәтиҗәдә авыллар яшәрде. Мәсәлән, Красный авылында иң борынгы таш мәчетне төзәтү эшләре башланды. Ул мәчет 1902 елда корылган. Тагын бер мәртәбә басым ясыйм: бу эш халык акчасына эшләнгән.

Хәзерге заманда иң әһәмиятлесе: традицияләргә карап, яңа буынны тәрбияләү. Шуңа күрә татар мәктәпләре һәм татар класслары ябылу проблемасы бик үткен булып тора. Бу проблеманы мәдрәсәләр ачу хәл итте. Бүгенге көндә Түбән Новгород өлкәсендәге һәр авылда дәүләт рөхсәте белән мәдрәсә ачылган. Мәдрәсәләрдә Ислам диненнән башка татар теле дәресләре мәҗбүри, чөнки татар теле – традицияләр белән тәрбияләүнең нигезе. Кеше балачактан белем алырга ятарырга тиеш. Шул уңайдан программа эшләнгән. Ул программа буенча балалар татар һәм дөнья мәдәниятләре белән таныша, фәнни һәм дискуссион клублар, спорт көннәре үткәрелә. Олырак буыннар өчен Мәскәү университетлары белән килешүләр төзелгән. Алар нигезендә сәләтле укучылар югары уку йортларына керә алалар. Безнеңчә, сәләтле балаларга бу киләчәк тормышларында зур ярдәм була.

Моннан тыш, яшьләр тарихи эзләү эшләрендә актив катнаша. Шулай да без үз тарихыбызны бик аз беләбез. Без тарихны өйрәнүне XX гасырдан башладык. Бу вакытта да анда ак битләр җитәрлек иде. Берничә ел элек без Бөек Ватан сугышында катнашучыларның язмаларын туплый башладык. Ул язмада Түбән Новгородтан чыккан һәм сугыш вакытында югалган якташларыбыз да байтак иде. Бүген дә бу эш дәвам итә. Күп солдатларның һәм офицерларның күмелгән урыннары табылды. Аларның исемнәре кабер ташларына язылган.

Әйтеп уздым инде, безнең авылларда күренекле урыннар бар, алар арасында музейлар да күп. Музейларны берләштерү йөзеннән программа ясадык. Экскурсион программа шул күренекле урыннарны күрсәтә. Быел ул авылга кайткан мәктәп укучылары өчен үткәрелә, киләчәк елларда аны киңәйтергә ниятебез бар.

Нәтиҗәләр буенча, без әйтә алабыз: Түбән Новгород өлкәсенең татар авыллары яңа форматка килә һәм яши. Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Бергә булыйк, бердәм булыйк!

БҮЛӘКЛӘҮ

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Хөрмәтле форумда катнашучылар! Шуның белән безнең пленар утырышның беренче өлеше тәмамлана. Тагын бер кат исегезгә төшерәм: сезгә бирелгән материаллар арасында форумның резолюция проекты бар, форум дәвамында резолюциягә кертергә кирәк дип санаган фикерләрегезне язма рәвештә оештыру комитетына җибәрә барсагыз иде.

Хөрмәтле форумда катнашучылар, без хәзер «Казан» милли-мәдәни үзәгенә барачакбыз. Төшке аштан соң без эшебезне өч секциягә бүленеп алып барырбыз. Хәзер төшке ашка тәнәфес игълан итәм. Автобуслар көтеп тора. Рәхим итегез.

## ПЛЕНАР УТЫРЫШНЫҢ ДӘВАМЫ

*(Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры)*

**03.08.2014**

*Чыгыш ясаучылар:*

*1. Ренат **ХАРИСОВ** – «ШТК – Татарская лига КВН» оешмасы җитәкчесе, «Шаяннар һәм тапкырлар клубы» хәрәкәте.*

*2. Гөлназ **БӘДРЕТДИН** – Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе урынбасары.*

*3. Нигина **ӘХМӘДУЛЛИНА** – Бөтендөнья татар яшьләре форумының җаваплы сәркатибе (темасы: «Татарстан Республикасына татар яшьләре күченү»).*

*4. Илһам **ГАЙНЕТДИНОВ** – Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (темасы: «Балтач районында татар яшьләре оешмасы эшчәнлеге»).*

*5. Рамилә **ГАБДУЛЛИНА** – Башкортостан Республикасы яшьләре лидеры.*

*6. Илдар **ЛОКМАНОВ** – Чиләбе өлкәсенең татар яшьләре берлеге активисты.*

*7. Сөмбел **БИЛАЛОВА** – татар эстрадасының яшь җырчысы.*

*8. Ленария **МӨСЛИМОВА** – «Tatweb» һәм «Мин татарча сөйләшәм» секциясе модераторы.*

*9. Айрат **ФӘЙЗРАХМАНОВ** – «Рух» секциясе модераторы.*

*10. Илмир **ИЛАЕВ** – «Бизнес яшьлек» секциясе модераторы.*

*11. Рашат **ЯКУПОВ** – Казанның 2 нче лицей-интернатының татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*

*12. Кәдрия **ИДРИСОВА** – «Ак калфак» оешмасы рәисе.*

*13. Диана **ГАЛИАКБЕРОВА** – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының оештыру бүлеге мөдире*

**Ренат ВӘЛИУЛЛИН:** Хөрмәтле яшьләребез, эшебезне дәвам итәбез. Кичә безнең эчтәлекле, бик матур гына җыеныбыз башланып китте. Бүген безнең шулай ук бик мөһим көннәребезнең берсе. Без пленар утырышның дәвамына килдек. Безнең сайлаулар да шушында булачак. Бүген без Арча районына да барырга тиеш булабыз. Менә шушы ике көндә инде сез бер-берегез белән таныштыгыз. Сезнең универсиада авылында танышу кичәләре булды, Зөлфия Камалова концертын карап үттегез. Барыбызга да бик ошады! Ә хәзер продуктив, матур итеп кенә эшләргә язсын иде. Алып бару эшләрен шулай ук Тәбрис Яруллинга тапшырабыз.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Исәнмесез, хөрмәтле делегатлар! Яшьләр форумы үз эшен дәвам итә. Бүген безнең бик җитди көн. Программа нигезендә кичә узган барлык проектлар, секцияләр мәктәбе буенча без нәтиҗәләр ясыйбыз. Кичә мин өч секциядә дә булдым. Һәрбер секциягә рәхмәт! Делегацияләрне дөрес бүлеп оештыргансыз. Һәрбер делегация берничә кешегә бүленеп, өч секциягә таралганнар иде. «Бизнес секция»не Илмир Илаев һәм Диләнур Әхмәтҗанова алып бардылар. Тарихи үзаң һәм рухи тормышка багышланган «Рух» секциясен Айрат Фәйзрахман алып барды. Аның нәтиҗәләрен ул әйтер. IT-parkта «Мин татарча сөйләшәм» һәм «Tatveb» секцияләрен Рашат Якупов һәм Ленария Мөслимова алып бардылар. Бу секцияләрдә аеруча кызыклы проект бар икән, аны секция рамкаларында калдырмыйча, пленар утырышта тәкъдим итәргә мөмкин. Без алдан делегацияләр белән сөйләшкән идек инде, алдан проектны тәкъдим итәр өчен әзерләнеп килгәннәр иде. Кичә дә миңа: «Нигә безгә сүз бирмәдегез, без бит әзерләнгән идек», – дип үпкә белдерделәр. Ләкин инде үзегез аңлыйсыз, безнең вакыт чикле, шуңа күрә бөтен кешегә дә вакыт җитмәде. Мәсәлән, «Рух» секциясендә 25 кеше чыгыш ясаган. Димәк,

теләк белдерүчеләр күп булган. Хәзер дә проектларны тәкъдим итәчәкбез. Сезнең алда залда микрофон тора. Һәрбер кеше чыгып, секцияләр, чыгышлар буенча үз сорауларын бирә ала. Форумның 2 ел эшләп килгән җаваплы сәркатибе Нигина Әхмәдуллина монда. Бу утырыш вакытында микрофонга чыгып әйтергә ояласыз икән, барлык сорауларны, язуларны Нигинага тапшырырга мөмкин. Тагын безнең мөһим чара – сайлаулар. Оештыру комитеты тарафыннан форумны идарә итүче орган – совет, яшьләр шурасы. Димәк, Бөтендөнья татар яшьләре советы сайлана. Былтыр аның составына 47 кеше кергән иде, быел без совет әгъзаларының проектын тәкъдим итәрбез. Инде аны кабул итү-итмәү ул сездән тора, без аның өчен тавыш биреп сайларга тиеш булачакбыз. Шуннан соң зал белән рәис сайлау мәсьәләсен дә чишәрбез. Гадәттә, без совет белән сайлый идек, ләкин залда, барыбыз да бергә сайлау дөресрәк булыр. Ничек итеп сайлыйбыз? Аның тәртибе бар. Димәк, һәрберегездә дә менә шундый бейджиклар бармы? Бар. Беренче рәттә утырган Айрат Фәйзрахманов, Гөлназ Бәдретдин һәм Илһам Гайнетдиновны сайлау комиссиясе буларак тәкъдим итәм. Әгәр дә сез каршы булмасагыз, алар ничә кеше битараф, ничә кеше каршы һәм ничә кеше хуплаганын санап барырлар. Һәм Президиумга китереп, белдереп барырлар. Әйдәгез, димәк, Айрат Фәйзрахмановны, Гөлназ Бәдретдинны һәм Илһам Гайнетдиновны сайлау комиссиясе итеп сайларга кем риза? Яхшы. Кемнәр каршы? Каршылар юк. Битараф? Берәү дә юк. Яхшы, бертавыштан кабул ителде.

Димәк, безнең әле кызыклы, файдалы чыгышлар да калды. Кичә без бөтен оешмалар исеменнән, проектлар, чаралар уздыру буенча чыгышларны тыңлап бетердек. Эшлекле рәвештә тәкъдимнәрне тыңлаганыгыз өчен рәхмәт. Инде бүген андый хисап тоту, отчет чыгышлары булмаячак, фәкать конкрет тәкъдимнәр, проектлар буенча чыгышлар булачак.

Беренче булып чыгыш ясаучылар турында бер-ике сүз әйтеп китәм. Без ике ел инде «Шаяннар һәм тапкырлар клубы»ның төп оештыручыларның берсе булып торабыз. Бу КВНың татарча аналогы. Ул Татарстанның Чаллы шәһәрендә туган иде һәм шулай зур хәрәкәткә әверелде. Хәзер ул шушы хәрәкәттән үсеп чыккан егетләр кулында. Егетләр аны Казан шәһәренә алып килделәр. Мин сүзне шушы хәрәкәтнең җитәкчеләренең берсе **Руслан Харисовка** бирәм. Руслан, рәхим ит!

**Руслан ХАРИСОВ:** Исәнмесез, дуслар! Беренчедән, сорау бирәсе килә. Кем татар лигасы турында белә? Кулыгызны күтәрегез әле. Ә кем белми? Андыйлар юк.

«Шаяннар һәм тапкырлар клубы»н КВНның татарча аналогы дип әйтергә була. Ул 19 ел элек Чаллы шәһәрендә туды. Аның оештыручысы, «әнисе» – Таштабанова Фәридә Якуповна. Һәм бүген дә ул Татарча КВН белән бергә. Шулай ук, ике ел элек без Казан шәһәренә күчтек. Бу бик шәп яңалык. Чөнки без монда күчкәннән соң командалар тагын да күбәйде. Татар лигасында командалар Татарстан, Башкортостан шәһәрләреннән катнашалар. Һәм инде, әлбәттә, төрле шәһәрләрдән актив катнашырлар дип өметләнәбез. Чөнки татар лигасы ул – зур гаилә, анда бик кызык.

Шулай ук, әйтәсе килә, татар лигасының үз җыелма командасы бар. Анда яшь һәм тәҗрибәле, күп еллар сәхнәдә уйнаган егетләр бар. Алар Республика лигасында гына түгел, ә Россия күләмендә узган уеннарда да катнашып киләләр.

Быел безнең тагын бер сезон башлана. Ул КВН мәктәбеннән башланып китә. Аларга төрле дәресләр, мастер-класслар үткәрелә. Анда бик күп яңа командалар формалаша. Татар КВН мәктәбен тәмамлаганнан соң фестиваль уза. Без анда сезне, әлбәттә, көтәбез, килегез. Рәхәтләнеп ял итәрбез!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Ә хәзер киләсе спикерны чакырабыз. Илдар Локманов – Чиләбе өлкәсенең татар яшьләре берлеге активисты.

**Илдар ЛОКМАНОВ:** Хәерле иртә, хөрмәтле делегатлар! Чиләбе өлкәсе татар яшьләре берлеге исеменнән барыгызны да бүгенге форумда катнашуыгыз белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм эшегездә зур уңышлар телим!

Безнең проект «Этно-парк» дип атала. Чиләбе өлкәсе Европа белән Азия тоташкан урында, Россиянең үзәгендә урнашкан. Анда төрле милләт кешеләре яши. Хәзерге көндә 152 милләт санала. Татарлар Көньяк Уралдан XI гасырда күчеп килә башлыйлар. Төрле һөнәр ияләре, сату-алу белән шөгыльләнүчеләр саны арта бара. Хәзер 220 меңнән артык татар санала. Бүгенге көндә шәһәрләр зурая, тормыш тиз темплар белән алга бара, яңа информацион технологияләр барлыкка килә. Көньяк Уралдагы татар бизнесының яңача эшләве, халыкны кызыксындырырлык, яшьләрне җәлеп итәрлек методлар булдыру бик мөһим. Татар бизнесының әһәмиятле өлкәсе булып һөнәр осталыгы тора.

Златоуст шәһәре кул осталары белән күптәннән билгеле. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, татар конгрессы оештырган «Татар кызы» конкурсына таҗны Златоуст осталары эшләде. Татарларның буыннан-буынга күчеп килүче металл белән эшләү үрнәкләрен шулай ук Магнитогорск осталары саклап килә. Көньяк Урал үзенең таш

чыга торган урыннары белән бөтен дөньяга билгеле. Татарларның бизнесын һәм һөнәрчелеген үстерү өчен бизнес-мәктәпне үтәргә кирәк булачак. Анда мастер-класслар, яңа проектлар тәкъдим итү һәм башка чаралар булачак. Бу мәктәпне тәмамлаучыларның проектлары милли-мәдәни «Этно-парк» комплексының татар хуҗалыклары составына үтәчәк. «Һөнәрчелек мәктәбе» – белем арттыра торган проект, ул үзенә түбәндәгеләрне тартачак: семинарлар, мастер-класслар, технологик эшләнеш процессы, маркетингны алга җибәрү. Бизнеслык мәктәбе, татар бизнесының хәл ителергә тиешле мәсьәләләрен «Бизнес мәктәп» оештырырга дип карар кабул ителде. Аны үтәү өчен түбәндәге эшләрне башкарырга кирәк: конкурста катнашучыларны сайлап алу, сораулар бирү, катнашучыларның максатлары буенча төркемнәргә бүлү, бизнес-план төзү, грантларда катнашу, дәүләтнең финанслау программаларына кертү. Бүгенге көндә, булдырылган проект – сайт. Анда инвесторларга кирәкле мәгълүмат һәм акча салу счетлары күрсәтелгән.

Быел сентябрь аенда Татарстаннан делегация көтәбез. Шунда барлык сорауларны, мәсьәләләрне карап үтәрбез дип уйлыйм. Рәхмәт барыбызга да!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Сүз Балтач районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары **Илһам Гайнетдиновка** бирелә.

**Илһам ГАЙНЕТДИНОВ:** Хәерле көн, хөрмәтле Президиум, делегатлар! Минем Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшьләр белән оештырыла торган эш тәҗрибәбез белән уртаклашасым һәм үземнең фикеремне мәркәзебез Казанда уздырылучы алтынчы Бөтендөнья татар яшьләре форумы делегатларына җиткерәсем килә. Күп кенә үткәрелеп килә торган Республика, илебез күләмендәге чаралардан килгән дәрәҗәле кунаклардан: «Сез татарча гына сөйләшәсез, татарча гына яшисез, аралашасыз» икән, дигән фикерләр ишетелә. Аллага шөкер, ул миллидини тәрбиягә килеп тоташа. Татарда «Тәрбия бишектән башлана» дигән әйтем бар бит. Районыбыз җитәкчелеге ярдәме белән, Республикабызда беренчеләрдән булып, район мәктәпләребездә әхлак дәресләре инде 13 ел алып барыла. Мәчетләребездә балалар мәдрәсәләре эшләп килә. Даими рәвештә хәләл ярминкәләр оештырыла. Бу эшләрнең нәтиҗәсе – бүген Балтач районы Борбаш авылында алтынчы Республика мөселман балалар Сабантуе уза. Анда Республика районнарыннан, Рәсәйдән кунаклар катнаша. Районыбыздагы яшьләр белән төрледән-төрле чаралар үткәрәбез.

һәм алар актив катнашып килә. Даими рәвештә КВН, «Авыл яшьләре» көннәре, мәдәни чаралар, фестивальләр үткәрелә, «Кәеф» интернет-радиосы бар. Балтач студентлар берлегенең фикерләре, тәкъдимнәре белән җирле җитәкчеләр даими кызыксынып бара. Районыбызның үсешендә креатив фикерләребезне кулланып килә.

40 ел дәвамында ут күршеләребез, Мари Иле Республикасының Мари Төрәк районы, Киров өлкәсенең Малмыж районы белән берлектә «Дуслык учагы» дип исемләнгән чара уздырып, татар милләтенең гореф-гадәтләрен, милли уеннарын башка милләт вәкилләренә өйрәтеп, саклау һәм үстерү эшендә эш алып барабыз.

2013 елда игълан итеп, беренче тапкыр, «Балтай-Everest» дип аталган кыска метражлы фильмнар фестивален агымдагы елның апрель аенда гала-концерт белән тәмамладык. Барлыгы 9 номинациядә 37 эшкә бәя бирелде. Мондый күләмле эшкә нәтиҗә ясаганда, якташыбыз Илшат Рәхимбай тарафыннан әйтелгән җылы сүзләр, алга таба да бу фестивальне даими үткәрергә фикер тудырды. 2015 елның апрель аенда узачак фестивальгә старт бирелде.

Хөрмәтле делегатлар, хөрмәтле Президиум, инде форумның резолюциясен кабул иткәндә берничә тәкъдимем бар. Проектлар мәктәбе турында сөйлибез, аларның берничә проценты гына татар телендә языла. Шушы проектларны безгә курыкмыйча татар телендә язып, инде югары бәяләсәләр, безнең проектлар тагын да артыр һәм күбәер иде. Икенче тәкъдимем татар авылларына кагыла. Аларны саклап калу, үстерү, аларда конкурентлашырлык җитештерү булдыру – көн кадагында торган мәсьәлә. Бу проблемаларны чишәрлек, югары, махсус урта белемле, авылда төпләнеп калырлык яшьләребезне туплар өчен, аларны эш белән тәэмин итәргә кирәк. Бу вәзгыятьне чишүдә илебез җитәкчелегенә үз фикеребезне, тәҗрибәбезне күрсәтү зарури. Чөнки авылларыбыз үз вакытында телебезне, динебезне саклап калды.

Хөрмәтле делегатлар, яшәешнең кайсы өлкәсенә генә карасак та көннән-көн дөнья күләмендә татар яшьләре зур роль уйный бара. Ул мәгариф өлкәсендәме, социаль, мәдәният, сәнгать, авыл хуҗалыгы – барысында да киләчәк буын вәкилләре. Мәчетләребезгә, Аллага шөкер, яшьләр йөри. Яшьләр булгач, киләчәгебез бар. Әмма тик утырырга ярамый, вакыттан артта калмыйча татар телен сакларга, үстерергә һәм камилләштерергә кирәк. Милли гореф-гадәтләребезне таратуда яңа технологияләр, алымнар кулланып, алдынгы фикерне һәм тәҗрибәне өйрәнеп, алга, вакыт белән бергә барганда гына нәтиҗә һәм үсеш булачак. Бергә булыйк, бердәм булыйк, битараф булмыйк. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Илһам, бик зур рәхмәт! Хәзер сүз Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе урынбасары **Гөлназ Бәдретдинга** бирелә.

**Гөлназ БӘДРЕТДИН:** Билгеле, татарлар сибелеп яши торган халык. Дөньяда татар яшәмәгән җир юктыр. Безнең бу җыелыш менә шуны исбатлап тора. Кемдер ачлыктан, кемдер сугыш елларында үз туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган. Бүгенге көндә ассимиляция һәм глобализация аркасында аларның нәселеннән булган балалар үзләрен татар итеп санар өчен бердәнбер мөмкинлекне күрәләр – үзләренең тарихи Ватаннары Татарстанга кайту. Бу процесс зур темплар белән бармаса да, дәвам итә һәм дәвам итәчәк.

Соңгы 2–5 ел эчендә генә Иркутск, Кемерово, Тольятти, Үзбәкстан, Казахстан, Самара, Мари Иле, Түбән Новгород, Екатеринбург, Себер, Оренбург, Приморье, Сембер, Кавказ республикаларыннан, Краснодар, Төркия, Кытай, Литва, Эстония, Азәрбайҗан, Латвия, Санкт-Петербург, Мәскәү төбәкләреннән туган якка кайтучылар бар. Милли хәрәкәттә булган һәр икенче татар – Башкортостаннан. Алар Казанга акча эшләү өчен килмиләр, ә татар мохитендә яшәр өчен, балаларын тәрбияләр өчен, татар булып калыр өчен кайталар. Кайбер татар яшьләре Татарстан Республикасына үз өлешен кертер, милләтне саклар өчен монда кайта. Исемнәрен әйтеп тормасам да, алар татар милләтенә бик билгеле. Алар татар милләтен, телен саклауда, үстерүдә зур өлеш кертәләр. Әмма монда килеп туган-тумачасыз, әти-әнисез, дусларсыз яшәү бер дә җиңел түгел. Эшлисе килгән кеше эшен дә таба ул. Әмма иң төп проблема – яшәү урыны. Аларга байтак акча түгеп яшәргә туры килә.

Бүгенге көндә без бер әйбер күрәбез: Украинадан кайткан кешеләргә яшәү урыны да, эш тә, балаларына балалар бакчасы да табыла. Чыннан да, мохтаҗларга ярдәм итәргә кирәк. Әмма 1996 елда, үз илебездә, Чечен республикасында, сугыш башлангач, анда яшәүче татарлар Татарстан хөкүмәтенә: «Берәр авылда җир бирсәгез, без авылга кайтыр идек», – дип мөрәҗәгать иткәннәр. Ул вакытны килеп чыкмый, алар Сарытау губернаторына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдылар. Губернатор аларга анда җир биреп, бүгенге көндә шунда яшәп яталар. Беркем дә Казан үзәгендә фатир сорамады, ә авылда җир сорадылар.

Шулай ук 2 ел элек Кытайда яшәүче татарлар безнең Президентыбызга шундый мәсьәлә буенча мөрәҗәгать иткәннәр иде.

«Без авылга кайтабыз, аны яңартабыз, төзәкләндерәбез», – дип. Аңа да җавап, кызганычка каршы, булмады.

Мин үзем дә берничә ел элек хат язган идем, Татарстанда чит илдән кайтучыларга социаль ипотека аша фатир алу мөмкинлеге тудыру турында. Җавабы аның бик гади иде: «Торган җирләрегезгә мөрәҗәгать итегез». Бушка да сорамыйбыз кебек, әмма җавап барыбер юк.

Тагын бер проблема: Россия төбәгендә яшәгән татар яшьләре паспортын кыстыра да килә. Эшен, яшәү урынын таба. Ә чит илдән килгән яшьләргә проблема күп: аларга яшәү, эш урыны буенча документ алырга кирәк. Шуңа күрә, минем тәкъдимем бар. Татарстан хөкүмәтенә яшьләр исеменнән мөрәҗәгать итәргә яки чит илләрдән килгән татарларга ярдәм итү, катнашу буенча аерым программа кабул итәргә. Бик зур рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт, Гөлназ! Ә хәзер сүз Бөтендөнья татар яшьләренең җаваплы сәркатибе **Нигина Әхмәдуллинага** бирелә.

**Нигина ӘХМӘДУЛЛИНА:** Исәнмесез, кадерле Президиум, делегетлар һәм кунаклар!

Син – яшь, перспективалы, югары белемле белгеч. Син Казанга кайтып, тору урынын табып эшләргә һәм яшәргә телисең, ләкин бер теләк кенә җитми шул. Чит ил татарларына тарихи ватанга ничек кайтырга? Максатка ирешү өчен өч адым үтәргә кирәк.

Беренче адым. Вакытлы яшәү өчен Рөхсәт (Разрешение на временное проживание). Бу документ сиңа 3 ел эчендә яшәргә һәм эшләргә хокук бирә. Ләкин яшәү рөхсәте бары тик документ алынган шәһәр яки районда гына.

Икенче адым. Өзлексез яшәү өчен Рөхсәт (Вид на жительство) – 5 ел дәвамында бөтен Россия буенча яшәргә һәм эшләргә рөхсәт биргән документ. Теге яки бу төбәккә бәйле түгел.

Өченче адым. Өзлексез яшәү өчен Рөхсәт алудан соң шунда ук Россия ватандашлыгына (гражданство РФ) документлар биреп була. Моның өчен билгеле шартлар бар:

– Россия Югары уку яки Урта белем бирү дипломы;

– 3 елдан күбрәк Россия ватандашы белән никахлы булса;

– әти-әниең Россия гражданы булса;

– РСФСР территориясендә туган булса.

Әлеге шартлар үтәлмәсә, Вакытлыча яшәү рөхсәтеннән соң 5 елдан соң РФ ватандышлыгына документларны тапшырырга мөмкин. Мәсәлән, син барысын да белдең дә һәм бүген Вакытлы яшәү өчен Рөхсәткә документларны бирергә җыендың, ди. Ләкин

бу очракта син документларны тапшыру каршылыклары белән очрашырга мөмкинсең. Квота инде май-июнь айларында бетте, ә киләсе елда бары тик гыйнвар-февральдә генә була. Нәкъ менә бу елны квоталар 41%ка киметелгән. Квотаның зур өлешен «түбән квалификацияле эшчеләр» ала. Перспективалы татар яшьләре өчен урын җитми! УФМСның Вакытлы яшәү өчен Рөхсәткә 2013–2014 елларның беренче айларында гаризалар кабул итү мәгълүматларына күз салыйк.

Без Татарстан җитәкчелегеннән Бөтендөнья татар яшьләре форумына Татарстан җирлегендә Вакытлыча яшәү өчен 100 квота бүлеп чыгаруны сорыйбыз. Бу очракта югары белемле татар яшьләренә мөмкинчелекләр ачылыр иде. Бу тәкъдим хыял булып кына калмас, ә тормышка ашар дип ышанабыз!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Нигина бик зур рәхмәт! Чыннан да, җитди мәсьәлә. Әле бу чыгышка өстәп әйтәсем килә. Нигина монда Казанга күчкәндә татарча яхшы белми иде. Форумга әзерләнгәндә карыйм: инде Нигина татарча чыгышлар язып утыра. Димәк, аның шундый прогресс булды. Ул гражданство алып, үзен дә, әнисен дә Татарстанга күчерде. Менә нинди батыр кеше булып чыкты. Нигина бик зур рәхмәт сиңа!

**Ринат ЗАКИРОВ:** Миграция мәсьәләсе чыннан да бик катлаулы. Әле ничә ел элек кенә без бөтенләй кабул итә алмый идек. Кытай татарлары беренче тапкыр укырга килгәндә, әти-әниләре белән ул чактагы Татарстан Президенты М.Шәймиев белән очрашып, шул мәсьәләне дә караганнар иде. Ул вакытта аларның күчү мәсьәләсе хакында Россия законында бер генә җөмлә дә юк иде. Президент аларга: «Балаларыгызны укырга китерегез, аннары үзегезгә дә мөмкинлек ачылыр», – дип тәкъдим ясады. Үткән ел Татарстанга 500 кешегә квота бирелде. Россия законнары буенча һәр кеше бу квотаны ала ала. Шуңа күрә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен мөмкинчелек ачыла. Ә инде чит җирләргә килеп урнашкан милләттәшләребез арасында кире кайтканнары да шактый. Татарстан авылларында милләттәшләребезне кочак җәеп каршы алырга әзер торалар. Бөтен хакимият башлыклары якты йөз белән каршы алачак. Татарстан авыллары әкренләп шәһәрләшеп бара. Елдан-ел мөмкинлекләр арта. Авылларда эшмәкәрлек үсә, гомумән, авылларда яшәү шартлары яхшырды. Шуңа күрә, күчеп кайтырга исәбегез булса, үзегездән активлык булса, моны чынга ашырырга мөмкин. Ләкин без бервакытта да: «Әйдәгез, безгә күчеп кайтыгыз», – дип әйтеп яшәмибез, чөнки татар – бик зур милләт. Бүгенге көндә, безнең 37 илдә татар оешмалары эшли.

Без Татарстанда гына җыелып яши торган милләт түгел. Без кайда гына яшәсәк тә, татар милләтен күтәреп, барлык төбәкләргә дә таралырга тиешбез. Бу очрашулар шушы татар тормышын киләчәктә тагын да күтәрергә ярдәм итәр дип уйлыйм. Рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Ә хәзер сүз татар эстрадасының яшь җырчысы, Мәскәүдә яшәүче **Сөмбел Билаловага** бирелә. Рәхим ит!

**Сөмбел БИЛАЛОВА:** Хәерле көн, хөрмәтле дуслар! Бүген сезнең алдыгызда чыгыш ясавыма мин бик шат. Шулай килеп чыкты, мин Казанда туып үстем, ә бүген Мәскәү шәһәреннән килгән делегат. Язмыш татар кешесен кайда гына илтми. Мин татар кешесенә кияүгә чыгып, хәзер Мәскәүдә торам һәм, инде шушы форсаттан файдаланып, Мәскәү татар яшьләренә рәхмәт әйтәсем килә. Аеруча, Эмиль Фәйзуллинга, чөнки алар үзләре янына килгән һәр кешене колач җәеп каршы алалар. Һәрвакытта да ярдәм итәләр.

Мин Мәскәүгә килгәч бик курыккан идем, нишләрмен, кайда барырмын дип. Бер кешене дә белмим. Инде үземнең бер дә татар мәдәниятеннән ерак китәсем килмәгән иде. Шуңа күрә, Аллага шөкер, Мәскәүдә үземне бер дә чит төбәктә итеп хис итмим. Татарлар Мәскәүдә бик актив. Бик күп чаралар, концертлар, проектлар тормышка аша. Һәм үзем дә аларда кайныйм.

Сезгә бер проект тәкъдим итәсем килә. Ул ноябрь аенда, Мәскәү шәһәрендә уздырылачак Бөтенроссия «Татар кызы-2014» бәйгесе. Бу бәйгенең төп оештыручысы – Стелла Брундукова. Рәсәй татар автономиясе белән берлектә оештырылачак. Мин бәйгенең төп администраторы.

Бу бәйге турында бераз сөйләп үтәсем килә. Ул шулай ук Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы һәм Федерациясе ярдәме белән оештырыла. Бәйгенең максаты – татар кызларында татар теленә, сәнгатенә, гореф-гадәтләренә кызыксыну уяту. Шулай ук шартлары бар: 18–25 яшькә кадәр; татар гаиләсеннән булу; татар телен сөйләм дәрәҗәсендә белү мөһим.

Минем сезнең яныгызга чыгуымның максаты – татарлар яши торган төбәкләрдә сайлап алу турларын уздырырга ярдәм итә торган бик актив кешеләр кирәк. Сезнең арагызда шундый кешеләр булса, минем яныма килә аласыз. Мин сезгә барысын да сөйләрмен. Без ноябрь аенда Мәскәүнең иң зур залында шундый шоу-программа уздырырга планлаштырабыз. Һәр төбәктән иң яхшы, иң булган татар кызларын көтеп калабыз. Аларны табуда безгә ярдәм күрсәтсәгез, без бик рәхмәтле булыр идек. Безнең

бәйге турында белешмәне «Вконтакте» челтәрендә һәм сайтта карарга мөмкин.

Сентябрь-октябрь айларында шушы кастингларны уздырырга уйлыйбыз. Аннары сайлап алынган кызлар, Мәскәүгә килеп, бер ай безнең укытучылар белән эшләячәкләр, мастер-класслар үтәчәкләр, билгеле шәхесләр белән очрашачаклар. Һәм ноябрьдә инде безнең зур гала-концерт була. Кадерле дуслар, «Татар кызы-2015» бәйгесе сезне көтеп кала.Татар яшьләре, һәрвакытта да бергә булыйк һәм без барысын да булдырырбыз.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Димәк, вәгъдә ителгәнчә хәзер секцияләр буенча нәтиҗә ясыйбыз. Без аны «Проектлар мәктәбе» дип атадык. Беренче секция «Tatweb» һәм «Мин татарча сөйләшәм», аның модераторларының берсе –**Ленария Мөслимова**. Сүз Сезгә.

**Ленария МӨСЛИМОВА:** Хәерле кич, форум делегатлары, мөхтәрәм кунаклар! Безнең кичә IT-паркта 200ләп кеше катнашында «Мин татарча сөйләшәм» һәм «Tatweb» секцияләре утырышы узды. Алар проектлар мәктәбе форматында иде. Форум делегатлары һәм кунаклар татар телен һәм интернетны үстерү максатына җавап биргән 12 проект кабул иттеләр. Проектларны тәкъдим итүчеләр арасында яшь инициатив кешеләр булды. Алар татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү, аның мохитен төрле яңа дәрәҗәләргә чыгару теләк-максатына ирешергә тели. Кайбер проектлар матди ресурсларга мохтаҗ. Секциядә тәкъдим ителгән проектлар арасында: планшет өчен «Әлифба» кушымтасы, «Хәләл гид» кушымтасының татар версиясе, балалар өчен «Үчтеки» сайты, балаларга татар телен өйрәтер өчен «Акыллык» проекты, чит илдә скайп аша татар телен өйрәтү, андроид өчен русча-татарча, татарча-русча сүзлек һ.б. бик тә кызык проектлар кабул ителде.

Яңа проектлар залда кызыксыну уятты. Һәрбер чыгышка секциянең экспертлары үз фикерләрен белдерде, киңәш-тәкъдимнәрен кертте. Форум делегатлары милли проектларны тормышка ашыру юллары турында белешергә тырышты. Бу юнәлештә алар проектларның матди ягы турында да сораштылар. Иң төп мәсьәлә – ул татар телен, мәгарифен үстерү максатыннан ясалган проектлар. Гадәттә алар табышсыз, бары тик милли хисләр, инициатива белән башкарыла. Проектларның сыйфаты, башкарылу вакыты, перспективасы, даими булуы шик астында кала, шуңа бәйле секциядән форумыбызга килгән тәкъдимебез шул: заманча татар проектларын үстерү һәм этәргеч бирү максатыннан, форум кысаларында, крауфайдинг аша матди фонд булдыру һәм инициатив эш

башкарган яшьләргә мондый проектларда матди ярдәм күрсәтү. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Бик зур рәхмәт, Ленария! Чыннан да, мин дә кичә ул секциядә катнаштым. Бик күп кызыклы проектлар булды. Яхшы әзерләнгәннәр иде. Проектлардан күбесе инде тормышка ашырылган. Ә планлаштырылганнарын инде җентекләп карап, форум исеменнән хатлар язып, аны берәр дәүләт программасына кертеп тормышка аштырырга тырышырбыз. Димәк, алга таба, «Рух» секциясе. Ул «Казан» меңьеллык музеенда узды. «Рух» секциясе тарихи үзаң, рухи тормышка багышланды. Аның модераторы – **Айрат Фәйзрахманов**. Рәхим ит, Айрат!

**Айрат ФӘЙЗРАХМАНОВ**: Саумысыз, хөрмәтле делегатлар! Безнең бу секциядә 200гә якын делегат катнашты. 25 кеше чыгыш ясады. Чыгышлар төрле дәрәҗәдә булды. Рухи кыйммәтләргә төрле караш. Барыбыз да уртак нигезебез булып, дин, тарих, тел тора дигән фикергә килдек.

Тарих турында сөйләшсәк тә, күбебез тел проблемасын күтәрде. Бигрәк тә Башкортостаннан Бәләбәй гимназиясе директоры чыгышы кызыксыну уятты. Чыгыштан соң шундый тәкъдим яңгырады: аерым бер авылда татар мәктәбен ачу. Аның буенча аерым алгоритм төзеп, яшьләребезгә тарату, җиткерү.

Чыгышларыбызның географиясе киң, дәрәҗәсе дә, ысуллары да төрле. Кайбер чыгышлар милли стильдә узса, икенчеләре фәнни яктан ясалды. Чыгышларда сүз татар авылларының көнкүреше турында да булды. Без шундый нәтиҗә ясадык: секция ахырында чыгыш ясаучылар үзләре халык алдында нотык тотарга икәнен белеп, алдан ук әзерлекле булсалар иде. Конкрет проектларны секциядә тәкъдим итү зарур. Гомумән, сүз анда шул ук кыйммәтләр турында барды. Әмма конкрет проектлар булмады.

Секция ахырында безнең аерым бер тәкъдим ясалды. Мордовия республикасында булган күңелсез вакыйга буенча түбәндәге мөрәҗәгать тәкъдим ителде: Бөтендөнья татар яшьләре форумы яулыкның милли традицион баш киеме икәнен билгели. Татар кызларының яулык киеп йөрүе милли гореф-гадәтләрне саклау өчен бик мөһим. Бөтендөнья татар яшьләре форумы Мордовия Республикасы җитәкчелегеннән кызларның яулык бәйләп йөрүен тыючы карарны гамәлдән чыгаруны таләп итә. Һәм мондый карарлар Россиянең башка төбәкләрендә дә кабул ителгән булса, аларны да шулай ук гамәлдән чыгару мәсьәләсен куярга. Аны резолюциягә кертүегезне сорыйбыз яки аерым мөрәҗәгать ясарга тәкъдим итәбез. Шуның буенча тавыш бирәбезме?

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Әйдәгез, бу мөрәҗәгать буенча тавыш бирәбез. Бу мәсьәләне хуплыйбызмы, юкмы? Кем риза хупларга? Яхшы, рәхмәт. Кем каршы? Берничә кеше каршы. Битарафлар? Яхшы, рәхмәт. Күпчелек тавыш белән ризалашабыз бу тәкъдим белән. Рәхмәт.

**Айрат ФӘЙЗРАХМАНОВ:** Шулай ук, шундый тәкъдим яңгырады: Татарстан Республикасы, татар халкы тарихы буенча аерым конкурс, олимпиада уздырырга һәм өйрәнелү фәнен мәктәпләрдә укытылуы хакында күзәтеп барырга. Мөмкин булса аны да гомум резолюциягә кертүегезне сорыйбыз. Бик зур рәхмәт! Менә шундый тәкъдимнәр яңгырады. Шулай ук, аерым секция программалар кабул итәргә тиеш дигән тәкъдимнәр ясалды. Аларны форум материалларына туплап, бастырырбыз дип уйлыйбыз.

Шулай ук, әйтергә кирәк, Татарстан Республикасы институты саклана башлаган иде, шул теманы дәвам итеп, күмәкләшеп тәкъдим төзедек. Аны Бөтендөнья татар яшьләренең белдерүе буларак кабул итүегезне сорыйм. Соңгы вакытларда Татарстан Республикасы Президенты атамасы тирәсендә шактый кызу бәхәсләр бара. Халкыбызның күпчелеген Татарстанда Президент институтының юкка чыгу куркынычы борчый. Бөтендөнья татар яшьләре форумында катнашучыларның фикере шундый: «Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм аның җитәкче органнарын формалаштыруны Республиканың фәкать үз вәкаләтләре дип раслый. Шулай булгач, Россия Дәүләт Думасы тарафыннан илебез Конституциясенә каршы килгән закон кабул итү нияте, Республика җитәкчеләренең атамасын көчләп үзгәртү омтылышы бездә кискен ризасызлык тудыра. Президент атамасы халык фикере белән булдырылды һәм демократик шартларда халык фикере хокукый нигез була ала дип саныйбыз. Без, җир шарының төрле почмакларыннан килгән татар яшьләре, мондый басымны катгый рәвештә кире кагабыз һәм халкыбызны Татарстанда «Президент» институтын якларга чакырабыз. Тирән тамырлы дәүләтчелек традицияләренә ия булган 7 миллионлы татар халкының, һичшиксез, үзенең милли лидерын якларга хакы бар. Без бу мәсьәләләрдә бердәм булсак, максатыбызга ирешә алырбыз!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Бик мөһим белдерү. Әйдәгез, аны тавышка куйыйк. Кем шушы белдерүне кабул итәргә риза? Яхшы, рәхмәт. Кем бу белдерүгә каршы? Яхшы, рәхмәт. Битарафлар? Яхшы, рәхмәт. Күпчелек тавыш белән белдерү кабул ителә.

**Айрат ФӘЙЗРАХМАНОВ:** Бик зур рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Айрат, рәхмәт! Киләсе чыгыш соңгысы. Ул «Бизнес яшьлек» дип атала иде. Аның модераторлары: Татарстан Республикасының инвестицияләр агентлыгы идарәсе хезмәткәрләре **Илмир Илаев** һәм Диләнур Әхмәтҗанова. Илмир сине сорыйбыз, секциянең нәтиҗәләре буенча чыгыш ясарга.

**Илмир ИЛАЕВ:** Хәерле көн барыгызга да! Хөрмәтле, форумда катнашучылар, килгән кунаклар, Президиум әгъзалары. Дөресен генә әйткәндә, форумда беренче тапкыр гына катнашам. Шул ук вакытта, оештыручылар миңа «Бизнес яшьлек» секциясенең модераторы булырга мөмкинлек бирде. Моның өчен зур рәхмәт сезгә! Мин әлеге форумда милләттәшләрем, фикердәшләрем белән бергә булырга бик шатмын.

«Бизнес яшьлек» секциясенең форматын без бераз үзгәртергә тырыштык. Алып бару дәвамында бары тик гадәти чыгышларга гына тукталмадык. Яшьләр, эшкуарлар өчен кулайрак атмосфера тудырырга тырыштык. Дискуссия, аралашу, сорау-җавап форматында алып барырга тырыштык. Без секция дәвамында тормышка ашырылган һәм реализация этабында булган, тәкъдим ителгән проектлар белән танышып уздык. Секциягә махсус кунаклар, спикерлар чакырдык. Шулай ук әйтеп узасым килә, проектларга бәя бирер өчен өч белгеч чакырылган иде. Алар арасында Татарстан Республикасы премьер-министрының икътисад мәсьәләләре буенча киңәшчесе Нәзил Насыйбуллин, «Акбарс торг» ачык акционерлык җәмгыятенең кибетлар ачу буенча үсеш директоры Гали Миңнуллин, Бөтендөнья татар эшкуарларының ярдәм итү ассоциациясе рәисе Уразаев Фәрид Язкәрович бар иде.

Без секция дәвамында 10 проект белән танышып уздык. Безгә оештыручылар бик яхшы һәм зур зал бирделәр. Анда 200дән артык кеше җыелган иде. Проектларга тукталып китик. Ләкин конкрет яшьләргә күрсәтерлек, үрнәк булырлык проектлар бик аз иде. Минем әйтеп китәсем килә, бары тик берничәсен генә, чөнки вакытыбыз чикле.

«Yummy» группасы вәкиле, Илдар Кәримов заманча субкультура булдыру турында сөйләп үтте. Бу заманча, алдынгы, сәләтле яшьләр бергә җыелып, җырлар-видеолар булдыралар. Аларның эшчәнлеге коммерция белән бәйле түгел, аларның төп максаты – Республикабызда, татар яшьләре арасында заманча культура булдыру. Шулай ук, Айгөл Сингатуллина, татар яшьләре өчен заманча, милли кием җитештерү проекты белән уртаклашып китте. Кызыксынучылар, әлбәттә, төгәлрәк беләселәре килсә, без аның белән таныштырырга әзер. Шулай ук, минем әйтәсем килә, Алсу

Вәлиева турында. Ул безгә бик детальле, җентекле итеп интернет-проектлары турында сөйләп китте. Интернет челтәрендә ничек итеп акча эшләве турында. Һәм бу, минемчә, яшьләр өчен, бигрәк тә, эшкуар булырга омтылучылар өчен файдалы мәгълүмат булды. Шул ук вакытта, әйтеп узасым килә, «Бизнес-проект» булмаган, әмма Республикабызны дөньякүләмендә танытуга юнәлгән проектлар да бар иде. Безнең агентлыгыбыз һәм Бөтендөнья икътисад форумының Казандагы вәкилләре, Бөтендөнья яшьләр академиясенең Казандагы башлыгы Дилбәр Садыйкова белән эшләгән проект. Ул «Татарстанның яшь вәкилләре» дип атала. Белгәнебезчә, безнең форумга да чит илләрдән, регионнардан бик күп яшьләр килә. Менә шушы яшьләр өчен Республикабызның хәле турында, үсеше, дөньякүләм танылуы турында аңлатып киттек. Һәм әлеге проект та шуның белән бәйле, чөнки, беләсез, безнең яшьләребез һәрвакыт сәяхәт итә, без алар белән бергәләшеп Республикабызны дөньякүләм танытуда эш алып барырга тиешбез. Бу сәнгать, әдәбият, тел ягына бәйле проект. Без бу проектны март аенда башлап җибәрдек һәм сәләтле яшьләр арасыннан телләр белгән, презентацияли алган кешеләрне сайладык. Алар дөньякүләм конференцияләрдә катнашканда Республикабызны шулай танытып йөриләр. Рәхмәт, минем чыгышым тәмам.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рәхмәт, Илмир. Без әле генә тавыш бирдек Татарстан Президенты институтын саклап калырга дип. Без аны интернет челтәренә элачәкбез. Интернет аша да, кәгазьгә чыгарып та, һәрберегез үз төбәгегезгә кайткач аны таратыгыз. Киң җәмгыятькә таратыйк. Ике битараф тавыш белән кабул иттек. Хәзер сүзне **Рашат Якуповка** бирәсем килә. Һәрберегезгә кичә резолюция таратылган иде, без анда яңа тәкъдимнәр керткән идек. Шушы резолюциянең проекты хакында сөйләп китәр өчен Рашатны чакырабыз.

**Рашат ЯКУПОВ:** Тагын бер тапкыр, хәерле көннәр! Димәк, VI Бөтендөнья татар яшьләре форумының резолюциясе.

Татар яшьләре тормышының актуаль мәсьәләләре турында фикер алышканнан соң, борынгы рухи мирасыбызны, милли йөзебезне, ана телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу, буыннан-буынга ирештерү максатында, VI Бөтендөнья татар яшьләре Форумы (БТЯФ) делегатлары түбәндәге

КАРАРНЫ КАБУЛ ИТТЕ:

– Бөтендөнья татар конгрессының V Съезды тарафыннан тәгаенләнгән мөһим мәсьәләләрне тормышка ашыруны төп максат итеп санарга;

– Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге татар яшьләре оешмалары белән элемтәләрне тагын да ныгыту буенча Бөтендөнья татар яшьләре форумы идарәсенең эшчәнлеген хупларга;

– Сәяси әһәмиятен аңлаган хәлдә, Татарстан Республикасында Президентлык институты статусын һәм Россиядә федерализм принципларын үстерү буенча татар иҗтимагый оешмалары һәм киң җәмәгатьчелекнең тырышлыгын хупларга;

– Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге татар тарихи-мәдәни мирас объектлары кергән экскурсион программаларны булдыру максатында, яшьләр белән эшләү һәм туристлык Федераль агентлыгы, ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы туризм агентлыгы белән тыгыз элемтә булдырырга. Шулай ук халыкара яшьләр туристлык программалары кысаларында, махсус порталлар, он-лайн сервислар ярдәмендә татар халкының тарихи-мәдәни мирас ядкәрләрен һәм Татарстан бренден танытуда актив катнашырга;

– Уставта билгеләнгән максатлар нигезендә, халыкара, россиякүләм һәм республикакүләм грантларны оту өчен җирле яшьләр оешмаларының төрле бәйгеләрдә актив катнашуына ирешергә;

– Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә теләктәшлек ассоциациясе белән берлектә милли мәгарифне, туган телне, тарихи үзаңны үстерү, милли традицияләрне, гореф-гадәтләребезне саклау максатында инвестиция проектлары төзергә һәм тормышка ашырырга;

– Үзәк Азия һәм Европада яшәүче татар яшьләрен туплау-берләштерү эшенә ярдәм итәргә;

– Татар яшьләренең Татарстан Республикасы югары уку йортларында белем алуын киңәйтергә, аларны БТЯФ эшчәнлегендә актив катнаштырырга;

– Татар телен өйрәнү һәм актив пропагандалау максатында «Мин татарча сөйләшәм», «Автохәрәкәт», Татар дозор», «Печән базары» һәм «Уку паркы» кебек акцияләрне дәвам итәргә, аларны үткәрү географиясен киңәйтергә;

– Бүгенге көндә татар телен өйрәнүдә популяр булган «Ана теле» онлайн-мәктәбе эшчәнлеген киңрәк җәелдерү эшендә актив катнашырга. Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә яшәүче мәктәп балаларының татар теле һәм әдәбияты буенча Татарстан республикасында үткәрелүче халыкара олимпиадада катнашуына булышлык күрсәтергә;

– Авылларда яшәүче татар яшьләрен «Россия татар авыллары» иҗтимагый берләшмәсе эшчәнлегенә киңрәк тартырга, та-

тар авыллары яшәеше серләренә төшенү, туган телебезнең тәмен тоемлау йөзеннән милли бәйрәмебез Сабантуйны, «Авыл кызы» конкурсларын, атлар чабышы ярышларын шәһәр һәм авыл яшьләре белән берлектә үткәрергә, «Россия татар авыллары» иҗтимагый оешмасы белән уртак милли-мәдәни туристлык программалары төзергә;

– Татар телен укыту өлкәсендә милли мәгарифтә килеп туган торгынлык күренешләрен бетерү максатында, Татарстан Республикасында татар теленең, дәүләт теле буларак, рус теле белән бер дәрәҗәдә укытылу таләбен хупларга. Этник милли укыту оешмаларына һәм татар теле курсларын оештыручы оешмаларга ярдәм күрсәтергә, шәхси милли һәм якшәмбе мәктәпләренең эш тәҗрибәсен өйрәнеп, киң кулланылышка кертергә, төбәкләрдә мондый мәтәпләрнең санын арттыруга ярдәм итәргә. Ата-аналар, белем бирү оешмаларына милли мәгърифәтнең зарурлыгын төшендерергә;

– Гаилә институтларының әһәмиятен аңлаган хәлдә, яшьләр арасында милләтнең төп нигезе булган татар гаиләсен төзү һәм саклап калуның әһәмиятен пропагандалау, милли гаилә төзү зарурриятын аңлату эшләрен алып барырга;

– Бөтендөнья татар яшьләре форумына һәм җирле оешмаларга кешенең шәхес буларак камилләшүендә, формалашуында дини тәрбиянең никадәр әһәмияткә ия булуын билгеләп, дини кыйммәтләрне өйрәнергә, яшьләр арасында традицион ислам тәгълиматын пропагандаларга, радикаль идеяләр үтеп керүне булдырмаска;

– «Хәләл» регионара иҗтимагый оешмасының сатып алучыларның хокукларын яклау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча алгарышын хупларга, урыннарда әлеге продукцияне тарату, сертификацияләү, сыйфатын контрольдә тотуда ярдәм күрсәтергә;

– Татарлар күпләп яши торган төбәкләрдә татар теленең рәсми (дәүләт) тел статусы булырга тиешлеген күтәреп чыгарга;

– Татарстан Республикасы җитәкчелегенең тел, мәдәният, мәгариф өлкәсендәге сәясәтен хуплаган хәлдә, Европа хартиясенең төбәк телләренә мөнәсәбәтле уңай эш юнәлеше турындагы мәгълүматны киңрәк таратырга, Европа хартиясенең Россиядә актуальләшүенә ирешергә;

– tatar доменының рәсми ачылуына, татар интернет чараларының таралуына, үсешенә төрле яклап ярдәм итәргә;

– Россиянең төрле төбәкләреннән, чит илләрдән Татарстан Республикасына күченеп килүче яшьләргә ярдәм буенча дәүләт

программасын булдыру турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим белән чыгарга;

– Татар яшьләре оешмаларының халкыбызның милли гореф-гадәтләрен, ана телебезне саклауга юнәлтелгән проектларын һәрьяклап хуплау грантын булдыру турында Татарстан Республикасы хөкүмәтенә тәкъдим итәргә;

– Милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне, туган телне, этномәдәният, телләр төрлелеген, толерантлыкны, үзара татулыкны тагын да ныгытырга, үстерергә, фашистик идеологияне, милләтчелекне, шовинистик төркемнәрне булдырмау йөзеннән милли яшьләр оешмалары белән хезмәттәшлекне тагын да көчәйтергә;

– Спорт яшьләргә физик яктан камилләшергә генә түгел, ә үзара аралашу өчен дә зур мөмкинлекләр тудыра. Соңгы елларда үткәрелгән халыкара спорт форумнары, шул исәптән, Казанда узган Бөтендөнья җәйге Универсиада-2013, Сочида булган кышкы Олимпиада-2014 уеннарының милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне, дуслыкны, хезмәттәшлекне ныгытуда ышанычлы корал булып торуын искә алып, әлеге уңай тәҗрибәне актив кулланырга;

– Без бөтендөнья яшьләрен Россиядә 2015 елда су спорт төрләре, 2018 елда үткәреләчәк футбол буенча дөнья чемпионатларын һәм Формула I ярышларын уздыруны хупларга һәм анда катнашырга чакырабыз;

– Татарстанда икетеллелекне саклау һәм үстерү максатыннан, Дәүләт телләре турында канун нигезендә, Татарстан Президенты каршында икетеллелек мәсьәләләре буенча омбудсмен һәм Татарстан хөкүмәте каршында икетеллелек мәсьәләләре буенча иҗтимагый шура булдыруны таләп итәргә;

– Хаталы тәрҗемәләрне, элмә такталарны төзәтү һәм алга таба аларга юл куймас өчен Казанда бердәм тәрҗемә үзәген булдыруны тәкъдим итәргә;

– Казанда татар телендә чит ил һәм татар фильмнарын күрсәтә торган заманча кинотеатр булдыруны тәкъдим итәргә;

– хатын-кызлар баш киеме – яулыкны – милли традицион баш киеме дип билгеләргә. Татар кызларының яулык йөртүе милли гореф-гадәтләребезне һәм әхлакны саклау өчен бик мөһим. Кызларның яулык бәйләп йөрүен тыю карарын инкяр итүне һәм гамәлдән чыгаруны Мордовия Республикасы җитәкчелегеннән һәм шундый ук карарлар кабул иткән Россиянең башка төбәкләреннән таләп итәргә.

Форумның нигезләмәсе шулай.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Рашат, бик зур рәхмәт! Резлюциягә тагын яңа тәкъдимнәр бармы?

**Эмиль ФӘЙЗУЛЛИН:** Минем кечкенә тәкъдимем бар. Форумда тел проблемасы турында әйтелгән. Һәм ул резолюциянең проектында 12 пункт булып тора. Анда менә шундый җөмлә бар: «Этник, милли укыту оешмаларына ярдәм күрсәтергә, шәхси, милли, якшәмбе мәктәпләрендә эш тәҗрибәсен өйрәнеп, киң кулланышка кертергә һәм төбәкләрдә мондый мәктәпләрне арттырырга». Монда тагын берничә сүз кертергә телим. Этник, милли укыту оешмаларында һәм иҗтимагый оешмаларына да укытырга дип тәкъдим итәм. Яки аерым бер пункт кертергә кирәк. Иҗтимагый оешмалар каршысында татар телен өйрәнү дәресләре курсларын киңәйтергә. Шул ике тәкъдимнең берсен сайларга кирәк булачак.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Яхшы, мин уйлыйм шушы син әйткән тәкъдим буенча мәктәпләр белән беррәттән алып барырга. Әйдәгез, һәр оешма каршында татар теле курсларын булдыру. Алайса, резолюциягә тагын бер тәкъдимне кертәргә. Ризамы? Рәхмәт. Карышлар бармы? Каршылар юк. Битарафлар? Юк. Булды рәхмәт. Нигездә менә шушы тәкъдимне дә резолюциягә кертәчәкбез. Безнең тагын бер тәкъдим бар.

**Ринат ГАРИФУЛЛИН:** «Болгар» радиосын интернет челтәрендә тыңлый алмау мөмкинлеге һәммәбезне дә борчый. Татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә радиоалгычларга чыгу мөмкинлеген булдырсак иде.

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Яхшы, рәхмәт тәкъдимең өчен, Ринат. Безнең резолюциядә бар, гомумән конкрет бер радионы алу дөрес булмастыр. Чөнки безнең радио, телевидениебез берничә. Шуңа регионнарда, яңа пунктлар ачу мәсьәләсен карарга кирәк. Ул безнең резолюциягә кертелгән. Шуңа бу мәсьәлә каралыр. Әйдәгез, тавышка куйыйк. Кем риза? Рәхмәт. Каршылар? Юк. Битараф? Юк. Бер тавыштан кабул ителде. Рәхмәт.

Безнең чыгыш ясамыйча калган кешеләребез, безнең оешманың дуслары бар. Шуңа күрә, рөхсәт итегез, Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумы һәм «Ак калфак» оешмасы рәисе **Кәдрия Идрисовага** сүз бирелә. Рәхим итегез!

**Кадрия ИДРИСОВА:** Хөрмәтле җәмәгать, исәнмесез! Хәерле көн, кадерле яшьләребез! Егетләребез, кызларбыз! Без сезнең белән бергәлектә эшли торган оешма. Татар хатын-кызларының Бөтендөнья форумы һәм татар хатын-кызларының Бөтендөнья «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы. Сез төрле төбәктән килгән яшьләр. Монда бик күп яңа кешеләр белән танышасыз, алга таба алар бе-

лән элемтәдә булсагыз иде. Ни өчен бу турыда әйтәм, чөнки өч көн дәвамында сезнең белән аралашабыз. Сез бит инде безнең янып торган яшьләребез. Күзләрегездә – ут, җаныгызда – дәрт. Һәм инде эшләргә атлыгып торасыз.

Татарны сезнең белән саклап калырга мөмкин. Һәм инде өлкән буыннан калган мирас белән берлектә. Без аларны өйрәнергә булышабыз. Шуңа күрә сезгә әйтәсе килгән теләкләрем берничә. Иң беренчесе: телнең саклау проблемасын әйттек, аны ничек саклап була? Ничек үзебезнең калебебезгә салып була? Һәм кичә бу турыда сөйләшә башладык. Беренчедән, үзебезгә сөйгән яр сайлау. Безнең биредә нәкъ шул яшьтәге кешеләр. Эш дип, җәмәгать эшлеклесемен дип, пар сайламый калырга кирәкми. Без үзебез яраткан, гомер буе бергәләп тормыш кора алырлык иптәш сайлый белергә тиешбез. Иң беренче сайларга кирәк үзебезнең милләтебез кешесен.

Мин сезгә V класс укучысы язган шигырьне мисал итеп китерәм. Аның әтисе урыс, әнисе татар.

Минем әтием урыс, әнием минем татар.
Әти әйтә, урысны, әни әйтә, татарны ярат.
Утырам шулай, уйланып,
Ай белән тәңрегә карап.
Әти китә башымнан сыйпап,
Белмим, нишләргә кирәк.
Уйланырлык бу шигырь юллары.

Икенчесе: үзегезгә яр сайлаганда беркайчан да бу минеке дип сайларга кирәкми. Фикер уртаклыгы сезнең белән бармый. Син, мәсәлән, бик тә мөкиббән икән спортка, ә синең ярың, гомумән, ул өлкәне яратмый. Ә киләчәктә бергә кушыласыз. Фикерләр уртаклыгы аерыла. Әгәр дә фикерләр уртак булмаса, өйдә хатын-кыз, менә аш, менә чәй, дип кенә яшәп булмый. Сез чәй эчкәндә дә, аш ашаганда да фикер уртаклыгы булганда гына гомер буе матур тормыш корып яши аласыз.

Аннары бәби табу турында. Гомумән, җәмгыять эшендә катнашкан кызларыбыз күп вакыт кияүгә чыкмый кала. Бу дөрес түгел. Гомумән, бу ярамый. Иң беренче яр сайлау турында да уйларга кирәк. Аннан бәби алып кайту.

Менә сез бүгенге бик актив яшьләр. Ә киләчәк буын кемгә кала? Бу турыда да уйларга кирәк. Һәм безгә буыннардан калган бишек җырларын өйрәнергә кирәк. Без бу мәсьәлә буенча киләчәктә конгресста фикер алышырбыз дип уйлыйм. Чөнки

без бишек җырларын да дискка яздыру ягында. Бәби тугач исем кушу мөһим. Мәгънәле исемме бу? Ул кешене гомере буе озата бара. Сез шундый камил, мәгънәле исем табарга әзерме? Хәзердән үк бу турыда уйларга кирәк. Һәм инде исем куштыргач, баланың беренче чәче җитә бит инде. Чәчне кем ала? Җиде көннән чәч алынырга тиеш, ул үлчәнергә тиеш. Үлчәнелгән чәчнең граммы бүгенге көндә көмеш граммы бәясенә тапкырланып, шул дәрәҗәдә мохтаҗларга хәер итеп бирелергә тиеш. Бу турыда без беләбезме? Һәм ничек итеп балага исем куштырырга? Бу турыда без аңлыйбызмы? Менә безгә белергә кирәк, хөрмәтле яшьләребез. Менә шуңа безгә бергәләшеп, матур итеп, киңәшеп очрашулар оештырырга кирәк.

Мин сезгә Бөтендөнья татар хатын-кызлары исеменнән ихлас күңелдән иҗадилык, җан тынычлыгы, бәрәкәтле тормыш телим һәм ризыкларыгыз һәрвакыт иманлы, тормышыгыз гаиләле булсын. Бик зур рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Кәдрия апа, бик зур рәхмәт! Безнең кичә төрле министрлыклардан, Татар конгрессы исеменнән рәхмәт хатлары тапшырылды. Безнең һәрдаим бергә эшләп торган тагын бер министрлык бар. Ул Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы. Аның Рәхмәт хатларын тапшырырга рөхсәт итегез. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәхмәт хатларын тапшырыр өчен сәхнәгә оештыру бүлеге мөдире **Диана Галиакберованы** чакырабыз. Диана, Рәхим ит!

**Диана ГАЛИАКБЕРОВА:** Исәнмесез, кадерле милләттәшләр! Рөхсәт итегез, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы исеменнән Рәхмәт хатлары тапшырырга. Татар халкы мәдәнияте һәм сәнгатенең иң матур үрнәкләрен пропагандалауга, милли гореф-гадәтләрне саклап калуга, рухи мирасны торгызу, милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытуга лаеклы өлеш керткән өчен Рәхмәт хаты белән Сисанбаев Илдар Марат улы бүләкләнә.

Шушындый ук рәхмәт хаты белән Бәдретдинова Гөлназ Ригат кызы бүләкләнә.

Шушындый ук рәхмәт хаты белән Мәрдәншина Ләйсән Рәфыйк кызы һәм Мәрдәншин Айдар Рафаэль улы бүләкләнә.

Барыгызга да уңышлар телим. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Ә хәзер дуслар, җитди вакыт җитте. Бөтендөнья татар яшьләре форумының җитәкче органнарын сайларга керешәбез. Рөхсәт итсәгез, безнең оештыру комитеты исеменнән, менә шушы төбәкләрдән, чит илләрдән булган татар иҗтимагый оешмалары исеменнән дә. Менә без исемлек төзедек. Шушы исем-

лекне, советка тәкъдим ителгән кандидатураларны укып китәргә рөхсәт итегез.

Димәк, Татарстан Республикасыннан: Гөлназ Бәдретдинова, Раил Өметбаев, Римма Бикмөхәммәтова, Нигина Әхмәдуллина, Рашат Якупов, Айзат Шәймәрданов, Аммар Аль-Анси, Айрат Фәйзрахманов тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы районнарыннан: Рамил Агдеев, Чаллы шәһәре; Зөлфәт Сәгъдиев, Чүпрәле районы; Илфат Гайнетдинов, Балтач районы һәм Илназ Шәрипов, Актаныш районы.

Европа илләреннән: Олег Шарипов, Латвия; Кәдрия Гәрәева, Эстония; Ильяс Ямбаев, Германия; Әмир Җиһаншин, Ислам Шәнгәрәев, Илдар Сисанбаев, Элина Паули тәкъдим ителә.

Россия төбәкләреннән: Динә Гәрәева, Новосибирск өлкәсе; Рушан Гибатдинов, Чувашия өлкәсе; Люция Гатина, Красноярск өлкәсе; Руслан Мөхәммәтшин, Кемерово өлкәсе; Рөстәм Нәҗметдинов, Томск өлкәсе; Сәид Төсмәхәммәтов, Төмән өлкәсе; Динара Мәҗитова, Әстерхән өлкәсе; Динар Хөсәинов, Ульян өлкәсе; Эмиль Фәйзуллин, Мәскәү шәһәре; Реналь Ихсанов, Сарытау шәһәре; Ренат Фәйзуллин, Ижау шәһәре; Рәмилә Габдуллина, Уфа шәһәре; Мөккәдәс Муртазин, Владимир өлкәсе; Әнвәр Тушаков, Санкт-Петербург шәһәре һәм Илмир Юлмурзин, Мордовия өлкәсе.

Шулай ук, безнең Казан бүлеге активистлары бар: Диләнур Әхмәтҗанова, Ленария Мөслимова, Гөлсәрия Нәбиуллина, Илзам Хаҗиев, Гөлназ Гатауллина.

Менә шушы исемлеккә тагын тәкъдимнәр бармы? Булмаса, мин шушы исемлеккә тавыш биреп, форумның идарә органы советын тәкъдим итәм. Димәк, кем риза шушы исемлек белән? Рәхмәт. Кем каршы? Юк. Кемнәр битараф? Яхшы. Димәк, бер тавыштан Бөтендөнья татар яшьләре форумының советы сайланды. Бик зур рәхмәт.

**Ринат ЗАКИРОВ:** Советы сайлангач, аның рәисе дә булырга тиеш бит инде. Рәисне советта да сайлап була, ләкин биредә утырган яшьләр, минемчә, һәрберсе шушы рәисне сайлауда катнашса, ул уставка каршы килмәячәк. Безнең бер тәкъдим. Тәбрис Яруллин шушы эшне дәвам итсен дигән фикер бар. Без инде алтынчы форумга җиттек. Тәбрискә кадәр өч лидер алмаштырдык. Җиңел әйбер түгел, үзегез аңлыйсыз. Дөнья катлаулы, четерекле, һәр оешманың үз тоткан юлы, җирлеге бар. Таләсә нәрсә сөйләп булмый, халыкка аңлаешлы булырга тиеш. Яшьләргә генә түгел, гомумән, татар халкына аңлаешлы позиция булырга тиеш. Сәяси

мәсьәләләр бик күп, шуларда ориентирлар булырга тиеш. Тәбрискә күз тимәсен дип әйтик. Аның үз тоткан юлы, фикере бар. Менә шушы әйберләр аны яшьләр бүгенге көндә таный торган лидерга әйләндерде. Без бик шатбыз, киләчәктә тагын ике елга барыбыз тарафыннан да шушы вазыйфаны йөкләргә кирәклеге турында сезнең кул күтәрүегезне сорыйм. Кемнәр Тәбрис Яруллинны сайлый? Яхшы. Кемнәр каршы? Юк. Кемнәр битараф? Юк. Бер тавыштан кабул ителде. Котлыйбыз!

**Тәбрис ЯРУЛЛИН:** Бик зур рәхмәт! Без ышанычны акларга тырышырбыз. Ә хәзер инде форумның рәсми өлешен төгәлләргә рөхсәт итегез. Безнең рәсми булмаган гимныбыз бар – «И туган тел, и матур тел...!» җыры. Татарстаннан Ширин Аль-Ансины һәм Башкортостаннан Илсур Сабит улы Сурсабитовны сәхнәгә чакырам. Сез җырны башлап җибәрүчеләр булырсыз. Ә без сезгә кушылып китәрбез. Рәхим итегез!

*«И туган тел, и матур тел…!» җырын башкаралар.*

## «Мин татарча сөйләшәм һәм Tatweb» секциясендә чыгыш ясаучылар

## ИСЕМЛЕГЕ

*Казан шәһәре, IT-парк, Петербург ур., 52 йорт.*
*Модераторлар: Рашат Якуп, Ленария Мөслим*

*1. Айдар һәм Ләйсән **МАРДАНШИНнар** (89258208885, 89251160960) –*

*«Mardesign» компаниясе җитәкчеләре. Планшет өчен «Әлифба» проектын тәкъдим итү.*

*2. Айрат **КАСЫЙМОВ** (89263280545, airat@gmail.com) – «Хәләл-Гид» приложениесы авторы. «ХГ»ның татарчасын тәкъдим итү.*

*3. Айгөл **ӘЮПОВА** – «Үчтеки» балалар проекты авторы. «Үчтеки» сайтын тәкъдим итү.*

*4. Руфинә **ГАБДРАХМАНОВА** – онлайн укытучы, «Әллүки» иҗат берләшмәсе кураторы. «Ана теле» проектын тәкъдим итү.*

*5. Рафил **ФАРВАЕВ** һәм Лилиана **САФИНА** (89636157303, rafil@mail.ru) – Мәскәү шәһәре яшьләр Советының идарә әгъзалары. «Milli mektep» проектын тәкъдим итү.*

*6. Римма* ***БИКМӨХӘММӘТОВА*** *(89375209914) – журналист. «Мин татарча сөйләшәм» акциясен тәкъдим итү.*

*7. Ринат* ***ГЫЙЛӘҖЕВ*** *(89031101454, gilrins@mail.com) – «Дуслык» иҗади-иҗтимагый оешмасы әгъзасы. Татар телен яңа форматта өйрәнү һәм саклап калу проекты «Татарча дискуссион клуб».*

*Экспертлар:*

*1. Римма* ***БИКМӨХӘММӘТОВА*** *– журналист.*

*2. Данил* ***СӘФӘРОВ*** *– Матбугат.ру сайты җитәкчесе.*

*3. Гөлназ* ***БӘДРЕТДИН*** *– журналист.*

**Айдар МАРДАНШИН:** Во время анимирования давали на пробу старшей дочери Сююмбике. Также планируем вставить кнопку, где можно было бы читать стихотворение, то есть коротенькое маленькое стихотворение начало которого с той буквы, которую ребенок видит. Далее следует отдельный выход меню, где будет раскраска на соответствующую букву. Понравившуюся картинку ребенок может выбрать, закрасить и сохранить в галерею, где уже взрослый человек может отправить себе по емайлу.

Приложение «Әлифба» есть на нашем сайте «Mardesign». Его можно скачать и повесить дома или в детском саду на стену.

Недавно запустили конкурс открыток. В прошлом году выпустили подарочные открытки, они всем понравились и в этом году решили выпустить новые открытки с большим количеством татарских узоров. Тот кто выиграет конкурс, будет обладателем первого экземпляра комплекта открыток. Призываем и вас участвовать в данном конкурсе.

Кто еще не знает про нашу студию, то это по-большому счету мы, в Санкт-Петербурге закончили университет искусств. Так же мы связаны с такимим проектами как диск татарской национальной культуры, татары в истории культуры Санкт-Петербурга. В партнерстве запустили сайт знакомств Bik Matur. Он еще только развивается, дизайн полностью наш.

*Залдан сорау.* **Эльвира ГЫЙЛЬФАНОВА** (Уфа): «Әлифба» проекты приложение формасында кайчан тормышка ашырылачак?

**Айдар МАРДАНШИН:** Все упирается в финансирование, реализуем сразу же как получим.

**Эксперт Римма БИКМӨХӘММӘТОВА:** От кого ждете поддержки и сколько это стоит?

**Айдар МАРДАНШИН:** Министерства культуры Татарстана. Если не получим, то общими усилиями попробуем запустить про-

ект. Попробуем обратиться к московским бизнесменам. Но большие надежды возлагаем на Министерство культуры РТ.

**Эксперт:** Айдар, помню ваш проект «Татарский календарь». Тогда была такая практика, что вы получали финансирование?

**Айдар МАРДАНШИН:** К сожалению, все финансирование которое мы до этого получали – от Всемирного Конгресса Татар и то, что я сам заработал. Сами спонсировали свои проекты. А этот проект на презентации существует пока как идея. На нее и планируем получить денежную поддержку и запустить.

**Эксперт Данил СӘФӘРОВ:** То есть приложение для пользователей будетбесплатным? О каких суммах речь?

**Айдар МАРДАНШИН:** Пока точно не знаем.

*Залдан сорау.* Әлеге приложение мәктәпкәчә яшьтәге балалар өченме әллә мәктәптә дә кулланырга мөмкин булачакмы?

**Ләйсән МАРДАНШИНА:** «Әлифба» создается для дошкольного возраста.

**Айрат КАСЫЙМОВ**: Здравствуйте. Рад всех видеть. Я участвовал на форуме в 2012 году, очень много новых лиц.

Тема моей сегодняшней мини-презентации немножко менялась от того, как сделать мобильное приложение до какой-то новости, в итоге татарская версия приложения.

Что такое «Халяль-гид»? Сейчас уже можно сказать, что это полноценная система. Если раньше это было мобильным приложением, то на сегодняшний день мы вышли в веб, сделали сайт и те, кто не имеют мобильных приложений могут с удовольствием пользоваться этим.

Первая функция – база точек. Есть множество сайтов, но реализация каждого из них разная. Мы же в свою очередь постарались сделать это максимально просто, удобно. Если попробуете, то сможете оценить. Сейчас имеются порядка двух тысяч халяльных точек по СНГ, сюда входят Казахстан, Украина, Белорусия, Россия и Крым. Есть обратная связь: пользователи могут не только смотреть эту информацию, еще и оставлять отзывы, комментарии. Поләзователи могут добавлять точки, исправлять, но опять-таки отправив запрос.Что-то исправить к сожалению не получится.

Так же у нас есть афиша исламских мероприятий. В любых городах проходят какие-то мероприятия. чтобы о них знали люди могут зайти и посмотреть, но на данный момент такой афиши не было.

Следующая функция – времена намазов. Они есть везде, это не новое. Что бы людей стало ходить к нам больше мы сделали,

времена намазов в городах. Есть аят дня, эта функция привлекает пользователей, чтобы заходить туда ежедневно.

Следующая функция – задать вопрос имаму. Если есть у кого-то вопросы, сомнения, то их через сайт, через приложение можно задать. Повторюсь, мы пытались увеличить аудиторию пользователей.

Как можно реализовать проект? Его действительно можно реализовать и это не сложно. Летом 2011 года прорабатывая эту идею у меня был всего один листочек, на котором написано примерно как это будет выглядеть схематично, т.к. я немного знал фотошоп. Прежде чем объяснять все это и писать техническое задание. Уже через пол года мы создали первую версию приложения, в которой было всего 4 категории. На сегодняшний день их уже 16. Для работы нужны всего лишь 3–4 человека, которые будут реализовывать проект. Сегодня в команде порядка 13–15 человек, а на постоянной основе работают 3–6 человек.

Для чего нужен сайт? Например, если у вас оффлайн бизнес проект, как «Акыллым». Может со временем и перейдут в интернет. Создав какой-то проект не получится обойти интернет. Так же мы поняли, что не хотим ограничивать аудиторию, в связи с чем создали целую платформу. Платформа на которой можно пользоваться всем: сидеть, оставлять комментарии. Т.к. у нас в компании был владелец iOS платформы версию для iphone сделали раньше. Для Андроида выпустили через пол года. Но на сегодняшний день есть кое-какие проблемы на Google Play, которые мы решаем.

После того как запустили сайт началось самое интересное – аналитика. Смотрели, кто заходит, как заходит, что смотрит. 30% посетителей – это те, кто заходит через мобильное приложение. Сейчас все прекрасно знают, что мобильные версии имеют сайты Яндекса, Mail.Ru. Весь экран Яндекса, конечно, вы не сможете набирать, но верстка сделана так, чтобы было удобно нажимать на весь экран. Мы тоже создали мобильную версию. Настроена автоматическая маршрутизация, если вы заходите на сайт, если у вас есть мобильное приложение, вы легко попадете на этот сайт.

И нужно ли вообще сейчас создавать приложения, когда есть такие мобильные сайты? Мобильная версия сайта полезна. Не нужно устанавливать ничего, но есть два минуса. Первое – вы не сможете монетизировать, т.е. если хотите что-то продать через сайт, то не сможете, а через приложение сможете. Второе – на сайт нужно будет заходить каждый день, вводить информацию, если вы продвинутый пользователь, то добавите в закладки, на главную

страницу. Если у вас стоит мобильное приложение, это иконка, которая у вас отображается на рабочем столе и как минимум 30-40 раз видите иконку, тем самым не забываете о ней.

Мультиязычность. Год назад при общении с представителем Всемирного форума татарской молодежи по имени Гульназ, я услышал: «Сез бит татар малайлары, сделайте татарскую версию тоже». Далее были два основных вопроса: цель и кто это будет делать. Специфика приложения такая, что приложением должны пользоваться все приезжие в Россию и для этого начали разрабатывать мультиязычность. Если здесь есть айтишники, кто знает, что такое «приятная плюшка»? Представьте, вы приходите домой, поели и вы были бы рады, если бы у вас в холодильнике стояла холодная кола, это не обязательно, но это приятно. И что важно, это уровень продукта. Если американец смотрит и там нет, как минимум еще английского языка, то он говорит, что уровень продукта низкий. Многие мои друзья, которые в дальнейшем учились за рубежом, помогли мне с переводом. В итоге появилась татарская версия. Наш лингвист – Ренат Гарифуллин. Тот, кто из Москвы скорее всего знает его, автор всех переводов именно он. Версия для телефона сейчас только в разработке. Кто знает, проблема с публикацией приложений, это происходит буквально от 3-х недель до месяца.

Когда вы начинаете тот или иной проект то вам интересны отзывы. Понятно, что вложив туда силы, вам это естественно не безразлично. В итоге, после 10 дней друзья вам говорят, вот же тут есть более интересный продукт, который попроще сделан и твое отношение к продукту уже меняется. Есть негативные отзывы и положительные. Негативные отзывы пишут обычно незнакомые люди, которые написав это на следующий день могут забыть об этом. А положительные отзывы больше получаешь при встречах. И участвуя на форумах, было приятно, когда люди подходили и говорили: «Мы пользуемся этим приложением», «В мечеть вчера съездил в такой-то области, построив маршрут по вашему приложению». К сожалению, положительные отзывы у нас в России никто писать не любит. Это нужно понимать, когда создаете свой проект. И какой-то научный айтишный проект у нас продавать, к сожалению, тоже не получится, а за рубежом, пожалуйста.

**Вопрос эксперта (Римма БИКМӨХӘММӘТОВА):** Ты говорил, что у тебя в команде около 13 человек, что ты платишь зарплату. Откуда?

**Айрат КАСЫЙМОВ**: Есть люди, которые патриоты своего

проекта, есть мусульмане понимающие что такое савап. Но есть в команде и русские люди, и из за рубежа. Сам считаю, что в проекте должны работать профессионалы, если они просят за это деньги, то пожалуйста. Найти их гораздо сложнее, но это того стоит.

*Вопрос из зала.* А прибыль приносит? Хотя бы что-то окупается?

**Айрат КАСЫЙМОВ**: Монетизация есть. Кажется, что это рассказывать не стоит. Размещение точек абсолютно бесплатно, но есть баннерная реклама, которую вы не видите и точка недели есть, которая отображается на сайте платно.

**Вопрос эксперта (Данил САФАРОВ):** Как вы утверждаете, добавлены точки по всей России?

**Айрат КАСЫЙМОВ**: Все точки, которые добавляют пользователи, приходят со статусом «не авторизировано». Специалисты сортируют эти точки, есть база данных, система целая, набирает номер, и если это подтверждается, что это халяль-кафе, то закрепляется. Я в Казани так приятно чувствую себя, тут практически все кафешки халяль, вот в Москве 3 года назад было совсем по-другому, единственные халяль-кафе там были, где есть пиво. Обычно негативные отзывы идут из Казани, но мы же показываем, что там есть спиртное, что там курят, т.е. сейчас, слава богу, нигде не курят. Мы показываем и человек, из своего уровня религиозности, набожности, сам контролирует: хочет он туда идти или нет. Мы говорим, что там есть халяль.

*Залдан сорау.* Googl Playда бар, iOSта бар, ә Windows Marketта булачакмы ул программа?

**Айрат КАСЫЙМОВ**: Пока у нас нет программиста для Windows Marketa. Для чего мы сделали мобильную версию сайта? Для того чтобы пользователи, на системах которых нет приложения, могли легко пользоваться сайтом. Скажу вам больше, сайт мы обновляем гораздо чаще, потому что это сделать гораздо проще.

*Залдан сорау.* Есть же компетентные люди по-поводу халяльности кафе. Халяль написать, сделать на сайте – это может сделать каждый, а тот человек, который исповедует Ислам, для него не все равно.

**Айрат КАСЫЙМОВ**: Спасибо. У нас есть параметры сертификата тоже, пожалуйста, вы можете отсортировать все точки, только те у кого есть сертификаты и ходить только по тем точкам, мы ведь не запрещаем.

**Айгөл ӘЮПОВА:** Исәнмесез, дуслар! Мин – Айгөл Әюпова. Казан федераль университетының татар филологиясе бүлегендә

укытам. Хәзерге вакытта төп шөгылем – бала тәрбияләү. Ике улым бар, олысы Нурбулатка 2 яшь ярым, кечкенәсенә, иншаллах, 2 ай булачак.

«Үчтеки» проекты – балаларын татар мохитендә тәрбияләргә теләгән әти-әниләр өчен. Сүземне башлар алдыннан, бармак уенын тәкъдим итәм, кайткач балаларыгыз белән уйнап карарсыз. Минем артымнан кабатлагыз:

Байгыш-байгыш (филин дигән сүз), әйдә, уйныйк качыш.
Тиз-тиз йөгерә тычкан, артыннан калмый йомран.
Сикерә йомшак йомран, шуыша арттан елан.
Тибрәлә шаулый камыш, менә бит минем табыш!
Һәм балагызны кочаклап аласыз.

Мин бу проектны ничек башлап җибәрдем? Моннан өч ел элек «Хәсән» нәшрияты җитәкчесе Гүзәл Хәсәнова миңа «Чырык-чырык чыпчык» дип аталган балалар фольклоры тупланган китапның автор-төзүчесе булырга тәкъдим итте. Бу китап өстендә эшләгәндә мин балалар фольклорын, әдәбиятын барлау, аны сайлап алу эшләре белән шөгыльләндем һәм шуны аңладым: татар халкының балалар өчен язылган бик матур бармак уеннары, мавыктыргыч әсәрләре күп, ләкин алар кайчандыр басылып югалган, кибетләрдә юк.

Икенче этәргече дә бар. Беренче баламның дөньяга килүен көтә идем: ничек тәрбияләргә? Татарча материаллар каян табарга? Шушы сораулар белән ВК сайтында «Үчтеки» дигән төркемемне ачып җибәрдем, анда балалар фольклоры әсәрләрен, балалар әдәбияты үрнәкләрен куйдым, аннары илһам килеп, үзем дә яза башладым, бармак уеннары, вак моториканы үстерү өчен бармакларга гимнастика, массаж белән шөгыльләнә башладым. Шуннан әниләргә кулланма рәвешендә видеога төшереп, ютубка элдем. Проект әкренләп үсә барды, рубрикалар да барлыкка килде. Төркемдә катнашучылар төрле өлкәдәге белгечләргә сораулар биреп, аларның җаваплары мәкалә рәвешендә «Үчтеки» төркеменә урнаштырылды. Аннан «Иң яхшы бармак уены» дигән бәйге игълан иттек.

Әлеге проект, дөресен генә әйткәндә, улым белән параллель үсте. Балам санарга өйрәнә икән, мин үз чиратымда саннар турында шигырьләр яздым, аларны видео, презентация рәвешендә эшләп, төркемдә урнаштырдым. Хәрефләр өйрәнә башлагач, әлифба тудыру идеясе килде, иптәшем белән пилот версиясен эшләдек. Марданшиннарның проектлары белән аваздаш булып чыкты ул,

алга таба проект өстендә бергәләшеп эшләрбез, бәлки. Хәреф һәм укырга өйрәтү бергә үрелеп барырга тиеш кебек. Хәзерге балаларга заманча технологияләр кирәк булуы белән дә килешәм.

«Үчтеки» тагын да ваграк проектларны үз эченә ала. Шундый уем бар: «Үчтеки»не онлайн журнал кебек эшләү. Арагызда балалар өчен язучы авторлар бар икән, яки психология, башка өлкәләргә караган мәкаләләр белән уртаклашырга телисез икән, рәхим итегез. Мин үзем инглиз теле укытучысы. Улым да инглиз телендә картон кәгазьдә басылган сыйфатлы әйберләрне бик яратып укый. Ләкин аларның татар теленә тәрҗемәләре юк, мин үзем кайберләрен тәрҗемә итем.. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Эксперт:** Ютубта күргәнем бар әлеге роликларыгызны. Мәгариф министрлыгы белән бергә эшләп карарга уйлаганыз юкмы?

**Айгөл ӘЮПОВА:** Мәгариф министрлыгына бардым, җавап шундый: андый проектларны без конкурс аша гына оештырабыз һәм юридик зат буларак кына эшли аласыз. Ә бу эшләр шактый катлаулы.

**Эксперт:** Команда буларак эшләргә кирәктер, әни буларак та.

**Айгөл ӘЮПОВА:** Иптәшемнең дизайн студиясе бар, мобильныйга приложениелар ясыйлар, берләшеп эшләсәк була, минемчә.

*Залдан сорау.* Балам татар, инглиз телендә рәхәтләнеп сөйләшә, дидегез, ә рус теле кая киткән?

**Айгөл ӘЮПОВА:** Ә рус теле урамда! Күршеләр, дуслар бар.

*Залдан.* Минем 2 яшьлек кызым бар, безгә бик читен туган телне саклап калу, чөнки чит төбәктә яшибез. Гаиләдә татарча гына сөйләшсәк тә, урамга чыккач, «эт»ләр, «песи»ләр «собачка», «кошка»га әйләнә. Сез бу мәсьәләне ничек хәл итәсез?

**Айгөл ӘЮПОВА:** Бездә дә бар бу проблема, безнең бала да урамга чыккач бер-ике минут аңламыйча тора, аннары инде ул сүзләрне отып ала. Параллель рәвештә алып бара. Минемчә, балаларның хәтере уникаль, улыма карап әйтәм, балалар губка шикелле.

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА**: Хәерле көн барчагызга да! Мин Казан федераль университетының IV курс студенткасы. Минем сезгә шаулап үткән «Ана теле» онлайн мәктәбен тәкъдим итәсем килә.

Әлеге проект оффлайн режимда, өч ел эшләп килә. Бүген проектта 9552 кеше теркәлгән, шуның 9301 Россия кешеләре, 251е чит илләрдән. Әлеге проект гади түгел, ул Education First компаниясе белән берлектә эшләнгән, ягъни, татар телен укыту методикасы инглиз теленнән алынган.

«Ана теле»нә теркәлеп кергәннән соң, татар телен белү дәрәҗәсен билгелисез, шуннан соң онлайн мәктәп тәкъдим ителә. Анда 9 дәрәҗә бар, һәр дәрәҗә 8 бүлеккә бүленә, һәр бүлектә 4 дәрес. Боларның һәрберсе видео, аудиоязма, фотографияләр аша бирелә. Әйтелеш, язу, грамматика лабораторияләрендә дә эшләргә мөмкин. Һәр биремне үтәгәннән соң сезгә бәя бирелә. Биремнәр арасында English leo программасы белән охшашлык күрәчәксез. Русча белмәүче тел өйрәнергә теләүчеләргә инглиз интерфейсы да бар.

Һәр дәрәҗәне тәмамлаганнан соң, сез 50 сораулык тест үтәргә тиеш буласыз. Ул үз эченә 4 күнекмәне ала. Грамматика, яңа сүзләрне кабатлау, уку һәм тыңлап аңлау (аудирование). Соңыннан сезнең балларыгызны чыгарып, шәхси кабинетка сертификат килә, кирәк булса бастырып ала аласыз.

«Ана теле» проектының тагын бер яңалыгы – 2013 елның декабреннән виртуаль дәресләр укытыла башлады. Шәхси кабинетыгызга кереп, дәрәҗәгез буенча үз вакытыгызны көтеп, виртуаль дәресләр аласыз. Һәр атна саен дүшәмбедән җомгага кадәр, Мәскәү вакыты белән 17:00- 21:00 сәгатьләрдә  2 дәрес үтелә. Бер дәрес 45 минут бара. Санакның икенче ягында сезне чын укытучы өйрәтәчәк.

Сүзем ахырына да җиттем, делегатлар, сез кайткач, һичшиксез, «Ана теле» проектында теркәлергә теләрсез, ләкин хәзерге вакытта 9552 кулланучы бар һәм, Education First тәкъдим итүе буенча, анда 10 000 кешелек лимит куелган. Әлегә теркәлгән кеше дә керә алмый, чөнки аларга лицензия юк, ләкин август аенда «чистка» башланачак, ягъни, актив булмаган кулланучыларны төшереп калдырып, өйрәнергә теләгән яңа укучыларга юл ачылачак.

*Залдан сорау.* **Гүзәл СӘГЫЙТОВА:** Мин Казан дәүләт консерваториясендә татар телен укытам. Ел башында «Ана теле» проекты турында студентларга сөйләдем. Алар теркәлергә теләделәр, ләкин, сез әйткәнчә, теркәлә алмадылар. 10 мең лимит кына булуы бик кызганыч. Проек кирәкле һәм бик кызык.

**Эксперттан сорау (Римма БИКМӨХӘММӘТОВА):** Әлеге лимит башка телләрне өйрәнгәндә дә шулаймы?

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА**: Әйе, испан, инглиз һ.б. телләрне өйрәнгәндә дә лимит 10 мең.

**Эксперттан сорау (Римма БИКМӨХӘММӘТОВА):** Барлык дәрәҗәләрне үтүче кешеләр бармы? Һәм нинди нәтиҗә әйтеп була?

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА**: Кызганыч, андыйлар юк, 5 меңгә якын кеше 1 нче дәрәҗәне үткән.

**Лилиана САФИНА**: Башка төбәкләрдәге кебек, бездә дә 2004 елдан бирле татар теле курслары эшләп килә. Елдан-ел анда килергә теләүчеләр саны арта, алар арасында татарлар күбрәк, шулай ук руслар, яһүдләр дә бар. Курслар башлангыч, урта һәм иркен сөйләшүчеләр өчен. Мәскәү халкының күбесе мишәрләр. Быел минем интенсив төркемгә бер укучы килде, ул әйтә: «А нет казанско-татарского и мишарско-татарского словаря?» Бу сорауга ничек җавап бирергә? , Әдәби телне белергә кирәк, ул безнең уртак телебез булырга тиеш, дип аңлатам.

Татар телен тәкъдим итүчеләргә соравым бар. Без кулланган әдәбият, материалларда текстлар күбрәк спорт, гаилә, ашамлыклар, кибетләр турында. Күп вакыт, татарлар ашыйлар һәм кибеткә генә йөриләрмени, дигәнне ишетәм. Татарның башка җанлы сүзләре гомумән кулланылмый. Мәсәлән, рус телендәге «занеси» сүзен татарча «чыгып алып кереп бир» дип әйтеп була, моның турында беркем дә язмый. «Минем ашыйсым килә», «ашарга бирең» дип кенә булмый бит, без телнең җанын, эчтәлеген, моңын югалтабыз. Бу зур проблема һәм, әлбәттә, Мәскәү шәһәрендәге курсларда без моның өстендә ел саен эшлибез, курсларга йөрүчеләрне арттырып барабыз. Хәлдән килгәнчә эшләргә тырышабыз. Быелгы курсларны «Милли мәктәп» дип атарга җыенабыз. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Эксперт (Римма БИКМӨХӘММӘТОВА):** Себер татарларында аерым тел дип әйтәсез, Мәскәү татарлары да аерым татар телен барлыкка китермәгез, зинһар өчен. «Чыгып алып керү» дигән сүзне «алып килү» дип кенә дә әйтеп була, татар теленең камиллеген өйрәнергә кирәк.

**Римма БИКМӨХӘММӘТОВА**: «Мин татарча сөйләшәм» акциясе киләсе елда үзенең 10 еллыгын билгели. Шушы вакыт эчендә ул иң уңышлы проектларның берсе дип, инанып әйтә алам һәм, бүгенге нәтиҗәләрен күреп, сөенә алабыз дигән фикердәмен. Бүгенге проектлар да шушы акциядән башланып китте. «Әлифба» булдыру, татар теленә өйрәтү – болар барысы да «Мин татарча сөйләшәм» акциясеннән чыккан проектлар.

Бүген пленар утырышта да, әлеге акцияне күп төбәкләрдә уздырырга кирәк, дип әйтеп үттеләр. Мин сезгә аның бераз механизмын өйрәтмәкче идем.

Кыскача гына тарихына килгәндә, без берничә кеше – язучылар, журналистлар, укытучылар – табыштык та берләшергә булдык. Татар телен куллану даирәсен киңәйтү идеясе белән, татар теле –

яшьләр теле, татарча сөйләшүче кеше – кәттә кеше, заман белән бергә атлаучы кеше, перспективалы дигән фикерне алга сөрдек. Икенче тармагы шәһәр мәдәниятен булдыру иде: моңа кадәр неформат булып саналган, ләкин бүген инде йолдыз булган, рэп, этно-фолк, рок стилендәге җырчыларны сәхнәгә чыгару. Татар теле – шәһәр теле, телнең уңай имиджын булдырыйк, яшьләр туган телендә аралашсын дигән фикер белән эшкә тотындык.

Кыенлыклар тумады. Еш сорыйлар: кайдан финанс аласыз? Финанс табу чыннан да авыр. Сөйләүлекләр, футболкалар, түштамгаларны булдырганда да үз акчабызны тоттык. Дәүләттән сорамадык, спонсорлар эзләмәдек. Чит ил технологияләрен кулланып, open air, ягъни, ачык зур мәйданга татар телен чыгарырга һәм заманча мәдәният белән үреп, зур акция булдырырга кирәк иде.

Урамда промоутерларны күрәбез бит: алар киләләр, товарларын тәкъдим итәләр. Безнең өчен товар ул – тел иде. Хәзер исемә төшерәм: яшьләр, алар бик солидный кешеләр иде, футболкалар киеп, Буман урамына чыгып киттек. Кешеләргә елмаеп эндәшә идек.

– Сез татар телен беләсезме?

Күбесе, юк, ди. Аннан:

– Хотели бы вы его изучить?

– Для чего?

– Вы знаете, что если вы знаете татарский язык, то вся тюркоязычная 500 млн. аудитория открывается для вас. Если вы владеете татарским языком, можете стать президентом Республики Татарстан. Что ваш iq на 10 пунктов становится выше, дип, позитив рәвештә татар теленең өстенлеген аңлата идек. Соңыннан матур теләкләр теләп, «Ваши первые 150 слов на татарском» дигән сөйләүлекләр яки түштамгалар бирә идек.

Күп кеше аптырый иде: ничек инде телне шулай урамда таратып була?. Ләкин без бу барьерны уздык. Бауман урамында ул вакытка кадәр татарча чаралар узмый иде, ә хәзер инде анда татар яшьләре тулы канлы хуҗа булып, халыкны җәлеп итеп, акцияне гөрләтәләр!

Акциянең кыйммәте шунда, бу – тулысынча гражданлык инициативасы белән барлыкка килгән проект. Шуның белән ул кадерле һәм мөһим. Битараф булмаган кешеләрнең күңелендә туып һәм ихлас теләк белән, тулысынча үз көчебезгә башкарылган проект. Нәрсә өчен моны әйтәм? Чөнки күбегездән ишеткәнем бар, имеш, бу акция Казанга гына яраклы. Монда бары сезнең оешмаларыгызның җирле хакимият белән уртак фикергә килүе, алар-

дан бары урамга чыгарга рөхсәт кәгазе кирәк һәм үзегез чыгасыз да, бездә булган технологияләргә нигезләнеп, акцияне оештырасыз. Сез төбәкнең тулы хокуклы гражданнары, ул Алтын Урдадан калган дәүләт, без үзебезнең җирдә яшибез һәм үз телебезне һәр шәһәрдә, төбәктә таныта алабыз. Татарлар йомылып яшәргә тиеш түгел, киресенчә, зур мәйданнарга чыгып, позитив энергия белән татар телен өйрәнү, татар теле, мәдәнияте турында, гомумән, татарлар турында мәгълүмат җиткерү безнең бурычыбыз.

Дәүләтнең авызына карап утырмыйча, яшьләр тупланып проектны башлап җибәрә алды. Мин үз чиратымда сценарийдан алып, нинди мәгълүмат кирәк, ярдәм итәргә әзер.

**Ринат ГЫЙЛӘҖЕВ**: Әссәламагаләйкүм, дуслар! Билгеле, бүген татар телен өйрәнү һәм саклап калу бик әһәмиятле. Практика булмау сәбәпле, соңгы вакытта яшьләр татар телен оныта башлады. Аеруча чит төбәкләрдә яшәүче татарлар турында сүз бара. Яшьләрне яңа татар китаплары белән кызыксындыруы авыр. Мин дә шундыйларның берсе.

Татар телен өйрәнү өчен яңа форматлар кирәк. Үзебезнең татар «Маназара» клубы турында сөйлисем килә. Клуб дебатлар форматында үтә, чөнки ул бүгенге көндә актуаль формат. Тема дискуссия, резолюция форматында алып барыла. Ике төркем: резолюцияне хуплаучылар белән кире кагучылар һәм аудитория. Аудиториянең сорау бирү мөмкинчелеге бар. Процесс барган вакытта актив катнашу таләп ителә. Бер командадан бер кеше 1-2 минут эчендә бирелгән теманы яклап чыгыш ясарга тиеш. Каршы команда вәкиле әлеге фикерне 2-3 минут эчендә кире кагарга һәм үз дәлилләрен китерергә тиеш. Шундый стандарт дебатлар структурасы буенча дәвам итәбез. Фәкать татар телендә генә фикер алышуны төп таләп итеп куябыз.

*проект*

## VI Бөтендөнья татар яшьләре форумының РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

**3 август, 2014 ел Казан шәһәре**

Татар яшьләре тормышының актуаль мәсьәләләре турында фикер алышканнан соң, борынгы рухи мирасыбызны, милли йөзебезне, ана телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калдыру, буыннардан-буыннарга ирештерү максатында, VI Бөтендөнья татар яшьләре Форумы (БТЯФ) делегатлары түбәндәге

КАРАРНЫ КАБУЛ ИТТЕ:

– Бөтендөнья татар конгрессының V съезды тарафыннан тәгаенләнгән мөһим мәсьәләләрне тормышка ашыруны төп максат итеп санарга;

– Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге татар яшьләре оешмалары белән элемтәләрне тагын да ныгыту буенча Бөтендөнья татар яшьләре форумы идарәсенең эшчәнлеген хупларга;

– Сәяси әһәмиятлеген аңлаган хәлдә, Татарстан Республикасында президентлык институты статусын һәм Россиядә федерализм принципларын үстерү буенча татар иҗтимагый оешмалары һәм киң җәмәгатьчелекнең тырышлыгын хупларга;

– Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге татар тарихи-мәдәни мирас объектлары кергән экскурсион программаларны булдыру максатында, яшьләр белән эшләү һәм туристлык Федераль агентлыгы, ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы туризм агентлыгы белән тыгыз элемтә булдырырга. Шулай ук халыкара яшьләр туристлык программалары кысаларында, махсус порталлар, он-лайн сервислар ярдәмендә татар халкының тарихи-мәдәни мирас ядкәрләрен һәм Татарстан брендентанытуда актив катнашырга;

– Уставта билгеләнгән максатлар нигезендә, халыкара, россиякүләм һәм республикакүләм грантларны оту өчен җирле яшьләр оешмаларының төрле бәйгеләрдә актив катнашуына ирешергә;

– Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә теләктәшлек ассоциациясе белән берлектә милли мәгарифне, туган телне, тарихи үзаңны үстерү, милли традицияләрне, гореф-гадәтләребезне саклау максатында ивестиция проектлары төзергә һәм тормышка ашырырга;

– Үзәк Азия һәм Европада яшәүче татар яшьләрен туплау-берләштерү эшенә ярдәм итәргә;

– Татар яшьләренең Татарстан Республикасы югары уку йортларында белем алуын киңәйтергә, аларны БТЯФ эшчәнлегендә актив катнаштырырга;

– Татар телен өйрәнү һәм актив пропагандалау максатында «Мин татарча сөйләшәм», «Автохәрәкәт», Татар дозор», «Печән базары һәм Уку паркы» кебек акцияләрне дәвам итәргә, аларны үткәрү географиясен киңәйтергә;

– Бүгенге көндә татар телен өйрәнүдә популяр булган «Ана теле» онлайн-мәктәбе эшчәнлеген киңрәк җәелдерү эшендә актив катнашырга. Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә яшәүче мәктәп балаларының татар теле һәм әдәбияты буенча Татарстан республикасында үткәрелүче халыкара олимпиадада катнашуына булышлык күрсәтергә;

– Авылларда яшәүче татар яшьләрен «Россия татар авыллары» иҗтимагый берләшмәсе эшчәнлегенә киңрәк тартырга, татар авыллары яшәеше серләренә төшенү, туган телебезнең тәмен тоемлау йөзеннән милли бәйрәмебез «Сабантуй»ны, «Авыл кызы» конкурсларын, атлар чабышы ярышларын шәһәр һәм авыл яшьләре белән берлектә үткәрергә, «Россия татар авыллары» иҗтимагый оешмасы белән уртак милли-мәдәни туристлык программалары төзергә;

– Татар телен укыту өлкәсендә милли мәгарифтә килеп туган торгынлык күренешләрен бетерү максатында, Татарстан Республикасында татар теленең, дәүләт теле буларак, рус теле белән бер дәрәҗәдә укытылу таләбен хупларга. Этник милли укыту оешмаларына һәм татар теле курсларын оештыручы оешмаларгаярдәм күрсәтергә, шәхси милли һәм якшәмбе мәктәпләренең эш тәҗрибәсен өйрәнеп, киң кулланылышка кертергә, төбәкләрдә мондый мәтәпләрнең санын арттыруга ярдәм итәргә. Ата-аналар, белем бирү оешмаларына милли белем бирүнең зарурлыгын төшендерергә;

– Гаилә институтларының әһәмиятен аңлаган хәлдә, яшьләр арасында милләтнең төп нигезе булган татар гаиләсен төзү һәм саклап калуның әһәмиятен пропагандалау, милли гаилә төзү зарурриятен аңлату эшләрен алып барырга;

– Бөтендөнья татар яшьләре форумына һәм җирле оешмаларга кешенең шәхес буларак камилләшүендә, формалашуында дини тәрбиянең никадәр әһәмияткә ия булуын билгеләп, дини кыйммәтләрне өйрәнергә, яшьләр арасында традицион ислам тәгъли-

матын пропагандаларга, радикаль идеяләр үтеп керүне булдырмаска;

– «Хәләл» регионара иҗтимагый оешмасының сатып алучыларның хокукларын яклау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча алгарышын хупларга, урыннарда әлеге продукцияне тарату, сертификацияләү, сыйфатын контрольдә тотуда ярдәм күрсәтергә;

– Татарлар күпләп яши торган төбәкләрдә татар теленең рәсми (дәүләт) тел статусы булырга тиешлеген күтәреп чыгарга;

– Татарстан Республикасы җитәкчелегенең тел, мәдәният, мәгариф өлкәсендәге сәясәтен хуплаган хәлдә, Европа хартиясенең төбәк телләренә мөнәсәбәтле уңай эш юнәлеше турындагы мәгълүматны киңрәк таратырга, Европа хартиясенең Россиядә актуальләшүенә ирешергә;

– .tatar доменының рәсми ачылуына, татар интернет чараларының таралуына, үсешенә төрле яклап ярдәм итәргә;

– Россиянең төрле төбәкләреннән, чит илләрдән Татарстан Республикасына күченеп килүче яшьләргә ярдәм буенча дәүләт программасын булдыру турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим белән чыгарга;

– Татар яшьләре оешмаларының халкыбызның милли горефгадәтләрен, ана телебезне саклауга юнәлтелгән проектларын һәрьяклап хуплау грантын булдыру турында Татарстан Республикасы хөкүмәтенә тәкъдим итәргә;

– Милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне, туган телне, этномәдәният, телләр төрлелеген, толерантлыкны, үзара татулыкны тагын да ныгытырга, үстерергә, фашистик идеологияне, милләтчелекне, шовинистик төркемнәрне булдырмау йөзеннән милли яшьләр оешмалары белән хезмәттәшлекне тагын да көчәйтергә;

– Спорт яшьләргә физик яктан камилләшергә генә түгел, ә үзара аралашу өчен дә зур мөмкинлекләр тудыра. Соңгы елларда үткәрелгән халыкара спорт форумнары, шул исәптән, Казанда узган Бөтендөнья җәйге Универсиада-2013, Сочида булган кышкы Олимпиа-2014 уеннары милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне, дуслыкны, хезмәттәшлекне ныгытуда ышанычлы корал булып торуын искә алып, әлеге уңай тәҗрибәне актив кулланырга.

– Безбөтендөнья яшьләрен Россиядә 2015 елда су спорт төрләре, 2018 елда үткәреләчәк футбол буенча дөнья чемпионатларын һәм Формула I ярышларын уздыруны хупларга һәм анда катнашырга чакырабыз;

– Татарстанда икетеллелекне саклау һәм үстерү максатыннан Дәүләт телләре турында канун нигезендә Татарстан президенты каршында икетеллелек мәсьәләләре буенча омбудсмен һәм

Татарстан хөкүмәте каршында икетеллелек мәсьәләләре буенча иҗтимагый шура булдыруны таләп итү.

– Хаталы тәрҗемәләрне, элмә такталарын төзәтү һәм алга таба аларга юл куймас өчен Казанда бердәм тәрҗемә үзәген булдыруны тәкъдим итү.

– Казанда татар телендә чит ил һәм татар фильмнарын күрсәтә торган заманча кинотеатрны булдыруны тәкъдим итү.

– Бөтендөнья татар яшьләре форумы хатын-кызлар баш киемен – яулыкны, милли традицион баш киеме икәнен билгеләргә. Татар кызларының яулык йөртүе, татар мәдәниятен һәм әхлагын саклау өчен бик мөһим. Бөтендөнья татар яшьләре форумы кызларның яулык бәйләп йөрергә тыю карарын инкяр итүне Мордовия Республикасының җитәкчелегенә һәм шундыйук карарлар кабул ителгән Россиянең башка төбәкләренә мөрәҗәгать белән чыга.

*Проект*

**РЕЗОЛЮЦИЯ**
**VI Всемирного форума татарской молодежи**

**3 августа 2014 г. г.Казань**

Делегаты VI Всемирного форума татарской молодежи, всесторонне обсудив роль и место татарской молодежи в деле сохранения национальной идентичности, родного языка, образования, культуры, обычаев, традиций и самобытности народа,

РЕШИЛИ:

– Учитывая особую политическую значимость, всемерно поддержать инициативу татарской общественности и общественных организаций Республики Татарстан по сохранению статуса института президентства Республики Татарстан и развитию в России принципов федерализма;

– Выступить с инициативой придания татарскому языку статуса официального (государственного) в крупных регионах с компактным проживанием татар;

– Предложить Государственному Совету Республики Татарстан выработать государственную программу поддержки молодых татар-соотечественников переезжающих в Республику Татарстан из других регионов Российской Федерации и из стран зарубежья;

– В целях сохранения и развития двуязычия в РТ на основании закона о Государственных языках РТ поддержать требование создания должности омбудсмена по вопросам двуязычия при Президенте РТ и общественного совета по вопросам двуязычия при Правительстве РТ. – В целях исправления ошибок в переводах на вывесках в РТ предложить создание единого центра переводов в Казани;

– Предложить создание современного кинотеатра в Казани, где будут демонстрироваться татарские фильмы и зарубежные фильмы, переведенные на татарский язык.

– Предложить правительству Республики Татарстан организовать грантовую поддержку проектов татарских молодежных организаций, направленных на развитие народных традиций и сохранение татарского языка;

– Считать важнейшей задачей в своей деятельности претворение в жизнь актуальных задач, поставленных на V съезде Всемирного конгресса татар;

– Одобрить усилия совета ВФТМ, направленные на расширение и укрепление связей с молодежными движениями других регионов РФ и зарубежных стран;

– Тесно взаимодействовать с Федеральнымы структурами по делам молодежи, агентством по туризму, министерством по делам молодежи Республики Татарстан, Агентством по туризму Республики Татарстан, международными туристическими организациями по созданию молодежных и экскурсионных программ с включением в них объектов историко-культурного наследия татарского народа в Республике Татарстан и Российской Федерации. Принимать активное участие в продвижении бренда Татарстана, позиционировании значимых для татарского народа объектов историко-культурного наследия в рамках программ международного молодежного туризма, в том числе посредством специализированных порталов и он-лайн сервисов;

– Общественным организациям молодежи на местах активно участвовать в конкурсах для получения международных, российских, региональных грантов для реализации своих уставных задач;

– ВФТМ совместно со Всемирной ассоциацией содействия татарским предпринимателям разработать и осуществлять программы по реализации инвестиционных проектов, способствующих сохранению и развитию национального образования, родного языка, исторического самосознания, традиций и обычаев;

– Всемерно содействовать процессу консолидации татарской молодежи Центральной Азии и Европы;

– Содействовать татарской молодежи в получении образования в вузах Республики Татарстан, активно вовлекать данную категорию татарской молодежи в общественную деятельность ВФТМ;

– Продолжать работу по пропаганде и изучению татарского языка посредством таких акций как «Мин татарча сөйләшәм», «Автохәрәкәт», «Татар дозор», «Печән базары һәм Укупаркы», расширить географию их проведения;

– Активно участвовать в реализации популярной программы онлайн-школы по изучению татарского языка «Ана теле». Содействовать участию учащейся молодежи регионов Российской Федерации и зарубежных стран в международной олимпиаде по татарскому языку и литературы, проводимой в Республике Татарстан;

– Шире вовлекать сельскую молодежь в работу общественного объединения «Татарские села России», практиковать совместное

проведение народных праздников «Сабантуй», конкурсов «Авыл кызы», конно-спортивных соревнований, а также практиковать посещение городской молодежью татарских сел с целью «погружения» её в родную языковую и культурную среду. Разработать и реализовать совместно с общественным объединением «Татарские села России» соответствующие программы этнокультурного туризма;

– В целях преодоления кризисных явлений в национальном образовании поддержать преподавание татарского языка, как государственного в равных правах с русским языком на территории Республики Татарстан. Оказывать всяческое содействие существующим этнокультурным национальным образовательным и учреждениям, организующим курсы татарского языка, активно изучать и внедрять опыт частных национальных и воскресных школ, участвовать в их организации на местах. Вести разъяснительную работу с родителями учащихся, администрациями образовательных учреждений, с тем что они способствовали сохранению национального образования;

– Учитывая особую важность института семьи, продолжить работу по пропаганде ценностей татарской семьи, как основы сохранения нации, в том числе традиционной для татар моноэтнической семьи;

– ВФТМ и местным организациям изучать и сохранять религиозные ценности как важный элемент в воспитании и формировании цельной личности, считать важной задачей пропаганду традиционного ислама и противодействия проникновению идей радикализма в молодежную среду;

– Поддержать инициативу межрегиональной общественной организации «Хәләл» по защите прав потребителей продукции и услуг этой отрасли, оказывать на местах всяческую помощь, связанную с реализацией, сертификацией, контролем за качеством данной продукции;

– Поддержать политику руководства Республики Татарстан в области языка, культуры и образования и способствовать продвижению принципов Европейской хартии региональных языков, распространению информации о положительном опыте реализации её положений, содействовать актуализации в России процессам ратификации Европейской хартии региональных языков;

– Содействовать официальному открытию домена .tatar и поддержать его развитие, всячески способствовать реализации татарских интернет ресурсов;

– Усилить сотрудничество с национальными молодежными организациями по вопросам сохранения национальной культуры, традиций, развития родных языков, поддержки этнокультурного и языкового многообразия, отстаивания идей толерантности, межнационального мира и согласия, противодействия попыткам ревизии фашистской идеологии, проявлениям национальной и религиозной ксенофобии;

– Учитывая, что спорт для молодежи является не только возможностью физического совершенства, но и перспективным способом коммуникации, использовать опыт, накопленный в ходе проведения крупных спортивных форумов, таких как Всемирная летняя Универсиада-2013 в г. Казани и Зимние Олимпийские игры-2014 в г. Сочи для достижения межконфессионального и межнационального согласия, укрепления дружбы и сотрудничества;

– Мы, участники Форума призываем молодежь всего мира самым активным образом поддержать проведение в России соревнований Формулы I, чемпионатов мира по водным видам спорта в 2015 и по футболу в 2018 годах;

– Всемирный форум татарской молодежи решил заявить, что женский головной убор – платок – является традиционным национальным головным убором и способствует сохранению татарской культуры и нравственности. Всемирный форум татарской молодежи решил обратиться к руководству Республики Мордовия с просьбой отменить постановление правительства, запрещающего ношение головных уборов в школе, а также ко всем главам регионов России, где приняты подобные решения.